Индекс 73951 Татар һәм урыс телләрендә чыга
ISSN 0235-974X

Идел

яшьләр журналы

7 / 99

ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ЖУРНАЛЫ

1989 елның июленнән бирле татар һәм урыс телләрендә чыг

Баш мөхәррир
РАШАТ НИЗАМИ

Идарә
Дамир ИСХАКОВ
Ислам ӘХМӘТҖАНОВ
Роза ШӘРӘФИЕВА,
җаваплы сәркәтип
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА,
бүлек мөхәррире
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ
Роза КОЖЕВНИКОВА,
баш мөхәррир урынбасары
Рәфикъ ЮНЫС,
баш мөхәррирнең беренче урынбасары
Фәридә ХӘСЪЯНОВА,
баш рәссам
Солтан ШӘМСИ,
бүлек мөхәррире

Мөхәррирләр
Гөлсирә ГАЙНАНОВА
Диләрә НӘҮРУЗОВА
Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ
Марат ЗАКИР
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА
Сергей МАЛЫШЕВ

Гамәли хезмәткәрләр
Альберт СӨЛӘЙМАНОВ
Гәүһәрия КӘРИМУЛЛИНА
Гөлсинә ШӘРИФУЛЛИНА
Гөлфия ХӘЙРУЛЛИНА
Мөнирә КУЗИЕВА
Нәгыйм ШАҺИ
Рушания ХАРИСОВА
Резидә ӘХМӘТҖАНОВА
Ринат НӘСЫЙБУЛЛИН
Светлана ЛАТЫЙПОВА

Журналны редакциянең компьютер төркеме җыйды һәм битләргә салды.

Журналны гамәлгә куйды: Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, Татарстан язучылар берлеге һәм редакциянең журналистлар коллективы.

«Идел»дәге язма, фото яки рәсемнәрне тулысынча йә өлешчә күчереп басу редакциянең рөхсәте белән генә башкарыла.

Журнал Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 222 сан белән теркәлгән.
Журналга Татарстанның көндәлек басмалар каталогы һәм Русия үзәк каталогы буенча язылып була.

Индекслар: татарчасыныкы — 73951, урысчасыныкы — 73952.

Редакциянең адресы:
420012, Казан, Мөштәри ур.,14. «Идел»
Белешмәләр телефоны: 36-97-32.

© «Идел», 1999, №7



Рашат Низами,
"Идел" журналының
баш мөхәррире

Көрәш рухын югалтмаска!

Әле кайчан гына...

Әйе, әле кайчан гына ишегалдында социализм хөкем сөрә иде. Теләсәк, аның төрледән-төрле якларын мактарга да, сүгәргә дә була хәзер. Әйтик, матбугат басмалары ул чакта шактый гына көйле-рәхәт яшәп ята иде: тиражлар зур, акча-финанс кытлыгы юк, югарыдан тиешле күрсәтмәләр бирелгән һ.б. Саташып китеп "Долой Советскую власть!" дигән сүзләрне ычкындырмасаң, кәнәфидә килеш коммунизм үрләренә таба тыныч кына барасың да барасың инде...

Шулаен шулай, әмма социализм дигәнең татар яшьләрен, һай, рәнҗетеп тә карады соң! Хәтергә төшерик: СССР дигән чагыштырмача йомшак империя үзенең канат астына 15 союздаш республиканы сыендырган иде. Урыс, украин, латыш, казакъ, үзбәк, грузин һәм башка милли республикаларның һәммәсендә дә яшьләр басмасы өзлексез чыга килде. Ә татарга нәрсә? Яшьләр журналы кирәк, дип авызыңны ачып кына кара, салкын канлы Мәскәү шундук бармак яный, баш очында йодрыгын уйната башлый.

Сан ягыннан Россиядә урыслардан кала икенче урынны тоткан татар милләте өчен бу гаять зур гаделсезлек, күрәләтә мыскыллау иде, әлбәттә.

Дөрес, 1922 елда Казанда "Кызыл шәрекъ яшьләре" дигән журнал ачыла. "Авыл яшьләре", аннары "Колхоз яшьләре" дип исемен үзгәрткәләп тора да... берничә елдан соң "шалт" итеп бөтенләйгә ябылып та куела.

Татарның яшьләр журналын торгезү өчен көрәш күп еллар буе бара. Әлеге мәсьәлә Татарстан һәм Россия язучыларының һәр съездында диярлек күтәрелә. Ләкин журнал ачу кебек гап-гади шушы эшне башкару ул чакта берәүнең дә кодрәтеннән килми. Ил җитәкчеләре эшчән-тырыш, тәвәккәл татарны Себергә "күчереп" утырту турында хыялланган бер заманда, кая инде аңа яшьләр журналы ачарга ирек бирү! Урысча укысыннар, совет халкы дигән тоташ масса кочагында эресеннәр, юкка чыксыннар янәсе...

Әле кайчан гына!..

Әйе, һәркемнең исендәдер: 60 нчы елларда яшьләр журналын ачу өчен көрәш аеруча кызып китте һәм татар милли азатлык хәрәкәтенең аерылгысыз бер өлешенә әверелде. Исемнәрен санап тормастан, гаделлек хакына шунысын әйтеп китик: бу изге көрәштә күп кенә журналистлар, язучылар, хөкүмәт һәм җәмәгать эшлеклеләре актив катнашты. Мең рәхмәт аларга!

Нәтиҗәдә, татар яшьләре хәятендә "Идел" дип исемләнгән яңь-яшь журнал барлыкка килде. Мәгълүм булганча, аның беренче саны 1989 елның июль аенда дөнья күрде. Киң катлам җәмәгатьчелек моны ифрат сөенеп, куанып кабул итте. Журналны, баш мөхәррир буларак, иң беренчеләрдән булып Римзил Вәлиев, аннары Фәиз Зөлкарнәй кебек талантлы каләмдәшләребез җитәкләде.

Инде менә "Идел" журналының чыга башлавына, ниһаять, 10 ел икән.

Тарих өчен бик тә кыска ара — мизгел генәдер бу, әмма көрәш тарихын, әлеге басманың татар яшьләре, рухият, әхлак, туган тел һәм миллият өчен әһәмияте хакында уйлансак, шушы кыска гына арага мәгънәви яктан әллә ничаклы казанышлар, байлыклар кереп сыйган.

"Идел" журналы кыска гына вакыт эчендә яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә ихтирамын яулады. Яшьләр журналы дип аталса да, без аның сәхифәләре ир-атлар, хатын-кызлар, әбиләр һәм бабайлар, абыйлар һәм апайлар, сеңелкәшләр, энекәшләр, киленнәр, кияүләр — кыскасы, һәр гаилә өчен кызыклы, мәгънәле, файдалы булсын диеп тырышабыз.

"Идел" — татар һәм урыс телләрендә чыга. Аның колачын, тематикасын, юнәлешен кыскача дүрт сүз белән аңлатырга мөмкин: әдәбият, мәдәният, миллият, заман.

Барысы да шома гына бара дип әйтергә җыенмыйбыз. Проблемалар, хәл итәсе мәсьәләләр бездә дә җитәрлек. Шулардан берсе — акча-финанс кытлыгы. Цивилизацияле илләрдәге шикелле, һичшиксез, бездә дә милли басмаларга дәүләт булышлыгы кирәк. Шөкер, бюджет кесәсеннән безгә дә азмы-күпме өлеш чыгаралар. Бирүен бирәләр, әмма шул ук акчаны тулысы белән диярлек салым өчен үкертеп басып та калалар. Ягъни хөкүмәт бер кулы белән биргәнне икенче кулы белән шундук тартып та ала.

Алда безне мөлдерәмә килеш Яңа XXI гасыр көтеп тора.

Мөстәкыйльлеген, дәүләтчелеген өр-яңадан торгызу өчен җитди көрәш башлаган татар халкы бу яңа гасырга ни рәвешле килеп керер? Алга таба ул үзенең туган телен, менталитетын, интеллектуаль көчләрен саклап кала алырмы? Әлеге сорауларга без шәт журнал битләрендә бергәләп җавап табарга тырышырбыз.

Сезне, милләттәшләребезне, "Идел" журналы бердәмлеккә, озын-озак сәфәргә чакыра.

Бергә булыйк!

ISSN 0235-974X

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын!

Идел

№7(119)

БУ САНДА УКЫГЫЗ:

СУ БАШЫ
МАНСУР ВӘЛИЕВ
"ИДЕЛ" ӨЧЕН КӨРӘШ

Җитмешенче-сиксәненче елларда авторга әлеге авыр, тигезсез көрәшнең әйдәүчесе булырга туры килә. "Идел" журналының чыга башлавы сугыштан соңгы чор әдәбияты өчен иң зур вакыйга булды", — ди М.Вәлиев.

УН ЕЛ ЭЛЕК...
РИМЗИЛ ВӘЛИЕВ
ИДЕЛ ҺАМАН АГА

Буяу исе аңкып торган буш бүлмәгә каяндыр урындыклар табып түгәрәкләнеп утырдык. Редакциягә Язучылар берлеге тәкъдим иткән яисә үзем белгән кешеләр чакырылды. Иң талантлы, иң көчле, дәртле һәм усал егетләр, кызлар читтә калмаска тиеш иде.

10024 БИТНЕҢ БЕРСЕ

Ун елда "Идел"нең төрле калынлыктагы 118 саны дөнья күрде. Без шул битләрне күздән кичерергә, ягъни, кыскартып яки өзекләр алып, аларның кайберләрен тергезергә булдык.

ВАКЫТ ТӘРӘЗӘСЕ
ИНСАФ СОЛТАНОВ
ФӘИЗНЕҢ ЯШЕЛ КУЫШЫ



Еллар үтеп аның туры сүзле тәнкыйтьче, үзенчәлекле шагыйрь, "Идел"не асыл журнал иткән баш мөхәррир булып китүенә бер дә гаҗәпләнмәдем. Фәиз үзенең кем буласын балачактан ук белгәндер сыман тоела миңа.

НӘСЕР
ӘЧТЕРХАН ЧИКЛӘВЕГЕ
Гасыр бәяне



1993 елны "Идел" күмәкләп иҗат ителгән "Арысланнар араны" исемле гасыр романы бастырган иде. Шул традицияне дәвам итеп быел да дүрт язучы гасыр бәяне "коеп куйдылар".

БЕЗНЕКЕЛӘР

"Идел" журналында эшләүчеләр белән укучыларыбызны Нәбирә Гыйматдинова таныштыра. "Әмма ни-нәрсә генә булса да "Идел" дөньяга чыга һәм аны "безнекеләр" әвәләп чыгара. Ә "безнекеләр" шәп халык!" — ди ул.

ША-ЯРЫШ
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
МИНҺАҖ МАҖАРАЛАРЫ

Минһаҗ абзый бу юлы "закун" яза. "Гаилә турында закун".

Басарга кул куелды 13.07.99. Заказ З-338. Гомум тираж 4403
Кәгазь форматы 84х108, 1/16. Күләме 8,87 шартлы басма табак. 13,51 нәшер-хисап табак.
Татарстан гәзит-журналлар нәшрияты басмаханәсе.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Разил Вәлиев,
Татарстан милли китапханәсе директоры

Безнең яшьлек үзенчә кызык та, кызганыч та булды. Заманасы шундый иде: җан теләгән китапны укып, теләгән киемне киеп, теләгән әйберне алып, теләгән җиргә барып булмады. Әмма барысына түздек, безгә шулай язгандыр, шулай тиештер дип уйладык.

Әмма Казанга килеп, бераз күзләр ачыла, телләр чишелә башлагач, дөньядагы бу гаделсезлекнең бары тик безгә генә түгел, "татар" исемен йөрткән тулы бер халыкка кагылганын аңладык. Юк, сүз хәзер инде кием-салым, ашау-эчү турында гына түгел, ә кешегә мөнәсәбәт, СССР дип аталган империядә татарга карата булган мөгамәлә хакында бара иде. Үзеңнең хокуксыз халык, каргалган кавем баласы икәнлегеңне даими тою матди бөлгенлеккә караганда күпкә авыррак булды.

Шигырь-хикәя язган иркенрәк холыклы без яшьләр җәмгыятьнең кыршаулы кысаларына сыеша алмыйча бәргәлә әндек. Чөнки әйтәсе килгән фикерне әйтергә ярамый, язган әсәреңне бастырырга яшьләр өчен бер әдәби газета-журнал юк, радио-телевидениедә дә татар сүзе өчен вакыт минутлап кына санала.

Без татарның язмышын беркем дә читтән килеп үзгәртмәсен, үзебезгә кирәк һәммә нәрсәне бары тик көрәшеп кенә яулап буласын елдан-ел ныграк төшенә бардык. Яшь язучыларның беренче катгый таләбе — яшьләр өчен журнал ачу иде. Журнал таләп итеп өч дистә ел буе Мәскәүгә баш оруларның, партия өлкә комитетында аһ-зар елауларның нәтиҗәсе булмагач, 1968 елда Татарстан Язучылары Корылтаенда театр балконыннан листовкалар чәчәргә мәҗбүр булдык.

Бүген гөрләп яшәп ятучы, инде иң популяр һәм мәгънәле басмаларның берсенә әверелгән "Идел" журналы чыга башлау — соңгы ярты гасырда халкыбызның рухи яңарышына, милли аңы уянуга юл тоткан җиңүләрнең беренчесе булды шикелле.

Кайбер басмалар кебек, "Идел" өйрәнчеклек чорын үтеп тормады, ул дөньяга туганда ук өлгереп туган иде. Беренче саннарыннан ук аның кыйбласы ачык, иманы төзек булды.

Соңгы ун елда татарда шактый басмалар дөнья күрде. Безнең хәзер әдәби газета-журналларыбыз да, хатын-кызлар һәм укытучылар өчен чыга торганнары да, хөкүмәтнекеләр һәм хәтта аерым кешеләрнеке дә бар. "Идел" журналы аларның берсенә дә охшамаган: ул, олыгайган ата-ананың көтеп алган беренче баласы кебек, аерым кадергә ия. "Идел"не яшьләр журналы, диләр. Юк, ул авыл яисә шәһәр яшьләре, студентлар басмасы гына түгел. "Идел" — чын мәгънәсендә бөтен милләт журналы, чөнки ул һәр санында татар халкының күңел түрендә йөргән иң мөкатдәс хисләрен үзенең укучыларына җиткерә. Әгәр журналны алдыручыларның саны берничә йөз меңгә җитеп, аларның һәммәсе "Идел" уйлаганча уйлый башласа, милләтебезнең рухи яңарышы өчен 4-5 буын түгел, ә бер буын гомере дә җитәр иде.

Равил Фәйзуллин,
"Казан утлары" журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре

"Без — Иделле халык. Хәзер инде "Идел" журналлы да булдык. Хәер, борын-борыннан Идел безнең рухыбызда, җыр-көйләребездә, җаныбызда. Без — Идел балалары, Иделкәйнең суын эчеп үскән кешеләр, аны (хәтта процентлар исәпләсәң дә байтакка чыга!) үзебезнең тәнебездә, вөҗүдебездә йөртәбез...

Әйе, "Идел" — байтак дистә еллар буе берничә буын көрәшеп, кан-яшь елап, күп кимсенүләр һәм югалтулар аша яулап алынган журнал. Күп көч куеп, азап белән килгән бәхетнең шатлыгы да зуррак, кадерлерәк була. Шуңа күрә дә, без — теге яки бу дәрәҗәдә әдәбиятта катнашып килгән каләм ияләре — Иделнең бөек исеменә лаек итеп иҗат итәргә тиешбез дип беләм. "Идел бит ул тирән бит ул, Идел бит ул киң бит ул!" Журналыбыз, чыннан да, киң күңелле булып, төрле төбәкләргә чәчелгән талантлы яшь милләттәшләребезгә күбрәк юл ачсын; һәр җөмләсе, һәр бите, һәр әсәре мәгънәле һәм тирән булсын!"

Бу юлларны мин нәкъ ун ел элек язганмын. Хәзер дә үтеләк, фикерләрем үзгәрмәде, киресенчә, бу теләкләр көчәйде генә. Бу еллар эчендә хыялдагы гына түгел, реаль журналның йөзләгән санын күрдек, укыдык, яраттык, уйландык, кайчак көрсенебрәк куйган чаклар да булгандыр, һәрхәлдә, бу журналга карашыбыз, мөнәсәбәтебез анык хәзер. Кистереп әйтеп була: өметләрнең күбесе акланды. Бик тә четерекле — үзе кызык, үзе фаҗигале шушы ун ел эчендә үзеңне саклау, йөзеңне һәм мәсләгеңне югалтмау бер басма өчен дә җиңел нәрсә түгел. Моны әдип буларак һәм матбага эшендә катнашкан кеше буларак әйтәм. Журнал шушы еллар эчендә шактый көчле авторлар төркеме булдыра алды. Бүгенге көннең иң актуаль проблемалары, бигрәк тә милли-сәяси темалар яшьләргә хас кыюлык белән даими яктыртылып килә. 90 еллар башында милли азатлык көрәше, бүтән басмалар белән чагыштырганда, аеруча тәфсилле һәм объектив яктыртылды дип уйлыйм. Йөзләгән яшь авторларның беренче мәртәбә "Идел"дә дөньяга күренүләре — журналның төп вазифасын башкаруы чагылышы. Полиграфик яктан да журнал яшьләргә хас зәвекъ белән матур итеп бизәлеп чыга. Әлбәттә, редакциядә тирән белемле, талантлы каләмдәшләребезнең эшләве төп нәтиҗәгә китерә дә инде. Журнал чыга башлаганнан бирле эшләүчеләр — Р.Зәйдулла, Н.Гыйматдинова, Р.Кожевникова, соңрак килеп кушылганнар — Фәиз белән Ләис Зөлкарнәйләр, Рашат Низамиев, Рәфикъ Юныс, Солтан Шәмси, С.Малышев, Марат Закир... Болар бит үзләре зур бер көч! Шуларга өстәп күпме фидакярь гамәли хезмәткәрләр...

Юбилей уңаеннан гадәттә күбрәк мактау сүзләре ишетерелсә дә, теләкләр дә юк түгел. Иң мөһиме — тиражны арттыру, журнал укучыларның сафын ишәйтү. Киләсе гасырда үз телебездә укучы яшьләрнең күбрәк булуын теләү — безнең җанда, канда бит! Ә әлегә, бу ямьле җәй көннәрендә ун еллык юбилей бәйрәме матур һәм мәгънәле узуын телибез!

Казан, Мөштәри ур., 14. "Идел"гә

"Идел" дигән сүз ул зур һәм җаваплы сүз. Чөнки Идел һәм Урал халкыбызның күмәкләп яшәгән урыны, тарихи ватаны. Шуңа күрә күп еллар элек мин үземә "Иделле" дигән иҗади исем алган идем. Димәк, мин сезнең журналның адашы булам инде.

1989 елның җәендә "Идел" журналының иң беренче саннары Финляндиядә яшәүче татарлар аша Мюнхенга килеп җиткән иде. Бу басма Германиядә яшәүче татарлар, бигрәк тә "Азатлык" радиосы хезмәткәрләре өчен зур һәм күңелле яңалык булды. Аның демократик һәм чын милли рухта, заманча чыгарылуы чит ил татарларының күңеленә хуш килде. "Идел"дә басылган кайбер мәкаләләр, шигырьләр радиобыз аша да яңгырый башлады. "Азатлык" радиосының Татарстан зыялылары белән тыгызрак аралаша башлавына "Идел" журналы зур тәэсир ясады.

Хәзер инде Татарстан һәм татар халкы тормышы шактый үзгәрде. Уңай күренешләргә "Идел" журналы да сәбәпче булуына шикләнмим. Киләчәктә дә сез милли тәрәккыятне җитәкләп баручылар арасында калырсыз дип ышанам.

Фәрит Иделле,
"Ирекле Европа"/ "Азатлык" радиосының
татар-башкорт редакциясе мөдире

"Идел" журналы кулыма эләккән саен мин аны бик кызыксынып укыйм. Һәркем үзен яшь итеп хис итә. Күңел картаймаса, яшьлек үтми, диләр. Миңа сезнең заманча затлы, алдынгы фикерле язмаларыгыз ошый. Иншалла, киләчәктә латин хәрефләре белән басыла башласа, "Идел", һичшиксез, еракларга яңгыраячак. Чит илләрдәге яшьләр дә укысын иде аны.

Хөрмәтле дуслар, барыгызны да "Идел"нең ун еллык бәйрәме белән котлыйм. Бәхет, уңышлар телим.

Төркәр Соуккан.
Швеция, Стокгольм шәһәре

Су башы

Мансур Вәлиев

"Идел" өчен көрәш*

"ИДЕЛ" ЖУРНАЛЫНЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫ СУГЫШТАН СОҢГЫ ЧОР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ӨЧЕН ИҢ ЗУР ВАКЫЙГА БУЛДЫ.

Илле ел гомер — ул бик озын вакыт бит! Аның дәвамында ничәмә-ничә мәртәбә зур тантаналар уздырдылар... Шау-гөр китереп һәр биш ел саен "татар әдәбияты үсешендә зур адым булган" съездлар үткәреп барылды. Югары дәрәҗәдәге кунаклар кабул ителде... Ә инде төрле атналыкларны , декадаларны санап бетерү мөмкин дә түгел! Һәм әле тагын шуныңише башка чаралар... Боларның бик күбесе ул чагында "дәүләт күләмендәге әһәмияткә ия эш" иттереп үткәрелде. Алар өчен илнең һәм җөмһүриятнең әллә никадәр акча байлыгы тотылды.

Без менә хәзер "Идел"нең чыга башлавы әнә шуларның барысы белән чагыштырганда да зуррак вакыйга дип әйтергә телибез түгелме соң?!

Әйе, нәкъ шулай! Чөнки моңа бик тә саллы дәлилләр бар.

Әдәбиятның яшәве һәм үсүе өчен иң беренче чиратта нәрсә кирәк? Нәрсә иң мөһим шарт булып тора?

Моның өчен әдәби әсәрнең язылуы һәм басылып чыгуы кирәк! Әдәби әсәрләр язылса һәм басылып чыкса — әдәбият яши һәм үсә дигән сүз!

Әлеге дә баягы Тукайлар, Фатих Әмирханнар чорын алыйк. Ул чагында татар телендә дә гәзит-журналлар күп чыккан, ә Язучылар берлеге бөтенләй дә булмаган. Ләкин бит безнең бик күбебез белеп тора: бу дәвер — Тукайлар чоры — татар әдәбиятының алтын чоры!

..."Идел"нең чыга башлавы милли матбугатның яңадан җанлана башлавын, уянып килүен күрсәтүче беренче адым иде. Без югарыда искә алып үткән шау-

* Идел, 1996 ел. №2. Кыскартып басыла.

шулы вакыйгаларның берсе дә үзенең әһәмияте ягыннан "Идел"гә тиңләшә алмый!..

"Идел"гә чуму

Ерак Көнчыгышта ике ел офицер булып хезмәт итеп кайтканнан соң мин бер ярты ел чамасы Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант вазифаларын башкардым.

Ә менә 1975 елның ахырына Фаил Шәфигуллин, "Идел" альманахы мөхәррире булып эшләгән җиреннән, тотты да "Чаян"га күчте. Аның урынына мине куйдылар.

Шунысын да әйтеп китим: мин әле ул вакытта СССР Язучылар берлегендә әгъза булып тормыйм, басылып чыккан китапларым да юк.

...Идарә утырышына "Идел" мәсьәләсен чыгаруны иң элек аксакаллар белән киңәшүдән башладык. Гомәр ага Бәширов белән Нәкый ага Исәнбәт безнең фикерне берсүзсез якладылар...

Сибгат аганың бер керүендә Илдар абый аңа ипләп кенә серне чишә башлады. Хәлне аңлатты. Хәтерлим, Сибгат ага шундук җитдиләнеп китте һәм берсүзсез килеште дә! "Кайчан керәбез соң..." — дип кенә куйды бугай ул... Инде төгәл хәтерләмим: шул ук көннеме, әллә бераз үткәчме — ләкин Сибгат ага белән Илдар абый берлек рәисе Гариф Ахунов янына кереп, андагы идарә утырышларының берсендә "Идел" альманахы мәсьәләсен куярга булдылар...

...Бу утырыш озак, бик тә озак барды. Анда катнашкан бер генә кеше дә сүз алмыйча, үзенең фикерен белдермичә калмады...

...Тагын-тагын киңәшә торгач, мондый уйга килдек — яшьләр өчен чыгарылачак журнал турында сүз баргач, иң элек комсомол Үзәк Комитетына мөрәҗәгать итәргә кирәктер. Җөмһүриятнең барлык иҗат оешмалары һәм комсомол өлкә комитеты исеменнән! Комсомол өлкә комитеты вәкиле Ринат Закиров безнең утырышта катнашты. Ул эшне тулысынча белә һәм безне аңлый. Тик менә аның мөдире Шәймәрданова дигән ханымга килеп җиткәч, эш озакка терәлде, туктап калды. Хикмәт шунда: үзенең хезмәт вазифасы кушуы буенча ВЛКСМ Үзәк Комитетына дигән әлеге хатны менә шушы Шәймәрданова язарга тиеш. Ә ул, күрәсең, мондый эшне — алар өчен гадәти түгел адымны — башкара алмый. Аның хәленнән килми бу! Яшьлегем, тәҗрибәсезлегем аркасында аның кулыннан килмәгәнлекне мин дә аңлап җитмим әле... Шуңа күрә, көн саен диярлек аның янына барып: "Эш ничек тора?" — дип сорыйм...Арттырып әйтүем түгел: бер унлап мәртәбә генә барганмындыр! Аптырагач, әлеге ханымның ачуы ук кабара башлады! Мине күрәсе үк килми тегенең...Шулай, байтак кына мине дә газаплагач, үзе дә шактый гына тинтерәгәч — ниһаять, көннәрдән берендә, Ринат әлеге хатның башланган вариантын үз бүлмәсенә алып чыкты да, без ул хатны бергәләп тиз генә арада язып та куйдык!

Ахыры 6 биттә

"Идел" бит ул!..

Илһам Шакиров

Һәрбер укымышлы татар кебек, мин дә "Идел" журналын озак еллар көтеп алдым. Аны беренче саннарыннан бирле укып барам. Милли аңны уятуда гаять зур эш башкардыгыз.

Татар җыр сәнгате, музыкасы турындагы язмаларга аерата игътибар итәм. Алак-шалак җырлаучылар белән сәхнә тулган бу заманда халык зәвегы өчен борчылып язылган андый мәкаләләр бик кирәк. Талантлы җырчыларны халыкка күрсәтеп, орлыкны кибәктән аерырга ярдәм итәсез.

Гомерең озын булсын, "Идел"! Кышын өстеңне калын боз капласа да, яз барыбер киләчәк бит!



Туфан Миңнуллин

Мин Идел янында туган малай. Идел белән яшьлегем нык бәйләнгән. Казанга бердәнбер юлыбыз да Идел өстеннән иде: җәен — пароход, кышын — ат чанасы.

Шуңа күрә "Идел" дигән сүз минем өчен аерым бер мәгънәгә ия.

"Идел" журналына да мөнәсәбәтем — аны туган көненнән үк якын күрүем — исемемә бәйледер. Бәхетемә каршы, анда мине хөрмәт итүчеләр эшләде, һәрвакытта да журналның көтеп алынган авторы булдым. Бүген дә, Аллага шөкер, шул традицияне дәвам итеп, мине үз итүчеләр Идел малаен онытмыйлар. Рәхмәтем зур.

"Идел"нең гомере Идел кебек озын булсын. Иделдә су мул булсын, "Идел"дә су әз булсын.

Әле бу гына да түгел. Ринат Закиров белән без әзерләгән ул хат инде тәмам кысасына кереп җиткәч, теге Шаймәрданова дигән бүлек мөдире дә аның белән килешкәч, комсомолның идеология буенча секретаре бар бит әле. Бу елларда анда Газизуллин дигән иптәш иде. Менә шул секретарь безгә болай димәсенме:

— Бик җитди проблема бу. Ашыкмыйк... Әйдәгез, махсус комиссия төзеп, тагын бер кат тикшерик! Хатны җибәрми торыйк.

Моңа кадәр дә бит инде аларның бүлек мөдире артыннан йөреп, ярты ел чамасы гомер үткән. Хәзер бусы, яңадан өйрәник, ди, комиссия төзик, ди! Шунда мин түзеп тора алмадым, кызып китеп, аңа болай дип тездем:

— СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким, Тукай бүләге лауреаты Хәсән Туфан һәм бүтән бик күп абруйлы әдипләр фикере сезгә дәлил түгелмени! Сездә әдәбиятны һәм аның проблемаларын болардан да ныграк аңлый торган тагын кем бар? Сез кемнәргә тапшырып, вакытны тагын да сузарга уйлыйсыз?!.

...Ниһаять, безнең иҗат берлекләре һәм комсомол өлкә комитеты исеменнән язылган хат комсомолның Үзәк Комитетына китте...

Ләкин шулай да, ул хат җибәрелгәнче, мондый фикергә дә килгән идек. Хатка тагын да көч бирү өчен, проблеманың дөреслегенә өстәгеләрне ышандыру өчен, халыктан Мәскәүгә хатлар җибәрергә кирәк!..

Баштарак ул хатларга "мәсьәлә өйрәнелә" дигән стандарт кына җаваплар да килә иде. Соңрак алары да туктады...

Түрәләр янында

Чиратта — өлкә комитеты иде. Өлкә комитетында исә идеология секретаре булып М.Ф.Вәлиев, ә культура бүлеге мөдире булып М.М.Мусин утыра. Болар — торгынлык чорының, шул системаның иң типик вәкилләре. Һәр икесе бик шома, бик ыспай сөйли. Тыштан бик интеллигент кыяфәтле, "шәп" кешеләр... Ләкин милләт өчен, мәдәният өчен алар дәверендә эш кенә эшләнми! Милли мәктәпләр ябыла бара, татар китапларын басу бик нык кими.

...Берничә көннән Сибгат ага Вәлиевнең ризалыгын алды. Тиз генә арада Вәлиевкә кемнәр барасын да киңәштек: Сибгат ага Хәким үзе, Гариф абый Ахунов, Шәүкәт абый Галиев һәм мин...

...Менә хәзер ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк — әмма барысы ике сәгатьләп вакытны алган ул сөйләшүнең баштагы бер сәгать ярымы бөтенләй бүтән нәрсә турында барды!.. Арабыздагы иң өлкән кеше Сибгат ага өчен мондый озакка сузылган сүз бигрәк тә авыр иде... Әле, шуның өстәвенә, Вәлиев без кергәч телефоннан берничә кешегә шылтыратып та алды, шулай итеп, тагын күпмедер вакыт югалды...

Менә шуннан соң гына өлкә комитеты секретаре безнең мәсьәләгә күчүне кирәк тапты. Аның мөнәсәбәте: "Әйе шул, кирәк шул, кирәк!" — дигән стандарт сүзләр рухында булды һәм бераздан шундый ук стандарт булган "ләкин..."гә килеп терәлде: илдә кәгазь белән хәл авыр бит әле, автономияле җөмһүриятләрнең берсендә дә андый журнал юк, без алсак, бүтәннәргә дә бирергә кирәк була, кәгазь бик күп сорала...

Ул боларны шаярган төсле генә, бик тиз арада гына әйтеп алды, җитди әһәмият бирмичә генә...

Аннары оста артистларча безнең алда тагын бер "сәхнә номеры" башкарды ул — телефоннан тиз генә Үзәк Комитетны җыеп алды, тегеннән әйтелгән сүзне шундук безгә дә кабатлагандай итте:

— Леонид Ильич аша гына дисезме?..

Бу инде "проблеманы Брежнев кына хәл итә ала" дигән сүз иде, янәсе.

Шул рәвешле безгә дә җавап бирү кебек иде инде бу! Шуннан соң Вәлиев, без утырган өстәл янына килеп, һич тә кәефен төшермәстән, үзе өчен бик күңелле темага әңгәмә кылгандай, сүзен дәвам итте. Ә бераздан безнең җитәкчебезгә болай диде ул:

— Давай, Гариф, без сине ни өчен депутат итеп сайладык! Давай йөр, теләсәң кая кер — синең хәзер бөтен полномочиелар да бар бит!

Гариф абый аның белән килешкән дә сыман, шул ук вакытта ризалашып та бетмәгән тавыш белән нидер әйтте...

...Сергей Михалковка бездән делегация керүнең тагын бер файдасы булды. Ул РСФСР Язучылар берлеге исеменнән РСФСР Министрлар Советына хат язды. Бу хатта РСФСР Министрлар Советы безгә яшьләр журналы кирәклекне хуплап КПСС Үзәк Комитетына чыкса яхшы булыр иде диелгән иде...

...РСФСР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары В.И.Кочемасов хатны өйрәнү һәм тәкъдим белән чыгу өчен РСФСР Госкомиздатына җибәргән булган. Нәкъ менә шушы көннәрдә генә җавап та килгән. Анда нәрсә дип әйтелгән дисез? "Татарстанда болай да журналлар күп, аларга әлегә журналлар җитә". Менә сиңа мә!..

...Һәм без, үзара киңәшкәч, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф.Табиевка язма рәвештә мөрәҗәгать итәргә булдык! Хат аксакаллар исеменнән булырга тиеш!..

...Яхшы хәтерлим — барлык аксакалларыбыз да әлеге хатка бик теләп кул куйдылар. Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Нури Арслан, Нәби Дәүли, Фәнис Яруллин һ.б. әдипләрнең имзалары булды. Әлбәттә, һәркайсының өенә барырга, аерым сөйләшергә туры килде.

Шулай итеп, хат тулысынча әзер. Тик аны беренче секретарьга ничек итеп тапшырырга соң?!Әгәр гадәти юл белән барса, ул хат башта өлкә комитетының мәдәният бүлегенә, аннары идеология секретаре Вәлиевка керергә тиеш. Ләкин тегеләрнең хатны үткәрүенә өмет юк. Барып җиткән хәлдә дә, никадәр вакыт югала дигән сүз! Ул арада съезд узып китәргә дә бик мөмкин. Кыскасы, өлкә комитеты секретаре янына үзем керергә булдым! Ә ничек, диярсез? Табиев бит җиде кат ишек артында! Кат-кат милиция саклый аны!

Әле ул чагында мин, КПССта тормау сәбәпле, берәр

эш чыгып өлкә комитетына керергә кирәк була икән, андагы иптәшләргә телефоннан шылтырата идем дә, алар миңа эчкә үтү өчен пропуск әзерлиләр иде. Менә шушы юлны файдаланырга булдым. Өлкә комитетының мәдәният бүлегендә утыручы таныш иптәшләргә телефоннан шылтыратып болай дидем:

— Сезнең янга киңәшергә киләсе бар иде, зинһар өчен миңа пропуск эшләтегез әле!

Бераздан теге бик мөһим хатны алдым да, өлкә комитетына киттем. Хәерле сәгатьтә!

Дошман тылына разведкага барганнан ким дулкынланмыйм!

...Пропуск тотып, өлкә комитеты бинасына кердем. Һәм мәдәният бүлегенә үткән кыланып, шундук икенче катка менеп тә киттем. Инде уйлыйм:

— Хәзер нишләргә?!.

...Ә аннары, ни өчендер, без язган хатны Табиевка гомуми бүлек тапшырырга тиештер дип уйладым мин ул чакны. Гомуми бүлек мөдире Рәмиев дигән түрәнең ишеге ярым ачык, үзе эчтә иде. Керер-кермәс кенә аңа хәлне аңлаттым. Хатны тизрәк Табиевка тапшырырга иде, дидем. Ә ул мине кырыс кына тыңлап торды да:

— Хатыгызны мәдәният бүлегенә бирегез! — диде. Мин исә яңадан аңлата башлыйм. Эш ашыгыч, вакыт сузыла, хатны бик тиз тапшырырга кирәк иде бит! Ә Рәмиев миңа җикеренә үк башлады:

— Вы меня поняли?!

Табиевның кабул итү бүлмәсен эзләп йөрим... Коридорда сораштыра-сораштыра барам. Шактый гына шик тә уятканмындыр инде яшьлегем, тәҗрибәсезлегем белән...

Көч-хәл белән таптым. Алары да әллә ничәү икән. Күп кешелек делегацияләр өчен хәтта кабул итү залы да бар. Мин килгәндә анысы буш иде... Ә янәшәдә генә, Табиевның үз кабинетына кергән урында, кабул итү бүлмәсе икән. Анысы да иркен, якты. Өстәл янында бер егет үзе генә басып тора. Минем яшьләрдә булыр. Акыллы гына, сабыр гына кыяфәтле. Ул миңа шундук ышанычлы, әйбәт егет булып күренде. Мин инде дошманнарны үтеп, ничектер үзебезнең кеше янына килеп чыккандай итебрәк сизә башладым. Һәм, иплән кенә, үземнең язучы аксакаллар исеменнән килүемне сөйләп бирдем. Безнең менә шушындый ситуация иде, бер-ике көннән безгә Сергей Михалков килә — шуңа кадәр Фикрәт Әхмәтҗанович та белеп торса иде дип аңлаттым.

Бу егет Табиевның ярдәмчесе булып чыкты. Ул хәлне аңлады. Хатыбызга тиз генә күз йөртеп тә чыкты. Иң зур әдипләребезнең имзалары да аңа тәэсир ясагандыр инде, билгеле. Һәм егет безнең хатыбызның бүген үк Табиевка тапшырылачагын әйтте...

...Ә икенче көнне Язучылар берлегендә шундый сүзләр таралды: Табиев тиз арада "Идел" буенча документлар әзерләргә кушкан! Үзе шөгыльләнмәкче була икән!..

...Язучылар съезды башланганчы ук КПСС өлкә комитетының матбугат секторы, язучылар берлеге "Идел" буенча кирәкле документларны әзерләп куйдылар.

...Тәнәфескә чыккач тиз үк беленде: Табиев белән Михалков исеменнән КПСС Үзәк Комитетына хат әзерләп йөриләр икән!..

Суслов һәм башкалар...

...Әлеге хат белән безнең Ф.Табиев КПСС Үзәк Комитетына бара. Брежневтан соң икенче фигура булган М.Суслов янына керә ул. Ә анда нинди сөйләшү булган соң?

Өлкә комитетындагы танышлар аркылы соңрак шул беленде. Алар арасында җылы гына сөйләшү булган. Суслов нигездә уңай караш белдергән һәм Үзәк Комитетның мәдәният бүлеге белән пропаганда бүлегенә тиешле документлар әзерләргә кушкан. Татарстанда яшьләр журналын торгызу буенча кирәкле кәгазьләрне әзерләргә!..

Вакыйгаларның менә шушы чоры безнең, ниһаять, тулы җиңүебез кебек тоелган иде! Табиевның Сусловта булуы һәм аның уңай фикерен ишетү — инде яшьләр журналы мәсьәләсен бөтенләй хәл итте сыман иде!..

...Иң соңгы, иң җитди сүзне без озак, бик озак көттек. Көтә-көтә мин үземнең җәйге ялымда да булып килдем. Ә теге хәбәр һаман юк. Шуннан соң инде без: "тагын нәрсә дә булса эшләргә!" дигән карарга килдек.

Әнә шул чагында милләтебезнең атаклы галиме Әбрар ага Кәримуллин белән сөйләшкән сүз искә төште. Элегрәк бер вакытны ул болай дигән иде: "КПСС ҮКның милли мәсьәлә буенча бик әйбәт бер консультанты бар икән. Ул иптәшнең әтисеме, әнисеме татар икән..."

...Безне кызыксындырган журнал мәсьәләсен Мәсгут ага белми иде...

...Ләкин Мәсгут ага Жунусов безгә ярдәм итәргә булды... КПСС Үзәк Комитетының матбугат секторы мөдире — аның әйбәт танышы икән.

...Наил Бариевич янына мине 5 кенә минутка дип кerткәннәр иде. Безнең сөйләшү ярты сәгать чамасы дәвам иткәндер. Ул миңа хәлне болай дип аңлатты:

— Табиев Суслов янына кереп, аннан мәсьәләне карарга ризалык алгач та, яшьләр журналы белән ҮКның мәдәният бүлеге шөгыльләнә. Ул чакта анда Шауро дигән иптәш иде. Алар "боларга журнал кирәк!" дигән карар чыгарган, тиешле документларны әзерләгән. Икенче баскыч — "кече Политбюро" утырышы. Һәм әнә шунда хөрмәтле генә бер иптәш (Наил Бариевич миңа аның кем икәнен әйтә алмыйм диде) түбәндәге фикерне уздыра:

— Бу мәсьәләне әлегә кичектереп торырга кирәк!..

СОҢГЫ СҮЗ

...Илгә яңарыш килде.

Бөтен проблемалар бер юлы өскә калыкты. Чишелеш сорый башлады. Күпләр исәбеннән "Идел" дә үзенә юл тапты. Айлык журнал булып дөнья күрә башлады, тиз арада йөз меңләп тираж җыйды! Милләтнең иң кызыклы һәм бай эчтәлекле басмасына әверелде!

Бу сәхифәдә без укучыларыбызны башлап язучы 56 автор белән таныштырдык. 57 нчесе менә Динә Әхмәт була.
Динә эшкуар, Чабаксарда яши.
Шөкер, дөнья куу аның җанына тутык төшермәгән. Юкса мондый хикәяне яза алыр идеме ул?

Динә ӘХМӘТ

Per aspera*, яки Бишкүмәч эпие

(сугарылган хикәя)**

I

Эпи, эпекәй! Безнең төбәктә ипине шулай атыйлар. Эпиләр бихисап күп төрле була: озынча, түгәрәк, сырлы, сырсыз, ак, кара, мәкле, киндер орлыклы, пудралы... Ләкин безнең өйдәге кебек тәмле эпине сирәк очратырга туры килде миңа. Үзе хуш исле, зур-зур тишекле, күпереп пешкән, кызгылт, түгәрәк, сырлы эпи. Иң-иң тәмле җире шул сырлары сыман тоела да инде. Кибән башы дип атала ул. Шуңа үзебезнең Чибәркәй сөтеннән аертылган сөт өстен ягасың да, аннан соң, үзебез җәй буе Марҗа чокырыннан җиләк җыеп ясаган вәринҗәдән бизәкләр төшерәсең дә, авыз суларын китереп, "сеп-сеп" ашап җибәрәсең. Каядыр икенче берәүләр дә үзләренең мүкләк сыерлары биргән сөттән аертылган сөт өсте ягып, Наруш чормагыннан җыйган җиләк вәринҗәсен таслап, шулай ук тәмләп кинәнәдер. Бу элеккечә, авылча сникерс була инде.

Эпинең тәмле булуы әфсенгә түгел, ә баш ясауга бәйле. Кисмәктәге әчене җылы су белән җебетеп, кирәгенчә җиз иләктән җилгәнгән он, аннан ары йомырка, атланмай, тоз вә песок салып, махсус агач калак белән яхшылап болгатасың да җылы урынга куясың. Ярый, ул кабара торсын...

Гомумән, эпи басу ул — үзе бер ритуал. Аны табибнең операциягә әзерләнүе белән тиңләргә мөмкин. Әвәлен кулыңны яхшылап юдыртып, башкаеңа чәчләреңне капларлык итеп яулык бәйләтеп куялар, алдыңа алъяпкыч асалар. Шулай итеп, мин — "табиб", эпи басам, әнкәй — шәфкать туташы, алып, салып, биреп, куеп кына тора. Изгәлим, әвәлим, кулга ябышмый башлаганчы басам да басам. Әнкәй сырлы табаларны майлап тезеп куя, мин тигез итеп камырны бүлеп салам да, өсләрен туглаган йомырка белән сылап тигезлим. Шулай иткәч ул гелләрем матур вә йөзе килеп кызара. Кисмәк төбендә икенче эпигә баш ясар өчен камыр калдырыла. Эпие уңа торган кешедән гелән-гелән әҗәткә дә сорап керәләр аны, алтын бәрабәренә йөри ул, шуңа күрә "мая"ны җитәрлек итеп калдырырга кирәк.

Җиде эпи табасы кучкарга менеп утыра. Алар кабара торган арада мичне тергезеп җибәрергә кирәк. Инде рольләр алышына, баш табиб вазифасын әнкәй үз кулына ала, мин, шәфкать туташы, дөресрәге, баласы кебек, алып, биреп торучы. Морҗаның кашындагы һәм муенындагы һәммә тарткычлар тартылып, ачыласы әйберләр ачылып беткәч, карусыз гына, лапас сәндерәсеннән утын алып керәм, әнкәй аларны аркылы-торкылы итеп мич эченә өя. Аннан соң үзебез "пиларам"нан җыйган йомычкаларны, каен тузларын "апкерәм", әнкәй аларны алгарак өеп ут кабыза. Утын бик тиз янып китә. Мич авызын калай капкач белән томалап куябыз. Капкач инде тишкәләнеп беткән, шул тишекләрдән сихерле ут җемелдәп, бу җем-җемә балкыш күзләрдә чагыла, сәкенең түр башында утырганда әллә ниткән уйларга батыра. Ниндидер тарту көче, сихәт, бабалар рухы бар бу ялкын телләрендә. Элекләре борынгы бабаларыбыз да шулай сихри учак тирәли яшәешнең газаплап сорауларына җавап эзләп утырганнардыр. Күчмә халык тирмәдә урта бер җирдә яккан бит ул учакны, шуңа ишарә: безнең өйләрдә мич тирәли әйләнеп йөреп була. Бу бит учак!.. Нигә бу почмакларда асалы яки чуклы-чүпләмле искитмәле сокландыргыч сөлгеләр икән? Нинди генә төсләр уйнамый анда: кызыл, зәгъфран, яшькелт — барысы да җете, кәттә төсләр. Өйнең күрке, яме булырдай бу буяуларны салават күперен чалкан егып, шуннан алсаң гына инде. Җирдән мыскаллап җыеп кына җепкә бу кадәр сут сеңдереп буламыни, җүләркәем. Ни өчен безнең әбиләр, әниләр почмак күренгәнне яратмый? Шул сөлгеләрне элеп йомрылый, тирмә, чатыр кебек итә. Болар бит барысы да тиктомалдан түгел... Әйтерсең лә хәтер учагы яна. Ул учакка әнкәй утыннар өстәп ала. Сүрелми учак. Һәркемнең өй түрендә үз учагы, тормышлар төрлечә акса да, тарих бер генә шул.

Безнең мич шома яна. Холкы мич чыгаручы Нуррәйхан абыйныкы кебек җайлы, ипле. Кимәлен китереп салган. Төзи генә түгел, башыннан азагына кадәр бер кәлимә сүз дә әйтмичә, "Ончы Фәхри" көен

* *лат.*, каршылыклар аша.
** Җыр һәм шигырь белән сугарылган хикәя. Язганда "Курай" белән "Дулкын"ны тыңлау нәтиҗәсе.

көйләп, илһамланып иҗат итә ул мичне. Андый шанлы оста бар микән ул тагын, ай-һай!?

Янып бетмәгән кисәүләрне кисаугач белән мичнең кече ягына өяләр. Мич җылысын җәлләми, өй эченә рәшә булып җылы ультракыска дулкыннар тарала. Казанда тәмле аш пешә.

Иртәгәсе көннең дә хәстәрен кайгыртырга кирәк: самавыр кайнату өчен уртача зурлыктагы кузларны сайлап, чуен чүлмәккә тутырып, өстен таба белән каплыйлар. Зерә матур ул чүлмәк тулы кызгылт-миләүшә ут! Мич тартканда, кайчак күмер кисәге идәнгә төшеп китә дә аны яндырып алырга өлгерә. Ул чокырларның да файдасы бар, чикләвек ватып ашарга бик уңай.

Ниһаять, мич әзер. Мин кабарынкы эпиләрне селкетмичә генә җайлап әнкәйгә бирә барам, ул бисмилласын укый-укый, табагач белән иплән кенә мич түренә тезә бара.

Бер сәгатьтән алар әзер булырга тиеш. Әнкәй мич капкачын ачып карый да, аһ итә, аның йөзе җиде кашлы йөзек күргән кеби яктырып китә. "Йөзләре килгән!" — дип куя, уңган, димәк. Минут эчендә аларны кисаугач белән тартып чыгарып табадан төшерәбез дә, астына эскәтер җәеп, бер-берсенә бөяп, мичнең йөрәк ягындагы кучкарга тезәбез. Өстен "бафлилы" сөлге белән ябып куябыз. Шулай итеп безнең кара күзләр өендә эпи пешә. Җиде эпи. Атнаның җиде көненә. Җиде бала өчен...

II

Тик экономия дигән нәрсә бар. Он быелгы яңа уңышка кадәр җитсен өчен, бераз кысыбрак тотарга туры килә.

— Җитәр микән?

Күңелне өтәли һәм өшетә торган бу сорауны башта әнкәй үз-үзенә генә бирә булса кирәк. Язга чыккач, бу сөаль безгә дә ишетелеп-ишетелеп киткәли:

— Фарчит итеп бетерәбез бит инде. Җәйгә тәбикмәклек тә көлчәлек кенә калып бара, берәр әмәлен табарга кирәк булыр...

Келәттәге барлык он тәпәннәрe коргаксып, соңгысының төбендә бернечә тубаллык кына калгач, без исеме җисеменә туры килеп тора торган бернечә генә йортлы Бишкүмәч авылына эпигә йөри башлыйбыз. Мәктәптә укулар менә-менә бетәргә тора. Бу сәфәргә әлегә мәктәпкә йөрми торган кечкенә кызны, мине җибәрергә булалар.

Кояш тәмам колга озынлыгы күтәрелгәч, юлым уңсын, аягым җиңел булсын дип уң аяктан бусагалап, хыял йомгагын өмет белән алдан тәгәрәтеп, шул тәгәри киткән йомгак артыннан юлга чыга кызчык. Карышмакланып булмый инде бу очракта. Акка зәңгәр борчак төшкән кесәле күлмәгендә кульяулыкка төйнәлгән акча, кулда "ситкы".

И, гөнаһсыз сабый бала, серле дөньяның мәңге ачылмас тылсымын сафлыгың, самимилек-садәлегең белән үзеңчә аңларга маташкан күңел күбәләккәең шул тиклем дә ихлас булыр икән! Күпме могҗизалар, кыенлыклар көтә сине...

Алар турында уйламый әле ул балачак урамыннан барганда. Чөнки барча кешеләрне, һәрбер эт һәм песине яхшы белә. Менә күрше эте Юлбарыс койрыгын изәп, хәерле юл теләп калды. Бу түбән очка кадәр шулай. Ул оч балаларын кызчык белми, шуңа күрә билгесезлектән курка. Уйланып бара торгач, мәктәп каршындагы тыкрыкта бер күч баланың бик мавыгып ләпек белән уйнап маташуларын күреп алды. Үзләре бер ил кебек — балачак иле. Сизмәсеннәр дип, мәктәп коймасына ешылып диярлек мыштым гына үтә

Д. Нәүрүзова рәсеме.

башлады. Бу оч балалары бик чаялар. Язын чоңгыл ясап интектерәләр, тез тиентен чумып лычма су буласың. Җәен су кергәндә киемеңә каз боты ясап куялар. Җиләк җыярга барсаң, каршыңа чыгып җиләкләреңне талап алалар. Ак чырайлы, энә йоткан кебек үтә күренмәле юка малайлар, чәбәләнеп беткән чәчле кызлар бәлки сизмәсләр дә иде, тик яннарындагы көчекләрә әйтерсең лә кизү тора — чит кешене ятсынып сөрән салды. Тегеләр, әлбәттә, кызны күреп, якыная башладылар. Кем белә аларның уенда ни барын. Кыз куркып бар булган көченә йөгереп китте.

— Өс-с-с, өс-с-с...

Ачулары чыгып, этне өстерүләре иде бу. Ярый әле аяклары җитез, сандалие да уңайлы, чәпертмә булса йөгерерсең болай. Көчек, җиңәлмәслеген аңлап, шыңшып кире борылды, бик бәләкәй иде шул әле ул.

Кыз сулуы кабып икенче тыкрыкка кереп посты, күзләрен чытырдатып йомды да учлары белән битен томалады, имеш күзен йомса аны күрмиләр...

— Бинахакка беркемне дә рәнҗетмим, мине дә беркем кыерсытмасын иде, — диде ул гаҗизлектән кемгәдер ялварып.

— Бу-у-у беркайчан да-а-а алай булмаяча-а-ак, бу-у-у беркайчан да-а-а алай булмаяча-а-ак, бу-у-у беркайчан да-а-а-а...

Беравык, каяндыр өстән, зират ягыннан җавап кайтавазы яңгырап торгандай булды. Кыз аңына килеп тауга карады. И Ходаем, хәзер курыкмыйча зират турысыннан үтәсе бар инде. Урамнан үтәр иде, каршыда гына явыз Сәгыш бабайлар ихатасы. Күз яшьләре аша ул бермәлгә куркыныч булып калган дөньяга карап торды, әйләнә-тирәдәге һәммә нәрсә күз яшендә йөзә иде. Зират ягына ул көпә-көндез карарга да курка, чөнки анда кызның әтисе җирләнгән. Күптән инде, алты еллап элек. Иртәгә котылгысыз көн, аннан соң котылгысыз төн булган кебек, котылгысыз югалтулар күп бу тормышта. Гомер ахырын белеп булмый диләр, белеп була микән әллә, сырхавы тәмам мантымаслык иткәч, үләренә берничә көн кала, какча, арык тәненең бар җегәрен җыеп, бөтен әйтер сүзен әйтеп, әманәтләрен җиткезеп калдырган.

— Башкалары үсәр инде, аякта басып торалар, кечкенәсе үләр, мөгаен, яши алмас, — дип әйткән.

Иртәгә уянсалар, әтиләре инде дөньяда юк. Ә кызның әле җисмани яшәеше өзелмәгән, әнә, Бишкүмәчкә эпигә барып ята. Әтисен хәтерләми шул, ни чара итәсең. Кеше алдында хәтерләмим дип әйтеп булмый бит инде. Уңайсыз булмасын өчен әбисе өйрәтеп куйды, сорасалар, хәтерлим дибәйт, әрҗәдә ята иде, күзләре йомык иде дибәйт... Ятимлек үзен сиздерә, ул үзен кем алдындадыр гаепле тоя, аны кыенсыну, җәберсенү тойгысы эзәрлекли, билгесез бер хис җанын үксетә иде.

Шулай инде, кешеләр мәңгелеккә китәләр, җаннары булып күбәләкләр очып йөри яки күккә йөрәкләре йолдыз булып атыла... Яисә җырлары кала, чишмәләре кала... Әтисеннән дә чишмә калды. Яңгир чишмәсе. Көтү көткәндә су эчәсе килеп казыган ул аны.

Песи борчагы түшәлгән алабута катыш кычытканнар арасында утыру уңайсыз да бит, нишлисең, алда куркыныч һәм шомлы, бөтен тирә-юньгә яманаты чыгып "фашист" мөһере тагылган Сәгыш бабайлар ихатасын үтәсе бар. Безнең авылда шулай инде, кыскарталар: Галиулла — Галеш, Вәлиулла — Вәлеш, Сәгыйдулла — Сәгыш. Аларның эте бу көчек түгел инде, бозау хәтле. Ниндидер шом иңгән биек капкалар, бер генә ярык та булмаган шундый ук биек коймалар өстеннән өч кат чәнечкеле тимерчыбык сузылган... Аны бик озак "өтермән"дә утырып кайткан дип сөйлиләр. Бала үзенчә, бу чәнечкеле чыбыкларны ул төрмәдән кайтканда алып кайткандыр инде, дип уйлый иде. Кара шом каплап алган бу ихатада ниләр бар икән?

Бервакыт шулай каяндыр кайтып киләләр хатыны белән. Бара-бара да, син миңгерәү, чукынчык нәрсә, хатын-кыз ир-атның сул ягыннан барырга тиеш, дип аты-юлы белән сүгенә башлый. Хатынының бөрешкән сыны җөгереп сул якка чыга, кул алмаштырган арада "тамак ертучы" эздән генә аумый кала. Алга китәләр. Лаякыл исерек тагын киреләнә башлый. Син нәрсә, әпәләвек, аңгыра, ахмак, шуны да белмисең, хатын-кыз ир-атның уң ягыннан барырга тиеш, дип җикеренә. Җәнҗалга күнеккән дәшмәс хатыны җөгерттереп уң якка чыга... һәм кайтып җиткәнче уңлы-суллы йөгерү дәвам итә.

Бөкләнеп, бөгәрләнеп, бөтәрләнеп вә җомарланып, чияләнеп, төенләнеп беткән язмышлы булуы аның шөкәтсез җыерчыклар баскан йөзенә язылган, һәм ул аны беркемгә дә үтүкләтми, эчкән вакытларында да батынкы күзләреннән яшь агызып күңелен нечкәләми иде.

Җәй көннәрендә — басу каравылчысы, кыш көннәрендә силус базы, яисә шуныңише колхоз милкен, малмөлкәтен саклый. Авыл кешеләре аның күләгәсеннән дә куркалар, һәм ул моннан бик канәгать, чөнки авыл мужигы болай уйлый: куркалар, димәк, ихтирам итәләр.

Аны үтереп тә караганнар инде, үлмәгән ул.

Атаклы сыбызгысы бар аның. Шул сыбызгысын сызгырта-сызгырта "Харли-Девидсон" кебегрәк кара мәтаеннан кайнап китә алмаенча интеккән чәйнүк тавышлары чыгарып, басу тирәли әйләнергә дип кузгалуы була, болын һәм кырдагы бөтен кош-киек котлары очып, ду килеп елгага томырылалар. Алай-болай кулына эләксә, кычкыртып, чыелдатып, чырлатып булган бөтен йон һәм каурыйларын йолкып, муенын борып, җир мае эзләүчеләрдән калган чокырга тыгып куя. Шуңа күрә барлык җан ияләренең геннарында бу курку кодланып беткән, бер буыннан икенче буынга ниндидер күренмәс җепләр аша бирелеп бара.

Шулай бермәлне безнең Чибәркәй көтүдән кайтмады. Исле сабын ашаудан гайре бер генә яман ягы да юк иде бахырның, ни булгандыр. Әйтәләр иде аны, утарында малларны җәзаларга сандал һәм станоклары бар икән дип, валлаһи газим, хак икән. Чибәркәйне мөгезеннән арканлап, ал аяклары җиргә тимәслек итеп өскә тарттырган, тар гына бер аратага кертеп кысрыклаган. Бу аратаның як-ягыннан меңәрләгән вак кадаклар чыгып тора. Ора гына бу безнең Чибәркәйгә камчы белән. Чибәркәебез кычкыра да алмый, авызлык кидертелгән, ух-ух ухылдый гына. Ян-якка талпына да алмый, бизгәк тоткан шикелле дердер килә, җитмәсә аягы да икәү генә. Камчы өскә

күтәрелгән арада күзен акайтып карарга өлгерә дә, үркәчләренә "кәнчил койрыгы" килеп төшкәндә сыртын бераз бөкрәйтеп, авыртуны җиңеләйтү өчен күзен йомып, әзер булып тора.

— Денсез, дога белән көнең башланса болай кыланмасиең, миһербансыз, үтерүче булып үләсең үзең дә, үтермә малкайны, — әнкәйнең бу сүзләренә колак та салмады. Үзеннән курыкмаган кешеләрне гафу итә алмый иде ул. Ач һәм явыз кеше кебек, ябагалары коелып беткәнче тунады Чибәркәйне. Чыбыркы сабына җәпләнеп беткән моның кулы, яраткан эше, күренеп тора. Инде яраларга пес итәсе генә калды. Бернәрсәдән дә чирканмый бит ул. Үзе кешелексез, авылдашларының да кешелеген таптап тәм таба. Әхлак законнарын бозган кеше кешечә яши алмый, бәхетсез була. Моңа тәгаен эт үлеме биреләчәк иде.

Гомеренең күп өлешен 40 градуслы булып йөреп үткәргенлектән, бер ярты тоттыргач, өстәвенә "монау потлы бидрә белән он алып килергә" дип боерып, әмере үтәлгәч кенә җибәрде малкайны.

Шулай итеп ул елны без бозаусыз калдык. Чибәркәебез гелән туры өйгә кайта торган булды, геннарында курку коды ныклап урнашкан, ул гына да түгел, бу хәлләрдән соңгы елларда туган бозаулар да туры өйгә кайта торган булдылар. Бахыркай, мөгезендә боҗралары күбәеп, картаеп киткәндәй булды.

Уйларны бүлеп, авыл ягыннан ниндидер зынҗырларын, чыгырларын шалтыратып Шиһабетдин абыйның "бет-бетик" тракторы тавышы ишетелде. Алабуталар чорнамышында сөмсерен коеп утырган кыз сикереп торды. Форсаттан файдаланып, трактор белән янәшә йөгереп авыл башына чыкты. Менә авылның соңгы йорты. Мондый нык йортлар авылда дүртәү генә. Бу — әтисенең энесе Самат абыйлар ихатасы. Гөлбакча эчендә дә иске җыруын җырлап утыручы йөзьяшәр имәннән мунча кебек кенә бер йорт булып, аны үзеннән дә кечкенә умарталар боҗралап алган иде. Самат абый туган йортларын истәлек итеп саклый, аны сүтеп атарга кулы да күтәрелми, намусы да кушмый. Узган гасыр йорты алдындагы сиреньнәр, нәкъ шул вакыттагы кебек, әллә кайчан тиеп киткән җилдән булган талпынуларын кабатлап чайкалалар. Алмагачлар, чияләр туй күлмәге киеп алган. Бал кортларына эш күп монда, тимәсләр кызыйга. Таш йорт тәрәзәсеннән бал малае белән бал кызы карап тора, әти-әниләре эшкә киткәндә бикләп киткәннәр. Әхмәт бабасы исән булса, бал бабай булган булыр иде. Бабай да, әби дә яшисен яшәп, соңгы тамчысына кадәр кайнап беткәч, үлемнән курыкмыйча гына, зиратта уллары Яңгир янына алдан урын сайлап куеп, шуннан соң гына дөньядан киттеләр. Кызчык аларның кайчандыр күмер булып та, инде көле генә калган күзләренең нидер сиземләгән, нидер чамалаган кебек аңа озак карап торганнарын хәтерли әле.

Ниһаять, авылдан чыгылды, ярты киенлык узды дигән сүз. Яртысы гына әле. Инде бераз яшел чирәмнән җәяүләргә кирәк. Сикерә-сикерә чәчәкләр җыеп, күбәләкләр белән куышып бар да бар үзеңнең әкияти юлың белән. Туктале... Соң бу әкияти җәтмә генә бит. Чирәм арасыннан тагын бер курку шытып чыкты. Алда озынлыгы әллә ничәмә чакрымга сузылган, тирә-якта дан тоткан тирән чокыр — Марҗа чокырын үтәсе бар иде. Төбенә төшеп э-э-эһә-э-һә-эи-и-и дип бар тавышка ярсаң, унарча мәртәбә кабатлый. Тирәнгә күрә, тиз генә җылынып җитә алмый, иртәнчәк, көтү белән чыкканда эче сөт тутырган сыман томан була. Сөйләкләргә караганда, имештер ки бу чокырның "таш идән" дигән җирендә кечкенә генә йорты белән бер марҗа яшәгән. Ниндидер "ак"лар килгәч, аны үтергәннәр.

"Таш идән"дә катлам-катлам хәлвәдәй, дәверләр бастырыкланган. Борынгы серле төпкел серхәзинәләрен тирән яшергән...

Җәйләрен җиләк күп була анда, куяннар сукмагыннан барып, аулак яланнарга килеп чыксаң, күз ачып йомганчы бер чиләк җыясың да җыясың инде. Бигрәк тә яр асларыннан. Иллә да яраталар инде качып калырга!

Җиләген җиләк тә, ничек итеп төшеп менәсе инде аргы якка. Чокырга төшкәч, авыл күренми, шуңа күрә бик шөлләтә. Ничек инде туган авылың күренмәгәч курыкмыйсың ди. Җитмәсә түр башында ялгыш кына эреми калган ала томан кисәге шикләндереп тора. Кыям абыйларның буаз сыерлары шул кыядан егылып төшеп үлде инде.

Күптән түгел монда билдән су ташыган, әнә юл өзек чакларның эзләре...

Ярый, ничек кенә булмасын, тизрәк үтеп чыгарга кирәк. Берүзем генә түгел бит әле, күләгәм үзем белән дип юанып, күләгәсенең кулыннан чытырдатып тотты. Соңгы тапкыр авылына карап алды да, атылып төшеп китте. Тез буыннары тотмый иде. Яр читендә чак-чак кына эләгеп торган кәсләр тузаннар туздырып аска мәтәлде. Кызны да узып аяк асларында вак ташлар тәгәрәде. Салкын чокыр төбендә эреми калган тоҗымнарны өзеп, кыр кәҗәсе кебек дүңгәләктәндүңгәләккә сикереп инешне чыкты да, бар калган көченә өскә томырылды. Менә... менә хәзер менеп җитәчәк... Ярдагы бер учма куе үләнгә ябышты да тез күмәчләре белән мүкәйләп менеп, сулуы кабып чирәмгә ауды. Ташлар тәгәрәп төшкән тавыш кайтавазлары әле дә булса кабатлана иде.

Авыл күренеп тора, курыкмасаң да була, тик эчәсе генә килә менә. Җиргә яткан көйгә колак салып тыңлап карый, чишмә тавышы ишетелә. Тагын ниндидер гүләү, безелдәү... Ниндидер кош аңа исеме белән эндәшеп кычкырган төсле. Монда гомер бакый сандугачлар яшәгән кый... Бу чишмәдән гомер бакый шул сандугачлар тезелеп су эчкән. Кырмыскаларның, черкиләрнең, һәрнәрсәнең үз урыны бар... Бакчый, гөлчәчәкләр исе төяп җилләр исеп уйный, күбәләкләр шатлыгын кая куярга белмичә әле андагы чәчәкләргә килеп чүгәли дә кыңгырауларны шалтырата, әле баш төртергә өлгергән гөмбә калфакларына ятып ял итә. Шатлык өстәп йөреп ярты көндә җык булганнар инде болар. Бу күренешләрне хиссият белән күзәтеп, көнеңне монда үткәрсәң, төнен төшләрең төсле була инде.

Туктале, бу күбәләкләр чыннан да кеше җаннары микәнни?

Беркем юк, аулак бу көндә чәчәкләрнең күзләренә

карап аларга сүз кушасы килә:

— Нишләп сез елдан-ел әзәясез, чәчәкләр?

— Без кешеләрнең яулыкларына, күлмәкләренә күчәбез. Моңа сез гаепле. Никадәр күбрәк һәм зуррак чәчәкле кием кисәгез, болын-кырларда, урман-куаклыкларда, елга-күл буйларында чәчәкләр дә шул кадәр әзәя бара. Элгәре бертөрле төстәге, борчаклы, сызыклы, буйлы күлмәкләр киеп йөриләр иде. Шуңа күрә без дә күбрәк идек. Кеше өсләренә күчтек без... Ахырзаман якынлаша, ахрысы, ахырзаман, — дип ах-ух килделәр зарланышып яшьле чәчәк күзләре. Ул саф чыкларда зәңгәр күк йөзе чагыла иде хәтта.

Кыз, үзен аклагандай, акка зәңгәр борчак төшкән кесәле күлмәген сыпырып куйды, һәм аларга беркайчан да чәчәкле күлмәк кимәскә сүз биреп ары атлады.

Күккә ник бүрек хәтле булса да болыт эленсен. Сүндерсә бу сусауны Бишкүмәчнең чылбырлы коесындагы кәүсәр суы гына сүндерә инде. Ярый әле бидрәдә су калган, бала-чага әйләндерә торган чыгыр түгел бу. Су тешне камаштырырлык суык иде.

Зурмы дисәң, зур да түгел, кечкенә авыл Бишкүмәч. Шүрәле каргаган аны. Беренче йорт — Әхәт бабайлар йорты. Бу әзмәвер бер карт булып, кызга ул корт чагып шулай шешенгән кебек тоела иде. Чал чәчле, кырку ак сакаллы, кәләпүшле-камзуллы, озын ак "пыша" күлмәк вә кара шараварлы. Түгәрәк кузлеген, колагына менеп атланып та тик утыра алмаганлыктан, җилем бау белән дилбегәләгән. Биш вакыт намазын калдырмый, чиртсәң акыл коела торган бик зирәк карт иде бу. Имән кабыгыннан эшләнгән биек коймалар, анда кәүсә урыннарында йомры тишекләр бар. Ләкин тишекләрдән карармын димә. Койма артында чебен очып керсә дә ажгырып өрә торган эт. Акка кара тимгелләр төшкән нәселле эт. Каян килеп чыккан да, ничек килеп капкан ул монда? Андый эт бүтән берәүдә дә юк.

Ә бакчалары, ә бакчалары... Гади бакча түгел, гөлстан! Аларның чәчәкләре — кичен күзен йомып, иртән керфекләрен ача торган серле чәчәкләр. Биредә ишек алдындагы бәбкә үләннәре дә куерак, биегрәк, сары таҗсыз чәчәкләр дә эрерәк иде. Таптап, җончытып бетерергә балалары юк шул.

Бал кортлары да үзгә, сәрби куакларында һәрберсе үз җырын җырлап, чәчәкләрдәге баллы сыекчаны имеп утыралар. Алар шулай алдыйлар гына. Кешенең якынрак килгәнен көтеп утыралар, аннан дәррәү ташланырга дип. Чәчәкләрнең шифалы суларга туенып килгән чагы, берәү дә борчып йөрмәсә, гел шулай имеп утырсалар, уңа инде боларның баллары!

Әйтәләр бит, эт яки мәче төскә-биткә хуҗасының үзен хәтерләтә башлый дип, бал кортлары да һәммәсе Әхәт бабай кебек "эре сөякле". Аның кебек түгәрәк күзлекле дә түгелме икән әле.

Алга таба терәүле, салам түбәтәйле кәрлә йортлар китә, алардан әбиләр таягы шикеллерәк кәкре нәрсәләр тырпаеп тора... Аркау киртәләре яңгырдан бүртеп ярылган, буй каккан казыклары җирдән дым алып үсеп киткән, ишек аллары...

Менә бусы кибетче Вәсилә апалар өе, димәк, чапырыш кибет була. Аллага шөкер, ачык. Эпи "кайткан", шуңа күрә кибет яңы чәчәк аткан: җете чәчәкләр төшерелгән яулыклы апалар муенса төймәләре кебек чират торалар. Кыз песи адымнары белән генә килеп шул муенса җебен төенләде. Кибет кечкенә, янып торган шәрә лампочканың җегәре җитмәү сәбәпле, ишек каерып ачылган, тимер колакларында, пар алка сыман, потлы амбар йозаклары эленеп тора. Чит авыл кешесен тиз сизделәр. Күз бәбәгенә ак тап төшкән апа белән кипкән аякларына кызыл эчле эрҗинкә элгән апа, тәртешеп, нидер пышылдашып алдылар. Әлбәттә, читятларга бирә башласалар, үз авылларына җитми кала. Бер башка ике "кирбеч" исәбеннән кайта бит ул. Инде килгән-килгән буш борып җибәрмиләр, бер буханка бирәләр анысы.

Кибеттә тагын Кубадан кайтартылган, үтә дә каты, төрле калынлыктагы камыш шикәре, шүрлектә каплы тоз, парлы чәй җамыягы сурәте төшерелгән, ян-яклары җылтырыйклы такта чәй, чеби ярмасы, тагынниләрдер... Бик сирәк булса да кайвакыт "барбарис", өстенә мармалаттан чәчәк ясалган ширбәт тә булыштыра иде. Бүрәнәдәге чөйдә әкәмәт зур бизмән асылынып тора. Астарак тутыккан кадакка бер көлтә ачкыч эленгән иде.

Кибетче Вәсилә апаның күз тирәсендә яра эзләре. Алар елмаюдан хасил булган җыерчыклар кебегрәк булганга, аны тагын да сөйкемлерәк итә, ә күзләре ниндидер нурлы җылылык бөркеп торалар. Җәһәтҗәһәт хәрәкәтләр белән кешеләргә шатлык өләшә, шуңа чират тиз эри. Колагындагы энҗеле зәркан алкалар аның әз генә булган хәрәкәтен дә, хәтта күз йомганын да сизгер кабатлап баралар. Күңеленә ниндидер йомшаклык иңгән аның, изге кешеләр кебек, беркайчан да тавышын күтәрмәс, әйтәсе килгәнен мәгънә тулы күз карашы белән аңлатып бирер. Мөлаем-сагышлы йөзе, нәзакәтле елмаюы, хәрәкәтләренең нәфислеге — барысы да шәһәр кешесе икәнен раслый. Тикмәгә генә кайтканмы ул Ташкентын ташлап? Имештер ки анда бик каты җир тетрәү булган, көчкә исән калганнар, яра эзләре дә шуннан икән. Ә олы кызы шуннан соң тотлыга торган булып калган.

Кибетнең хуҗабикәсе булу бик килешә Вәсилә апага. Аның җылы күз карашына җавап итеп кыз каушаудан, күз тимәсенгә куш чикләвек тагылган нәзек беләзеге кәгазь акча да күтәрәлмәс хәлгә җитеп:

— Әнкәй ишшугы бер эпи диде, — дигән сүзләрне пышылдап, акчаларны чут төймәләре янына этеп-этеп куйды. Хәер, монда артык сүз кирәк микән? Вәсилә апа әнисенең якын дусты, әхвәлләрен болай да яхшы белә. Чираттагы авылдашларының без кебек үткен карашларын күтәреп, "ситкы"га ике эпи сала. Беравык кибет эче тынып тора.

— Үз өлешемне бирәм, көяләнмәгез, барыгызга да җитәрлек, — дип чират халкын юата да, кызга карап өсти:

— Әниеңә сәлам әйт, акыллым, исән-сау кайтып җит, — ди, һәм әле башыннан да сыйпап кала.

Кыз рәхмәт әйтеп кибеттән чыга. Вәсилә апа сата торган кибет эпие шулай ук бик тәмле, хуш исле, күпереп пешкән. Әйтерсең лә аны совхоз пекарнясында эшләүчеләр түгел, ә Вәсилә апа үзе пешергән.

Хәзер инде исән-имин авылга кайтып җитәсе генә

кала. Күңеләнә, исәр Имам яки исәр Мосаллия гына очрый күрмәсен инде, дигән шик иңде. Авылдан авылга күчеп, сәләмә киенеп, чыпта бөркәнеп, җилкәләренә таяк белән төенчек асып, билләрен путалаган киндерә бауга, утырып ял итәр өчен купчек кыстырып, кешедә тамак туйдырып йөрүче ике сәер зат бар иде бу якларда. Акыл, зиһен ягыннан зәгыйфь булсалар да, алай зыян салганнары юк. Шулай да бала-чага уттан курыккандай курка үзләреннән. Бала кирәмәтләнсә, зурлар, әнә исәр Имамга биреп җибәрәм, яисә исәр Мосаллия алып китә үзеңне, дип куркытып җүнгә китерәләр.

Уйлана-уйлана Марҗа чокырына якынлашканда, төркем-төркем булып Олыймән авылы балаларының укудан кайтулары күренде. Шатланыплар китте кыз, куркыныч булмаячак хәзер. Олыймән балалары үзара дус, бердәм һәм берәгәйле, чөнки аларны авырлык берләштерә. Көн саен ничәмә чакрым җәяү йөрү аларны чыныктырып бетергән. Тормыш авыр боларга, һәм тагын да авыррак булачак әле, ләкин тиз генә бирешмәсләр болар.

Кыз беренче тапкыр җиңел сулап, кояшны эзләгәндәй күккә карады. Аллага рәхмәт әйтергә теләде. Кояш юк иде инде. Күктә тик шушы Олыймән балаларына охшаш көтү-көтү болытлар, ә еракта-еракта, Сикия кырыстаны ягында, бишни кара түсендәге укмашкан, очсыз-кырыйсыз кургашын тимгелле болытның арт ягы җиргә сеңгән иде. Ну ора гына Сикиядә яңгыр!

Ничек булса да кайтып җитешергә кирәк. Ул теректерек атлап, яраткан догасы "миншарл вәсуасуфисудуриннәс"не укый-укый, турылатып, ындыр артлатып кына элдертте. Инде барлык кыенлыклар да бу яшенле яңгыр алдында чүп кебек кенә тоела башлады. Яуса яусын инде анысы, тик дөбердәмәсен дә яшенләмәсен генә. Имеш, яшенле яңгыр һаваны чистарта, болай да бик саф бит әле ул... Йөрәктәге куркуы умырылып калганчы йөгерде дә йөгерде. Менә амбарчы Кашап абыйларның ындыр артына җитте, анда җәйге саклауга тәртәләре өскә күтәртеп бәйләнгән кышкы "кашауай", әйтерсең лә ядрә аткыч кебек, көшел-көшел болытларга төбәлгән иде.

Гел турылайтып кына булмый шул, башсыз шайтан таяклары тырпаеп торган чокыр-чакырларны әйләнеп үтәргә кирәк. Боларның башларын көтүче чыбыркысы кыеп төшергән инде. Шул кирәк аларга, үсмәсеннәр, кяферләр.

Күп калмады, димәк, мәктәптә дәресләр беткән, апалары кайтышка төгәл өлгерә. Ул җык булып алҗып, капканы ачып ишек алдына үткәндә, әтисе җиде кызына атап утыртып калдырган чәерле тупыллар, яңгыр алдыннан гына була торган җиләс җилдә җилбердәшеп, аны мактагандай каршы алдылар. Кызчыкның вак-вак җиңүләре кебек, бер кәррә яңгыр тамчысы аның битенә килеп тамды. Еламый иде ул.

Ике эпекәен кочаклап, иңнәрендә нинди‌дер өрфиядәй канатлар тоеп, баскычтан атлап менде:

бер,

ике,

өч.

Кайттыңмы, дигәндәй ишек күгәне сузып сәламләде. Озын, озак көн булды бу. Иртәдән кичкә кадәр.

Су башы

Камил Кәримов,
1983-88 елларда "Идел" альманахының җаваплы редакторы

Без — "Идел" малайлары

Ә беләсезме, "Идел" альманахының җаваплы редакторлары тәмәке тартмый торган кешеләр булган. Фәрваз Миңнуллин Язучылар берлегенә эшкә чакыргач, үземне "Идел" альманахына куячакларын белдем, чөнки мин тәмәке тартмый идем.

Ул елларда "Идел"дә берәр әсәрең чыкса, үзеңне язучы дип исәпли ала идең. Минем дә Фаил Шәфигуллин чорында "Мәхәббәт чокыры" дигән хикәям чыкты. Аннан, исемемне күтәрер өчен "Кыңгыр эш" дигән повестем басылды — монысын Мансур Вәлиев редакцияләде. "Идел"гә һәр кульязма сигез катлы фильтр аша үтә иде. Әйтик, хикәяне иҗат секциясе тәкъдим итә, син редакциялисең, аннан соң яшь авторлар белән эшләү бүлеге мөдире (ул, гадәттә, гел Илдар Юзеев була торган иде) раслый. Альманах тупланып беткәч, ике кат өскә менәсең — нәшрият редакторы Таһир Нурмөхәммәт күтә, ә ул өтер куелышларына чаклы җентекләп сүгенә-сүгенә укып чыга. Шуннан соң нәшрият директоры кул куя... Ниһаять, бер ел үтте дигәндә, "Идел" альманахы дөньяга чыга...

Мин гаиләдә төпчек бала. "Идел" альманахының да төпчек редакторы булдым... Дөрес, соңгы ике елым Язучылар берлеген яңа бинага күчерү мәшәкате белән үтеп китте. Яшь язучылардан җыелган әсәрләрне тиз генә редакцияләп чыгам да түбә калае сүтәм, траншеялар казыйм, җылыткыч торбаларны пыяла мамыгына төрәм, "Яңа бина" подвалыннан 1937 еллардан калган чүпләрне түгәм, тәрәз каршындагы бакчага сыерчык оялары элә...

Кыскасы, туачак "Идел" журналына бишек әзерләү иде инде бу...

Идел һаман ага

Хәзерге яшьләр, бу журнал мәңге булган, җир-су, Идел елгасы белән бергә яратылган, дип уйлый. Алар журналның кайчандыр булмавын күз алдына китерә алмый. Ә бит 10 ел элек кенә «Идел» журналы юк иде. Ышанасызмы? Коточкыч хәл бит.

Хәер, бүген татарча басмалар бихисап. Һәр фикер, милли тормыш авазлары бүген беркемне дә гаҗәпләндерми. 1989 ел башында хәл бөтенләй башкача иде. Сәясәтчеләр, депутатлар, язучылар милләт турында мәгълүмат чаралары аша сакланып кына булса да әйткәли башладылар. Әмма «Идел» журналы барыбер үзгәрәк, кадерлерәк, газизрәк булып искә төшә.

«Идел»дән башка Казанны, Татарстанны, аның мөстәкыйльлеген, гомумән татар дөньясын күз алдына китерү кыен. Бервакыт мин Идел елгасы бөтенләй булмаса, нинди хәл килеп тууын сурәтләгән идем. Мондый әкәмәтне, фаҗигале әкиятне фаразлау да чәчләрне үрә бастыра:

«...Көннәрдән бер көнне елга юкка чыга. Идел буена су эчәргә төшкән тайлар аптырашта кала: нинди кыямәт бу?

Комлы сазлыкта теплоходлар, метеорлар ауный. Каюталарга кыргый мәчеләр, этләр кереп оялаган. Матрослар авыл урамнарында шлюпка-компас кебек җиһазлар саталар. Әмма тельняшкадан гайре нәрсәгә ихтирам юк. Малай-шалай гына ярты дистә йомыркага штурвал тәгәрмәчен алмаштырырга риза.

Җирән сакаллы капитан, тутыккан маякка утырып, анархистлар партиясенә гариза яза. Неформаллар аны мактап доклад сөйли һәм кул чаба. Ятьмәләр, эреле-ваклы балык үләксәләре, ватык шешә, тимер вә пластмасса сыныклары буталып, таудай өелеп ята. Яшьрәк, гайрәтлерәк җәеннәр, баканыкы кебек нечкә генә өчдүрт аяк үстереп, берәр буага яки күлгә таба сикереп качарга телиләр. Алабугалар кәлтә булып шуышырга өйрәнә, чабаклар канат чыгарып очып карый. Бер төркем боцман мелиораторлар әзерли торган СПТУга китеп бара. Гидростанцияләр тыптын калган, электр лампалары янмый. Эпидемия куркынычы җанны өшетә.

Бер исерек бәндә Идел дулкыннары турында җыр суза, аның авызына берне тондырырга кешесе юк, күпчелек караеп катып өнсез калган...»

«Идел» журналы булмаса, шундый ук рухи фаҗига килеп чыгар иде. Шуңа ишарә ясаган әлеге фантастик сурәтләмәне мин 1991 елның 7 санына кертелгән баш мәкаләдә язган-

Римзил ВӘЛИ



мын. Баш мөхәррир үзенең чираттагы хакими нотыгында шундый әкәмәтләр сөйләгәч, нинди заман, «Идел» журналы редакциясенең ниндирәк булганын үзегез күзаллагыз.

Әйе, ул чакта «Идел»челәрнең дәрте, хыялы чиксез һәм йөгәнсез булган. Үземә хәзер бераз акыл кергәнен сизәм. Бүген баш мөхәррир булсам, баш мәкаләмә андый котыргап сурәтләр кертмәс идем. Гомумән, хәзер мин «Идел» журналының беренче санын яңадан чыгара алмас идем.

Нишлисең, хәзер инде безнең ише агай-энегә ветеран бабайлар кебек, мәктәп балаларына хатирәләр сөйләп, муенга алардан галстуклар бәйләтеп, беткән көч, үткән заманнар турында риваятьләр чыгарып йөрергә кала. Шулай да, «Идел» ничек башланды соң?

1989 елда «Идел» журналы ачылу милләтебезнең, зыялыларыбызның зур җиңүе булды. Ул бик озак барган көрәшнең нәтиҗәсе иде. Яшьләр журналы ачу турында Мәскәүгә хат язулар, зур җыелышларда ясалган кыю чыгышлар эзсез калмаган. 1988 ел ахырында өлкә партия конференциясенә КПСС ҮК секретаре В.Медведев Горбачев хакимиятенең татарларга уңай мөнәсәбәтен күрсәтүче «күчтәнәч» алып килде. КПСС ҮК Секретариатының Казанда яшьләр журналын ачарга рөхсәт итүе турында карары иде ул. Гадәттә мондый карарга яңа оешманың штатлары, сметасы беркетелә. Ә мәгълүм күчтәнәчтә «Идел» журналын ачарга рөхсәттән башка бер нәрсә дә юк иде. Ярты ел үткәч, 1989 елның җәендә, яңа газитләр-журналлар ачу хокукы барлык өлкә, республика хакимиятләренә бирелде. Шулай итеп, «Идел» журналын Татарстан җәмәгатьчелеге, республика җитәкчеләре ачты. Мәскәү түгел, Казан ачты безнең бу журналыбызны. Үзебез ачтык.

Элекке заманаларны сагынучылар шуны белсен: татарлар озак еллар буе бер ишекне шакып та, аны адәмчә ачучы табылмаган, шушы бер мәсьәлә уңай хәл ителмәгән. Ә инде соңгы 10 ел эчендә булган үзгәрешләр, элек башка да сыймаган милли гамәлләр хәзер табигый булып күренә. Татарстанның дәүләт әләме, туграсы бар. Үзебезчә кануннар чыгару, сәясәтчеләребезнең Мәскәүләргә барып олы агайларга акыл өйрәтүе, чит илләр белән турыдан-туры сәүдә итү элек матур хыял иде бит. Ә хәзер бу — гадәти күренеш. Казаннан туп-туры Истанбулга, Франкфуртка, Тель-Авивка, Гарәп илләренә очу табигый хәл. Кыска дулкынлы татар радиосы бар — рәхим ит, тыңла. Ул вакытта компьютер татарча сөйләшер дип уйлаган кеше юк иде. Интернет дигән нәрсә безнең өчен бөтенләй тумаган иде ул чакта.

«Идел» журналы республикабызның һәм милләтебезнең тарихи борылышы көннәрендә туды. Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе Туфан Миңнулин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Ринат Харис, галим Азат Әхмәдуллин, Татарстан комсомолының беренче секретаре Морат Гаделшин һәм башкалар җыелып баш мөхәррир сайладылар.

Конкурс каты булды. Анда катнашуымның сәбәбе — курку. Яшь язучыларның бик шәп «Идел» альманахы бар иде. Әмма журнал әдәби альманах түгел. Мин дә алынмасам, чын заманча журнал чыгара башламаслар дип курыктым. Литва, Латвия, Эстониядә «перестройка» рухындагы кыю, алдынгы әдәби-сәяси журналлар ул чакта бөтен СССРга яңгырады. Минем дә милли әдәбиятны

көчле журналистика, яңа документалистикага бәйлисем килде. Иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис сурәтле яшьләр журналы милләт язмышын хәл итү коралы иде ул чакта. Чөнки тәрәккыятнең куәте, тартучысы — алдынгы фикерле яшьләр. Алардан башка милләтчелекне дә, милләтне дә күз алдына китереп булмый.

Ни булса булды, 1989 елның 4 мартында Татарстан Язучылар берлегенең өр-яңа бинасына җыелдык. Буяу исе аңкып торган буш бүлмәгә каяндыр урындыклар табып түгәрәкләнеп утырдык. Редакциягә Язучылар берлеге тәкъдим иткән яисә үзем белгән кешеләр чакырылды. Иң талантлы, иң көчле, дәртле һәм усал егетләр, кызлар читтә калмаска тиеш иде. Беренче «планеркада» кемнең нинди бүлектә эшләячәген ачыкладык. Һәр санның яртысы проза-поэзиягә, яртысы публицистикага бирелүе, әсәрләрнең 50 процентлабы русчадан татарчага яки татарчадан русчага тәрҗемә ителүе шул көннәрдә хәл ителде. Бизәлеш, тышлык рәсеме, төсләр дизайны, кәгазь, формат — болар барсы да билгесез иде.

Буш бүлмәдә ярым аяк өсте үткәрелгән утырышта кемнәр булды? Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Нәбирә Гыйматдинова, Әхәт Мушинский, Майя Валеева, Роза Кожевникова — тагын кем булды икән? Мәскәүдә укучы, шул көннәрдә каникулга кайткан Фәиз Зөлкарнәйне әдәби тәнкыйть бүлегенә чакырып алдым. Штат буенча баш мөхәррирнең бер генә урынбасар тәгаенләнсә дә, урыс чыгарылышы белән шөгыльләнүче Әхәт Мушинскийдан башка, татар әдәбияты буенча «зам» статусын Фәизгә бирдек. Ул яңадан укырга китеп тормады, бераз соңрак диплом якларга гына Мәскәүгә барып кайтты. Фаяз Фәезов, Гадел Хәеров, Динара Бикбова урыс журналында эшли башладылар. Хатлар бүлеге мөдире Гөлшат Салихҗанова, татар чыгарылышы корректоры булып Алсу Садыйкова эшләде. Рәссам Алсу Тимергалина, фотохәбәрче Рөстәм Мөхәммәтҗанов — һәркайсы үзенчәлекле шәхесләр. Фәнни институтта диссертация язып ятучы Гөлсирә Гайнанова безгә машинистка булып килде. Һәм шул заманнан «Идел»дән китә алмады, хәзер хатлар бүлеген җитәкли.

Минемчә, «Идел»челәрнең беренче командасы шул замандагы иң сәләтле һәм фидакяр яшьләрдән тора иде. Төрле фикерле, төрле яктан булдырган шәхесләр иде алар.

«Татарстан яшьләре»ннән Исмәгыйль Шәрәфине яңа гүзәл журнал ясау идеясе белән кызыктырып, «Идел»нең беренче җаваплы сәркатибе итүләр, Рүзәл Әхмәтҗановның икътисад буенча ярдәмче булып китүе, нәшриятта эшләүче Гәүһәрия ханым Кәримуллинаның типографиядә генә түгел, җәһәннәмдәге кәгазь комбинатлары аша да ярдәм итүе...

Нинди генә хәлләр булмады! Секретариатта журналның макетын төзүгә мәрхүм Рөстәм Халитов алынды. Камал театрында туып үскән (мәшһүр артист Фоат Халитов улы) бу гаҗәеп кеше үзенең соңгы елларын безнең арада үткәрде. Нәкъ шул чорда аның иҗади мөмкинлекләре ачылды, «Идел» аның тормышы өчен рухи күтәрелеш булды. Бу минем сүзләр генә түгел. Рөстәм Хәлитов дәваланмый торган хасталыктан вафат булгач, Казанның татар зиратында Марсель Сәлимҗанов әйткән сүзләр бу.

Хәтерлим, филармониядән бер яшь җырчы безгә эшкә килде. Үз сүзләренә заманча җырлар яза, гитарада уйный. Аны яшьләр бүлегенә куеп, комсомол, сәясәт темаларына батырырга тырыштым. Әмма әйбәт кенә юмористик хикәяләр яза башлаган бу егет сәясәт шау-шуын өнәмәде. Кызу иде, кызык иде, талантлы иде, каһәрең. Андый билгесез даһилар безнең тирәдә күп булды. Ә монысы хәзер билгеле инде — язучы, композитор, җырчы Зөлфәт Хәким. Әнә киштәмдә аның өчтомлыгы тора. Лазер тәлинкәләре, кассеталары дөньяга таралган. Аның Карл Маркс урамындагы элеккеге комсомол өлкә комитетыннан бушаган бинаның бер кечкенә бүлмәсендә раскладушкага утырып миңа нәрсәдер укыганын, сөйләгәнен хәтерлим. Хәтта ял көннәрендә килеп акыл өйрәтеп китә идем. Нибары ун ел үткән...

Бер вакыйга истә калган. Татарстан журналистлар берлеге пленумы ачылыр алдыннан, газет-журнал нәшрияты каршында пикет үткәрелде. «Идел» — рассадник татарского национализма», «Не согласны с редакционной политикой гл.редактора Р.Валеева» дигән плакатлар күтәреп биш-алты кеше йөзләрчә журналист алдында мегафон аша кычкырып торды. «Идел»нең рус чыгарылышы тирәсендә йөрүче яшь язучылар иделәр алар. Кемдер аларны котырткан, куркыткан ахры. Бу — Татарстанда оештырылган иң беренче сәяси пикетларның берсе булгандыр. Мине эштән алдырыр өчен «рус» төркеме сәяси эш ташлау белән янады. Шулай да коллектив тынычланды, «Идел»нең милли кыйбласы үзгәрмәде. Шул вакытта Рөстәм Халитов, кесәсенә үзе ясаган пәке салып, урам почмагында озаклап басып тора башлаган. «Идел»гә һөҗүм иткән фетнәчеләрне ул үзенчә туктатырга булган. Үземне саклап «салкын корал» тотып урамга чыккан кешене моңа кадәр дә, аннан соң да күргәнем булмады. Күрергә дә язмасын. Шул вакытта Рөстәмнең пәкесен тартып-сорап алган идем. Әле дә саклыйм аны. Шунысы кызык, журналыбызның рус чыгарылышында эшләп шушы пикетны оештыручыларның кайберләре хәзер гаҗәеп татар милләтчесенә әверелделәр!

Бәлки «Идел» журналының тулы тарихын язарга, музеен булдырырга кирәктер?

Тагы нәрсәләр истә калган? «Идел»нең икенче елында ук тиражыбыз 120 меңнән артып китте. 40 тиенлек журнал сатып, без үзебез тапкан акчага яши башладык. «Идел» лагеренда үткәрелгән иң беренче татар яшьләре көннәренә спонсор булдык. Белоруссиядә яшәүче татарларга бер пар бию костюмы тектереп бирдек. Узган ел Минскига баргач, безнең яныбызга килеп, бу турыда искә алдылар. Яшьләр бит төрле сәяхәтләр, культпоходлар ярата. Редакция хезмәткәрләре очкычка утырып дүрт-биш көнгә Кишиневка, Одессага сәяхәткә барып кайттылар. Иҗади һәм сәяси программадан гайре менә шундый хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгәнгә күрә, мин бу турыда һич оныта алмыйм. Һәр санны чыгарыр өчен 18 тонна кәгазь кайтара идек. Ничек лимитын тапканбыз да, ничек акчасын җиткергәнбез, белмим. Шуны беләм, без СССРда иң беренче мөстәкыйль эшли торган, ягъни бернинди башка нәшрият балансына кермәгән редакция идек. Чөнки без редакция уставы язганда, кече ширкәт буларак банкта хисап ачканда беркайда да моңа охшаш басма булмавы беленде.

Беренче сан чыгу куанычы. Бу чын бәхет иде. Журнал чыккач, кайдан-

дыр катер табып, Идел буена ял итәргә чыгып кердек. Яр буена туктап учак яктык. Шәхси архивымда табылган шушы рәсемдә беренче иделчеләрнең күпчелеге. Көймәнең иң алдагы ноктасында икенче баш мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй. Хәзер инде ул мәрхүм. Рәсемдә ул очарга җыенган кош сыман уйланып тора. Күрәсең язмыш үзе аны «Идел» чыккан чорда безнең арабызга җибәреп, үзе үк кире тартып алгандыр.

Әлбәттә, журналның йөзен иң беренче чиратта әдәби хезмәткәрләр һәм әсәрләрнең авторлары билгели. 10 ел эчендә «Идел» күпме хикәя, повесть, шигырь, поэма, күпме мәкалә бастырып чыгарган. Аларны сайлау, кульязма битләреннән җәүһәр эзләү, талантка бәя бирү... Бу язмамда әсәрләр, авторлары турында сүз куертмыйм. Миңа «Идел»дә күбрәк сәясәт, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнергә туры килде. Нәбирәне, Ркаилне, Газинурны, Розаны, Фәизне язарга өйрәтү кирәкми иде. Аларга ирек бирүем белән горурланам. Бәлки аларны кыздырган, чыбыркылаган чаклар да булгандыр. Тәртип урнаштырганда мине дә сүгүчеләр булгандыр. Үзем белмим, хәтерләмим аларын. Ул чакларда чишмәләр дә тәмлерәк, су да юешрәк, шәфәкъләр дә матуррак иде шул. Үземә рухи яктан якын кешеләрнең әсәрләрен бастырырга өлгермәвемә үкенеп куям. Хәер, яхшы әсәрләргә, яхшы кешеләргә игътибар бирергә беркайчан да соң түгел.

«Идел»нең беренче санында дүртенче битне буш калдырдык. Төсле кысага алынган шушы журнал битенең аскы почмагына үзем чыгарган чәчмә шигырь куйдырттым. «ЯЗЫГЫЗ! Җирдән шыттык, җиргә сеңәбез. Чәчәк атып тагын шиңәбез, орлыкларны сибеп туфракка... Күпме җырлар көйде, күпме җаннар янды гомер дигән усал учакта! Аяз күктәй керсез кәгазь бите! Көзге кебек гадел. Шул көзгедә язылмаган китап, яшәлмәгән гомер, әйтелмәгән васыять, гыйшык хаты, мәдхияләр.» «Идел»нең яшь иҗатчыларга мәйдан бирү миссиясен белдерәсем килгәндер...

«Идел»нең икенче саныннан, 1989 елның августыннан башлап гадәттәге «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!» урынына «Сөй гомерне, сөй халыкны...» шигырен куйдык. Беренче тапкыр...

«Күптән түгел Германиядә чыккан бер журнал күрдем. Шуның кайбер битләренә кечкенә бизәкле пакетка салып, йә ислемай, йә сыек сабын, затлы порошок, тагын әллә нинди кирәкле тауарлар кыстырылган. Иснә, юын, авыз ит, тотып кара, хөрмәтле укучы. Һәр нөсхәгә җиткереп, шул пакетларны матурлап ябыштыручы кешесе яки машинасы табылган бит.

Әгәр мөмкинлек булса, «Идел» журналы битләре арасында түбәндәге нәрсәләрне кыстырып җибәрер идем: хаксыз рәнҗетелгәннәргә — аклау кәгазе һәм гафу үтенү хаты; мөстәкыйль Татарстанның төп канунын; аерым фатирга ордер; сәяхәт яратучыларга — путевка һәм авиабилет; сөт-ит, конфет-чәй алырга талон; авыруларга — иң яхшы дарулар; моңлыларга — иң яхшы җырлар, шигырьләр язмасы; Татарстанның һәр тарафында шоп-шома юллар ачылу тантанасына чакыру кәгазе; компьютерда эшләргә, чит телдә сөйләшергә бер атнада өйрәтүче методик әсбаплар; тарихыбызны һәм киләчәгебезне төгәл итеп күрсәтә торган бинокль сызымы; ялгызларга — ихлас дуслык хисләре; шау-шудан, ялганнан туйганнарга интим тынлык һәм бер чеметем генә ялгызлык...

Бу эшләр кулдан килмәгәнлекне белә торып әкият сөйләгән өчен мине сүгеп тә ташларсыз. Ләкин нишлим: һәр заманда вәзгыять могҗизалар таләп итә.

Дөресен әйтергә мәҗбүрмен: «Идел» журналы сезнең һәммә мохтаҗлыкларыгызны да канәгатьләндерә алмас. Ул сезгә бәхет тә, байлык та бирмәс. Безнең һәр укучыга өләшергә теләгән нәрсәбез — аң. Сәясәтне, заманны дөрес аңлау өчен кирәкле мәгълүмат, тузып бетмәгән фикерләр, матурлыкны, рухи байлыкны йөрәккә һәм акылга җиткерүче аң. Калганын үзегез табарсыз инде... Гаепләмәгез.»

Бу юллар «Идел» журналының беренче еллыгы уңаеннан 1990 елда басылып чыкты. Бүгенге «Идел»челәргә дә җиңел түгелдер.

Ә Идел ага, һаман ага...

Ун ел элек...

Исмәгыйль Шәрәфиев,
"Татарстан яшьләре" газитенең баш мөхәррире

Сагыну

"Идел"не сагынам...

Ул дөньяга килеп, тәпиләп киткән чорларда мин җаваплы сәркәтип булып эшләгән идем. Инде шактый гомер үтеп, сагыну-юксыну хисләре тоныкланган дип торсам — юк икән.

Кызганыч, көндәлек алып бармаганмын. Хәер, көндәлек кайгысы идемени ул чакларда? Журнал ачылды, бина бирелде, редакциядә бер иске өстәл, өч ватык урындык пәйда булды. Менә шул җиһазлар тирәсенә җыйналабыз да сөйләшәбез, җыйналабыз да сөйләшәбез.

Ул вакытлар... Өстәл кирәк, урындык кирәк, телефон кирәк, язу машинкасы кирәк, редакция мөһерен ясатырга кирәк... Кирәктән күп нәрсә юк. Әле җитмәсә журнал да чыгарырга кирәк. Беренче санны. Вакыт та кыса. Рәссамнар юк, фотографлар юк, шрифтлар юк, техредакторлар юк. Журналның макеты юк. Кыскасы, юктан күп нәрсә юк.

Журналның беренче саны бик зур авырлыклар белән туды. Әмма туды. Яңаны тудыру шатлыгы, җиңү тантанасы бөтен газапларны онытырды. Без барыбыз да бәхетле идек. Мин шул чакта кичергән бәхет мизгелләрен сагынам.

Рәфикъ Юныс.

Өзелгән спектакль. 1994, №7.

26 ел элек Г.Камал исемендәге театр бинасында "ЧП" булды. Халык тулы залда буран уйнады. Листовкалар бураны.

Листовкаларда бер таләп куелган иде: "Идел" журналы чыгарылсын!

1968 елның 25 марты. Партер, ике кат балкон шыгрым тулы. Монда бөтенесе дә бер-берсен белә. Чөнки тамашачылар сайлап чакырылган: театрда Татарстан язучыларының чираттагы VII съезды үтәчәк...

...Юк, мин берәүне дә гаепләмим. Кемнәрнеңдер чирек гасыр элек бөтенләй бүтән заманда кылган гамәлләрен тикшереп утыру егетлек түгел. Мин бары тик әлеге съездны татар тарихына гына салып карыйм. Болак арты татар республикасы тар-мар ителгәннән соң 50 ел вакыт узган. Суверенитет турында Декларация кабул ителәчәк көнгә 22 ел бар әле. Күпме еллардан соң зарыктырып килгән ирек, аны алу һәм сатулар шушы корылтайга да бәйле ләбаса. Бәйсезлек алган җөмһүриятләрдә язучылар халыкны әнә шул чакларда ук яки күп алданрак уята башлады ич. Ә монда татарның милли аңын тәшкил иткән асыл затлар үзләре оеп-йоклап яки дошман уенына катнашып утыралар. Уятасы иде аларны, бозасы иде бу уенны! Листовкалар түгел, чиста кәгазьләр ыргытып булса да. Әмма листовкалар язылган, аларны ыргытасы кешеләр тиешле урыннарга менеп кунаклаган инде.

Кемнәр соң алар? Сәер хәл. Бу вакыйга күпме еллар телдән төшмәде. Әмма листовка ыргытучыларның үзләрен белүче юк. Бу да татарның милли үзенчәлегенә бәйле бер нәрсә инде. Безгә каһарманлык һәм аның нәтиҗәләре — кирәк, каһарманнар үзләре — кирәкми...

Кыскасы, Татарстан язучыларының VII съездында листовкалар ыргыткан егетләрнең исемнәре матбугатта беренче мәртәбә игълан ителә. Менә алар: Разил Вәлиев, Зөлфәт (ул чагында — Зөлфәт Маликов), Мирза Мансуров...

Ун ел дәвамында "Идел"нең төрле калынлыктагы 118 саны дөнья күрде. Җәмгысе 10024 бит җыела. Без шул битләрне күздән кичерергә, ягъни, кыскартып яки өзекләр алып, аларның кайберләрен яңадан тергезергә булдык.

Рафаэль Хәкимов.

Халыкмы без, әллә яшәүчеләрме? 1989, №3.

...СССР төзелү уңаеннан көн тәртибенә РСФСРны тарату мәсьәләсе килеп баса, автономияле республикаларның да СССР составына, башка республикалар кебек, тулы хокуклы булып керүе күздә тотыла. Ләкин Сталин үз баласы булган РСФСРны яклап кала. "Минем уемча, — дип сөйли ул Бөтенроссия Советларының X съездында, — бу рациональ юл түгел, өстәвенә максатка да туры килми һәм кампаниянең барышы белән кире кагыла. Беренчедән, ул республикаларның берләшү процессында туып өлгергән федераль оешмаларның аерылуына китерер иде, — бу исә республикаларның революцион берләшү процессын тулысынча юкка чыгара. Икенчедән, әгәр дә без шушы ялгыш юлдан китсәк, хәлләр шундый борылыш алыр иде ки, ул чакта сигез республикага өстәп, РСФСРдан махсус рус ВЦИКы һәм рус Совнаркомы бүлеп чыгарырга туры килер, бу исә үз чиратында оештыру эшләренә хәзерге моментта бөтенләй кирәксез һәм зарарлы зур буталчыклар кертер иде. Эчке һәм тышкы хәлләрне искә алсаң, бу хәзерге вакытта һич тә акланмый. Менә ни өчен мин союзга берләшергә тиешле субъектлар дип дүрт республиканы атыйм: РСФСР, Кавказ арты федерациясе, Украина һәм Белоруссия"...

Сталин алдаша, әлбәттә. РСФСРда ул чакта ук инде рус ВЦИКы һәм Совнаркомы функцияләрен башкаручы югары органнар булган. Хикмәт анда түгел. Сталинга ничек тә рангларга бүленгән "автономияләр" идеясен яклап калырга кирәк булган. РСФСР сакланып калган очракта, татарларга да дәүләт ише бер нәрсә бирелгән булып чыга, ә милли үзенчәлекләреннән мәхрүм ителгән руслар исә дәүләтчелек идеясе белән тиңләшәләр, дөресрәге, дәүләт бюрократиясен гәүдәләндерәләр.

Ләкин ул чакта бит инде милләтләрнең үзбилгеләнү принцибы бар, һәм, гәрчә авыру сәбәпле СССРны төзүдә катнаша алмаса да, Ленин үзе дә әле исән, Сталин бу принципны капма-каршысына үзгәртә. 1913 елда ул аны болай аңлаткан иде: "Үзбилгеләнү хокукы — ягъни: милләт үз язмышын фәкать үзе хәл итә, беркем дә тормышына көчләү юлы белән катнаша алмый, аның гореф-гадәтләрен бетерә, телен кысрыклый, хокукларын чикли алмый"... Ул чакта Сталин әле демократ иде. 1920 елны бу принцип инде "автономияләштерү" политикасын үткәрергә комачаулый, һәм Сталин аны төзәтә: "...Халык массалары интереслары революциянең хәзерге дәверендә окраиналарның аерылып чыгуны таләп итүен үтә контрреволюцион эш дип таба", — ди...

...Татар милләтенә каршы юнәлтелгән беренче һөҗүм, ике автономияле республика төзү юлы белән, безнең халыкны икегә бүлүдән башланды. Шушы бүлгәләү аркасында башкортлар үз республикаларында азчылыкта калдылар. Татар халкын бүлгәләү, аннан соң тормышын Татарстан рамкалары белән чикләп кую Сталинга татарлар өстеннән шактый җиңел идарә итү мөмкинлеген бирде, җитмәсә, Татарстан һәм Башкортстан арасында даими көндәшлек атмосферасы тудырды. Башкортстанның үзендә исә сан ягыннан ишләрәк булган татарлардан шикләнү тәрбияләнеп килде. Башкортстандагы булган хәлләр шушы политиканың нәтиҗәсе булып тора...

Исмәгыйль
Мостафин.

Аллаһу әкбәр.
(Корьәнне урысчага
шигъри тәрҗемә иткән
Валерия
Порохова белән әңгәмә).
1995, №10

Зөлфәт Хәким.

Диагноз:
хроник ирексезлек.
1995, №1.

— Валерия Михайловна, үзегезнең ничек итеп хак юлга төшүегез турында сөйләсәгез иде.

— Корьәндә язылганнарның асылына нисбәтән, француз академигы Морис Букаиның (ул бөтен булмышы белән христиан кеше) "Дөньяда бердәнбер изге китап — ул Корьән", дигән сүзләре хәтергә килә. Нигә Корьәнме? Чөнки ул иңдерелгән чагында ук язып та алынган. Ә без хәзер Библия дип атый торган китап исә — авыз иҗаты ул... Авыз иҗаты — димәк, кеше иҗаты, ягъни авыз иҗатында Ходай Сүзе кеше заты аша уза, бик күп нәрсәсен югалтып тапшырыла. Нәтиҗәдә — аны күп төрле итеп сөйләп бирүләр, тәрҗемәләр пәйда булган... ... Мондый зур абруйлы христиан атакайларының тикшеренүләренә минем ышанмыйча хәлем юк... Гафу итегез, мемуарлар — әдәби жанр. Изге Юстиниан, христиан дин гыйлеменең шундый зур абруй иясе, Библияне "апостолларның мемуарлары" дип атаган икән инде, бу хәл дә күпмедер дәрәҗәдә күңел кайтуга китерә.

Корьәннең инглизчәсен укыган идем (шуны да әйтим әле, инглизләр мине урыс дип санамыйлар) — исем китте. Мин шаккаттым. Моны үзең кичерергә кирәк. Бу чын-чынлап мине тетрәтте. Минем аңлавымча, Ходай сүзенең авторы бер генә булырга тиеш, Корьәндә ул нәкъ менә шулай. Корьәндә Ходай үзе сөйли...

— Корьәнне беренче мәртәбә укыгач ни кичердегез? Нинди тойгы?

— Булуы мөмкин түгел! дип соклану тойгысы. Шундый китапның булуы мөмкин түгел дип исем китү. Андагы бар нәрсә дә мине шаккатырды. Анда акыл, Ходай акылы булырына мин әзер идем, ләкин мине Корьәннең фәннилеге тетрәтте. Энгельс "Табигать диалектикасы" китабында Һегелнең санның сыйфатка күчеше канунына мисал китерә, бәлки хәтерлисездер. Иген чәчә торган игенче турындагы ул мисалны Энгельс Корьәннән алган һәм аны үзенеке итеп күрсәткән. Әмма ул Корьәннең 56 нчы сүрәсеннән!

— Корьәннең тере китап икәнен тойдыгызмы соң?

— Тере генә түгел. Ходай илаһы иңгән китап ул. "Әл-хәмдел-иллаһи раббел-галәмин" (галәмнәр хуҗасы Аллаһка мактау...) дип укыйм. Менә ул Һегель диалектикасы. Библия безнең дөньядан гайре дөньялар булуын катгый инкяр итә. Юк алар аның өчен, бетте-китте! Һәм менә сез Корьәнне ачасыз, һәм беренче юлы ук: "Галәмнәр хуҗасына..." Моны ишетүгә галимнәрнең христианы да, буддачысы да, яһүдие дә, мөселманы да шым була... Хәзер ничаклы галактикалар, — бихисап галактикалар! — дөньялар бар икәне билгеле булды бит инде. Христианнар китабы Кояш һәм Җир барлыгын гына хәбәр итә. Корьәнгә карагыз: "Һәм ул Кояшны, Күкне вә Җирне вә алар арасында булганнарны яратты..." Күк белән җир арасындагы бу матди "күперләр" фән тарафыннан гасырның 50 нче елларында гына ачылды әле...

Мин коточкыч нәтиҗәгә килдем: минем халкым авыру!

Буйсындырылу, үзгә дин тотучы, үзгә холыклы милләткә баш иярргә мәҗбүр булу татар халкында эчке ирексезлек тудырды. Бу — психологик авыру. Татарны изгән, җәберләгән һәр тарихи вакыйга бу чирне кат-кат яңартты гына, янә үстерде һәм катлауландырды. Татар милләтенең башына янә бер коточкыч саллы кусәкне иң соңгы вакыйга орды — суверенитетка ышанган халык аны алалмады, алданды.

Ирекка ихтыяҗ — кеше организмының биологик реакциясе. Тарих дәвамында халыклар һәм сыйныфлар үзләрен изүчеләргә каршы көрәшкәннәр. Асылда кешелек тарихы — азатлык һәм хөррият өчен көрәш тарихы...

...Әлбәттә, куркуны җиңә торган иң шәп чара — агрессивлык. Әгәр дә кеше курку дигән пассив халәттән үзендә һөҗүмгә күчәрлек көч таба икән, курку газабы шундук юкка чыга. Ләкин татар халкы бу чараны сайламаган, дөресрәге, аны кулланырга татарның инде хәленнән килмәгән. Соңгы вакытларда һәм бүген дә татар халкының агрессив булмавы гуманлык принципларының нәтиҗәсе түгел, ул хәлсез, аның көче беткән, психик көчләре алҗыган.

Татар халкының бердәнбер котылу чарасы хезмәт булган һәм бу бүген дә шулай. Урыс чолганышында кирәгеннән артык хезмәт сөючәнлеге — татарның моңа хөкем ителүенә тиң.

Авыр хезмәт буыннан буынга татар халкының генетикасында чагылыш таба һәм моны бүгенге татарларның буйсыннарында да чамаларга була...

...Авыл татарының буй-сынына, йөрешенә игътибар итегез. Алар авыр адымнар белән, бераз бөкрәеп атлый, гүя һаман да үзе басып барган җирдән дөреслекне эзли. Рәхмәтсез һәм түләүсез хезмәт аны ямьсез гәүдәле иткән...

Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллин,
Нурлат шәһәре һәм районы хакимият башлыгы

– Журналның исеме бик дөрес сайланган дип саныйм. Безнең борынгы Болгар дәүләтебез дә, хәзерге тормыш-көнкүрешебез дә шушы Идел исеме белән бәйләнгән бит.

Демократик үзгәрешләр башланган вакытта барлыкка килгән, яңа Идел белән сугарылган "Идел" башка журналлардан бер башка өстен тора дип уйлыйм. Урыс әйтмешли, так держать, "Идел"челәр!

Мөхәммәт Хәбибулла улы Гатиятуллин,
Кукмара районы хакимият башлыгы

– Минем үземнең төп һөнәрем укытучы. "Идел"не кулыма алгач, ирексездән мөгаллим булып китәм – бу мәкаләне, бу язманы һичшиксез дәрестә кулланырга кирәк, дип уйлыйм.

Кукмарада татарлардан тыш удмуртлар, марилар, урыслар да яши. "Идел" журналының ике телдә чыгуы башка милләт вәкилләрен татар тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән таныштырырга ярдәм итә, үзенә күрә дәреслек булып тора.

Ринат Шамил улы Хәйров,
Татарстан республикасының дәүләт салым инспекциясе җитәкчесе

– Идел бит ул тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.

Татар җырына туры килеп тора сезнең журнал. Язмалары киң колачлы, эчтәлеге тирән аның. Киләчәктә дә тараймасын, саекмасын иде "Идел".

Ә без үз чиратыбызда "Идел"не яшәткән бюджетны тарайтмаска, саектырмаска тырышырбыз.

Рәфикъ Юныс

Без җиңелмәдек, безне җиңелдерделәр!
Фәндәс Сафиуллин белән әңгәмә.
1995, № 4

— Фәндәс әфәнде! 1991 елның 12 августында Казан белән Мәскәү тигез хокуклы сөйләшүләр башлап җибәргән иде... 1994 елның 1 февралендә Татарстан белән Рәсәй арасындагы Шартнамәнең проекты парафирланды. 15 февральдә исә һич көтмәгәндә бөтенләй бүтән кимәлдәге Шартнамәгә кул куелды...

Халыктан яшереп калдырылган, "Идел"дән тыш бүтән беркайда да басылмаган 1 февраль лаиһәсендә (проект) сезнең имза да тора. Сәясәтчеләр, юристлар, тарихчылар бу лаиһәгә һәм аны юкка чыгарган 14 көнгә кат-кат әйләнеп кайтачаклар әле. Сез беркадәр булса да шуларның серен-хикмәтен ача алмассыз микән?

— Серле эшләр Мәскәүгә баруның беренче көнендә үк башланды... Делегация әгъзалары — президентның киңәшчесе Рафаэль Хәкимов һәм мин, делегациянең җитәкчесе — вице-президент Василий Лихачев. Боерыкка 1994 елның 19 гыйнварында кул куелган, Мәскәүгә 20 сендә барганиебызды инде. Шул көнне үк Рәсәй делегациясе белән очрашу булырга тиеш иде. Җитәкчебезне таба гына алмыйбыз бит... Сөйләшүне башыннан ахырынача үзебезгә ерып чыгарга туры килде. Делегация башлыгы бер генә утырышта да катнашмады! Без Шартнамә проектын парафирлап, ягъни текстын кул кую өчен әзерләп кайттык.

...13 февральдә делегация яңа состав белән киткән кул куярга. Соңгы рәсми делегациянең әгъзасы булсам да, мин бу хакта алар китеп баргач кына белдем. Рафаэль шылтыратып әйтте. Ярар, мин әйтәм, Рафаэль, кем кул куйса да, безнең эш әрәм булмас. "И, Фәндәс Шакирович, ә син беләсеңме нинди проект белән киттеләр алар?!" — ди. Укып күрсәткән иде, йөрәкне кысып алды, инфаркт дип торам...

Казан, Мөштәри ур., 14. "Идел"гә

Айдар Сәхибзадә

Ике башлы угыл, яисә "тәҗрибә куяннары". 1996, № 9

...Мисалга Чиләбе өлкәсенә карый торган Мөслим дигән татар авылын алу да җитеп ашкан. Ислам җәмгыяте рәисе Госман Кәбиров әйтүенә караганда, авылда балык койрыклы балалар туа башлаган икән.

Мөслимдә галимнәр дә фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Нәтиҗәдә авылның бишенче буынына караган һәр дүртенче балада генетик үзгәрешләр, мутантлык чалымнары табылган.

...Радиация зонасында бары тик бер Мөслим авылы гына торып калды.

Ә нигә — Мөслим?

Бу сорауга авыл кешеләре үзләре: "Без бит — тәҗрибә куяннары, шуңа күрә дә монда калдырдылар", — дип җавап бирәләр. Чыннан да, радиация алган бу авыл кешеләрен тикшереп, күзәтеп вә өйрәнеп торганнар. Әмма ләкин бу хакта әйтергә дә, язарга да ярамый иде...

...Чиләбедәге биохимия институтын Мөслимнең өлкәнрәк кешеләре әле дә яхшы хәтерлиләр. Эт һәм тычканнар белән тәҗрибә үткәрүче бу оешмага аларны да китерә торган булганнар. Бер бүлмәдә мутант этләр уласа, аның күршесендә адәм балалары өзгәләнгән. ФИБ-4 тикшерү өчен алардан йә чәч бөртеге, йә таза теш (!), хәтта умыртка җелеген дә суырган! Эт-тычканнан да, мөслимлеләрдән дә рөхсәт сораучы булмаган.

..."Тәҗрибә" үтүчеләр рак яисә лейкомия авыруыннан үлә калса, аларның туганнарына "организмның тулаем чиргә бирешүеннән үлде" дигән таныклык кына бирелгән...

Атом чүплегендә яшәп ятуларын Мөслим кешеләре хәбәрдарлык чоры җиткәч кенә чын мәгънәсендә төшенә башладылар...

...Җирле хакимият Мөслим татарлары язмышы өчен борчылмый. Хәтта борчылучыларга да аяк чала...

Николай Михайлович Владимиров,
Минзәлә шәһәре һәм районы хакимият башлыгы

— "Идел"не укысам, ничектер күңелем яшәреп, матураеп китә. Киләчәктә дә тормыштагы хәлләрне йөрәккә үтеп керерлек итеп язгыз — җаннарны кузгатып, "яшьлек элексиры" салыгыз.

Нурислам Нуриман улы Хәбипов,
Баулы шәһәре һәм районы хакимият башлыгы

— "Идел" журналы, татар халкының узганын, бүгенге яшәешен дөрес чагылдырып, бүгенге көн өчен генә түгел, киләчәк өчен дә хезмәт итә. "Идел"не укып үскән, рухын ныгыткан яшьләребез XXI гасырда милләтебезне саклар, өметләребезне аклар дип ышанам. Шулай булса, йөз еллыгын да, ике йөз еллыгын да каршы алыр "Идел".

Федор Иванович Казайкин,
Идел буе электр челтәре директоры

Федор Иванович Казайкин "Идел" журналы 1992 елда икътисади кытлык кичергәндә саллы матди ярдәм күрсәткән иде.

— "Идел" — яраткан журналым. Мине — мордва кешесен журнал татар тарихы, мәдәнияте, сәнгате белән таныштыра. Киләчәктә журналыгызны башка милләт вәкилләре дә күпләп укысын иде.

Равил Хәмәт улы Зарипов,
"Алабуга" ирекле икътисад төбәге хакимият башлыгы, АлАЗның генераль директоры

— "Идел" журналы җаныма якын. Бер яктан, Зөлкарнәйләр минем якташлар. Икенче яктан, татар тарихы да, икътисад мәсьәләләре дә күпертмичә, шапырмыйча – ничек бар шулай, дөрес итеп күрсәтелә. Әлеге сыйфаты өчен журналны башкалар да ошата дип уйлыйм.

Кая агасын белеп ага "Идел". Көймәдә утырган мөхәррирләре дә, бер команда булып, бер якка ишеп алга барсыннар иде дип теләп калам.

Әнәс Гатуф улы Исхаков,
Азнакай шәһәре һәм районы хакимият башлыгы

— Бу тормышны өч кит күтәреп тора: тән тазалыгы, җан тынычлыгы һәм дөнья иминлеге. Шуларның берсе генә булмаса да тормыш кыйшая, асты өскә килә башлый.

"Идел"нең үз китлары бар. Хәтта өчәү генә түгел, күбрәк: ару-талу белмәс иҗат киты, хаклык-гаделлек киты, яшьлек-җилкенчәклек киты... Шул китларның берсе дә "Идел"дән читкә йөзеп китмәсен иде.

Наил Гамбәр улы Мәһдиев,
Бөгелмә шәһәре һәм районы хакимият башлыгы

— "Идел" беренче саннарыннан ук кыюлыгы, яңалыгы белән күңелләрне яулады. Бүген дә журналдан яңа фикер, яңа идея, яңа сүз көтәм. Тумас борын картаймасын, яшьләр журналы булып, яшь булып калсын иде "Идел".

"Идел" журналының баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәйнең юл фаҗигасенә тарып һәлак булуына ике ел тулды.

Кемдер: "Махсус оештырылган эш бу, гомер бакый милләтнең башын кисеп киләләр", — ди.

Кемдер: "Тәңре үз катына иң яхшыларны сайлап ала", — ди.

Югалтабыз да юанабыз.

Инде кайгы сөреме таралып килә.

Фәиз Зөлкарнәйнең татар мәдәнияте өчен, "Идел" өчен кем булганы ачыграк күренә башлады. Нинди асыл затны югалтканыбызны көннән-көн ныграк тоя барабыз.

Инсаф СОЛТАНОВ

Фәизнең яшел куышы

Авылдашым булса да, мәктәпкә кадәр Фәизне якыннан белми идем. Саскүл авылы алай зур түгел, Бишкаен белән Ык елгасы арасында ышыкланып утырган Озын урам да, Кара тал тавы култыгына сыенган Комгансызлар урамы. Тәпи йөри башлагач та малайлар белән аралашып-тәпәләшеп, дуслашып чыгарлык кечкенә авыл. Кечкенә булса да, кибет турыннан авыл икегә бүленә — түбән һәм югары оч малайлары үзара "чәкәләшеп" яши. Икебез ике очта торганлыктан, Фәиз миңа "дошман" саналырга тиеш иде. Якыннан белмәвемнең икенче сәбәбе — Фәиз күрше Сөендек авылында туган малай, әти-әнисе Хәтирә апа белән Мәүлит абый яңарак кына безнең авылга күчкәннәр иде. Мәүлит абый — Саскүлнеке, Сөендектә ГЭСта эшләгән, шунда өйләнгән, ГЭС ябылгач туган авылына кайткан. Мөгаен, Фәиз Саскүлне тиз генә үз итмәгәндер, җай чыккан саен Сөендеккә — әнисенең туганнарына, дус малайлары янына сыпырткандыр.

Авылыбыздагы башлангыч мәктәптә бергә укыганда да Фәизнең класста барлыгы сизелми иде: кызлар чәчен тартмый, дәрестә сөйләшеп утырмый, укытучы Мөбәрәкша абый тәмәке төтене белән ысланган бүлмәсенә аны ябып куймый.

Куштирәк урта мәктәбе. 1965 ел.
Беренче рәттә сулдан уңга: өченче — Ф.Зөлкарнәй, дүртенче — Инсаф Солтанов. Уртада — класс җитәкчесе Земфира Мостафина.

Шулай да үзен рәнҗеттерә торганнардан түгел иде ул. Әле дә хәтерлим, ничектер эләгешеп киттек тә, мин сукканмындыр инде, парта өсләтеп мине куып артыма типкән иде.

Саскүлләр Куштирәк урта мәктәбенә йөреп укый башлагач кына дуслашалар. Анысы да биш-алты авылдан җыелган малайлар арасында "марка" төшермәс өчен. Бергә булмасаң, Куштирәк "көртлекләренең" башка менеп кунаклауларын көт тә тор.

Дуслашуның тагын бер сәбәбе — мәҗбүр итсәләр дә саскүлләр интернатта тормый, бер-ике көн куналар да мендәрләрен култык астына кыстырып качалар. Язгы, көзге баткакта, кышкы суыкларда, бураннарда саскүлләр юлда булыр.

Юл газабы бер якынайтса, рәхәт-

лекләре тагын да якынайта: әрәмә буенда бәрәңге пешерүләр, пугач ясап шарт та шорт атулар, Зирек күлендә су коенулар, ябалак оялары караулар...

Урта классларда укыганда Фәиз бик алдыра алмады, математика, физика ише төгәл фәннәргә әлләни исе китми иде аның. Шулай бервакыт безнең укытучылар авыл мәктәбенә килеп ата-аналар җыелышы уздырды. Әни мәктәп карауучы булып эшли иде, мин аның уң кулы — утынын ярам, суын ташыйм, форсаттан файдаланып, яшеренеп, шул җыелышны тыңлап торырга туры килде. Класс җитәкчебез Мостафина Земфира апа безнең хакта сөйләп үтте дә Фәизгә тукталды.

1989 елда, әнә шундый гаярь тай сыман, "Идел" журналы торгынлык заманасыннан калган аран киртәләрен бәреп чыкты. Бәреп чыкты да, бүтәннәрне дә үзенә ияртеп, хакыйкать менә бу тарафта ул дигәндәй, тарих каршысына томырылды...

Ф.Зөлкарнәй, 1994 ел.

"Шундый башлы егет, әдәбиятны су кебек эчә, ә кайбер фәннәрдән укуы җитеп бетми", — диде.

Фәизнең әнисе Хәтирә апа көлеп сөйләде шул чакта. "Бик озак дәрес әзерләвенә аптырап тикшереп карыйсы иттем. Дәреслек өстенә әдәби китап куеп, шуны укып утыра икән ул. Китап укуыннан берничек тә котыла торган түгел аның! Малларга печән салганда да печәнлектән китаплары килеп чыга. Чарлакка менсәм дә аның китапларына абынам..."

Чыннан да, Фәиз дәрес барганда да, парта астына куеп, әдәби китап укырга ярата иде.

Элек Куштирәктә ел саен китап укучылар конференциясе уздыра иделәр. Китапханәче апаның гаҗәпләнеп, сокланып сөйләве истә калган. Колхозга карауучы дүрт авыл кешеләре арасында Фәиз Зөлкарнәев иң күп китап укучы булып чыкты һәм беренче бүләккә лаек булды. Куштирәктә укымаган китабы калмагач, район үзәгендәге китапханәгә юл салган иде ул.

Бервакыт җәй айларында Фәиз көндезләрен югала башлады. Әтиәнисе дә белми кайда икәнен. Эзли торгач таптык без аны. Бәрәңге бакчасы артында зур өянкеләр үсә. Шул өянкеләрнең берсендә куыш ясаган икән Фәиз. Шунда качып китап укып ята икән...

Без, егетләр, авыл клубында кеше булмаганда, яки кичке уеннан соң берәрсенең капка төбенә утырып, Фәиздән укыган китапларын сөйләтергә ярата идек. Ул тәмләп, тасвирлап калынрак китапларны икешәр, өчәр төн сөйли иде, күп серияле һинд киносы кебек була иде.

Фәиз "китап корты" гына булган икән дип уйламагыз. Без укыган чорда районда үзешчән сәнгать бик көчле үскән иде. Безнең колхоз берничә ел рәттән алдынгы урыннарны алды. Ә Фәиз театрда бик оста уйный иде.

Үз алдына бурыч куеп, шуңа ирешергә ярата иде Фәиз. Бер генә мисал китерәм. Без, берничә егет, чаңгыда шуып районда уңышларга ирештек. Шуңардан көнләшепме, әллә калышмаска теләпме, Фәиз дә чаңгыга басты, тиз арада II разрядлы чаңгычы булды.

Урта мәктәпне тәмамлагач безнең юллар аерылды. Армиядән соң Азнакай шәһәрендә очраштык. Ул беренче елны укырга керә алмады һәм Азнакайда эшкә урнашып (һөнәре дә нинди әле — янгын сүндерүче, мөгаен, китап укырга вакыт күп калсын өчен сайлап алгандыр ул аны), имтиханнарга әзерләнә башлады, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә барып керде.

Еллар үтеп аның туры сүзле тәнкыйтьче, үзенчәлекле шагыйрь, "Идел"не асыл журнал иткән баш мөхәррир булып китүенә бер дә гаҗәпләнмәдем. Фәиз үзенең кем буласын балачактан ук белгәндер сыман тоела миңа...

Фәиз Зөлкарнәйнең арабыздан киткәненә ике ел тулды. Аның юклыгына күңел ышанмый. Бала чактагы шикелле югалып торуы гынадыр — эзләп чыгасым килә. Карт өянкедәге яшел куышында качып һаман да китап укып ятадыр сыман.

Ул урман чишмәсенең тәме әле дә иренемдә. Үз кулларым белән кушучлап су эчкән беренче чишмәм ул минем. Печән өсте чишмәсе!

Кая әле ул вакытта чалгы тоту — юкә саплы, агач тешле тырманы да сырт ягы белән генә тарта алганмындыр. Шулай да эшнең кызуы миндә. Кульяулыкны , дүрт почмагын төйнәп, җиләс түбәтәй итеп кигән әтәй дәшеп кенә тора:

— Әй, малай, кил әле, йөтерәк кил, әнә, җиләкләрең кача.

Яңа гына чабылган күперенке кәрешкәләр өстеннән тәгәрәп төшәм дә камылларны аударып сузылган аяк эзе буйлап кына юыртып китәм.

Күләгәдә аксылланып пешкән эре җиләкләр, җиргә төшә алмыйча, камыл араларына кысылышкан.

Безнең печәнлек — кударада. Аланның түбән читеннән тирән чокыр башлана. Печәнлектән төшкәндә аны чокыр дип уйламыйсың да — аста үскән агачларның ябалдашлары өстеннән сукмак китә сыман.

Эссе һаваны чикерткәләрнең зеңе рәшәләндергән чак.

Абый белән чишмәгә төшәбез. Ул мине җитәкләп бара. Кулымда борынына калай кружка эленгән, тышы корымнан кытыршыланган чәйнек атына. Сукмак кыйгачлый да текәләнә, бераздан баскычка әйләнә. Салкынча рәхәт һава тубыктан балтырга үрмәли. Сусыл күләгә куерганнан-куера. Баскыч читендәге кура җиләклеккә генә өстән бер көлтә кояш нуры төшкән — чәйнек эченнән кояшка яшел чикерткә сикерде...

Җир баскычның иңкүләнгән бусагалары аска төшкән саен дымлана, салкынлана. Киң, шома яфракларга юеш эз салган әкәм-төкәмнәр, мөгезләрен чөеп, миңа карыйлар сыман: "Безнең кара сыер сөтен алырга килдеңме?"

Җир баскычның яшел-кызгылт мүкле соңгы бусагасыннан абый мине күтәреп ала да чишмә алдына түшәлгән таш өстенә бастыра.

Үги ана яфраклары уратып алган түгәрәк чишмә безнең өйдәге казанга, инәй сөт кайнатып кызыл эремчек ясый торган казанга охшаган.

Чишмә талгын ут өстендә кайнап утыра сыман, төбендә нидер җанланып-җанланып ала, карасуланган яфрак кисәкләрен, ком бөртекләрен айкалдырып, тулгандырып тора.

Үрелергә дә куркам, бармагымны пешереп алыр сыман: казанга — сөт өстендә йөзгән каймакка үрелгәнем бар иде минем...

Абый кружка белән чәйнеккә су тутыра да, күлмәген салып, чишмә өстенә иелеп, ах-ух килә-килә билдән юына башлый: уңга-сулга су чәчри, кигәвенчеркиләр кавеме аңа якын килә алмый

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

Кояшка – җылынырга китте

иөди. Минем янда исә отыры ишәяләр. балтырларымны чиратлап аяк сырты белән ышкыйм, җилкә аша аркама суккалыйм. Тизрәк җитсен генә чират — мин дә коенам. Тәне тимгелләнеп, иреннәре зәңгәрләнгәч, абый, күлмәк белән сулы чәйнекне эләктерә дә, кигәвен көчен ияртеп, югарыга элдерә. Абыемның ташлап китмәсен беләм — яр өстенә, кояшка җылынырга менеп китте ул.

Мин дә аякларымны аерып басып, чишмәгә иеләм. Суы болганган чишмә, мин үрелгәнне тоеп, ашыга-ашыга тыныклана. Әнә, су эченнән миңа охшаган бер малай карап тора башлады. Тагын кемдер карый кебек. Инәй сыман ягымлы итеп, яратып...

Печән өсте чишмәсенең тәме — күләгәдә пешкән җиләкле сөт тәме — әле дә иренемдә.

> ***Туры сүзле булганы, ачы хакыйкатьне ярып әйтергә кыюлык иткәне өчен "югарыдагы" агайлар аны "акылга утыртырга" да тырышып караганнар иде: журналның чыгуына махсус тоткарлыклар ясалды... Ләкин мөстәкыйль холыклы яшь журнал, заманалар никадәр генә авыр булуга да карамастан, үз дигәнен итте...***
>
> ***Ф.Зөлкарнәй. 1992 ел.***

Сабый бала дөньяга килгәч, кендеге белән җиргә, ана күкрәгеннән аерылгач, иреннәре белән чишмәгә берегә, ахры...

Чишмә суын татып та карамаган адәм баласы булса, дөньяның иң тансык ләззәтеннән, хиссиятеннән мәхрүмдер ул: ана сөте тимәгән, тана сөте имгән сабый хәледер аңарда.

Кичен абый белән авылга кайтып тормыйбыз. Печән чүмәләләре кибәнгә менгәнче өебез монда — урманда. Яшь каенны иеп әтәй ясап биргән шалашка кереп ятканчы учак ягыла, бәрәңге пешә, чәй кайный. Учактан күтәрелгән очкыннар күккә ябышып җемелди башлагач кына куышка үрмәлибез. Куыш эче якты — черек төпләрнең гәрәбәләре — тычкан утлары печән түшәмгә, печән түшәккә сибелгән. Куыш авызын әйбәтләп томалагач, чират миңа җитә — абый мине иске бишмәтнең култык эченә салып җиңнәрен бәйләп куя.

Тычкан утлары белән бергә күзләр дә сүнә. Колак кына һаман йокламый: әле төнге кош кычкыра, әле ябалак ухылдый, әле тычкан кыштырдый. Менә алар да тынды. Келтер-келтер, келтер-келтер. Монысы нәрсә икән? Келтер-келтер... Арба тавышы ла!

— Абый, уян, арба килә, абый! Печән урларга киләләр!

— Йокла сана, — дип мыгырдый абый. — Төн буена йөри ул арба...

Бераздан, тәгәрмәч келтерәгән тавышны басып, йоклаган тавышы да ишетелә. Шулай печән саклый-саклый, мин дә йокыга киткәнемне сизми калам.

Икенче көнне чүмәләләрне барлап йөргәнемне күреп абый көлә:

— Печән урларга тагын килер әле ул арба, төн генә җитсен!

Саный белмәсәм дә чүмәләләрнең һәммәсе дә урынында икәнен беләм, покостагы печәнгә дә кагылучы булмаган. Урламагач, нишләп төнлә урманда йөри ул арба?!

Чыннан да, төн җитеп урман тынуга ул арба тагын килә. Келтерәве ерагаймый да, якынаймый да, безнең печәнлеккә кирәгә кыймаган сыман урана бер тирәдә.

Авыр сулаганымны ишетеп абый сүз башлый:

— Чишмәнең көмеш тәгәрмәчләрен күрдеңме син? Күрмәдеңмени?! Һәй, энекәш, көмеш арбасы да бар әле аның. Көмеш арбага җигелгән көмеш яллы, көмеш тояклы атлары да бар! Төн җиткәч, көмеш арбага көмеш атларын җигеп йолдызлардан көмеш су ташый безнең чишмә...

P.S. Бу нәсер 1997 елның май аенда, абыем Фәиз Зөлкарнәй һәлак булырга ике ай кала язылган иде. Абыйга укыдым, балачакларны искә төшереп бик озак сөйләшеп утырган идек.

Бу журнал басылып яткан көннәрдә туган якта "Фәиз чишмәсе"н ачмакчылар.

Абыем якты дөньядан киткәч, бу нәсер гел башка төсмерләргә ия булды сыман. "Абыемның ташлап китмәсен беләм — яр өстенә, кояшка җылынырга менеп китте ул..."

Бәрәкалла!

Фәиз Зөлкарнәй премиясе

Шөкер, күренекле язучы, милләт хадиме Фәиз Зөлкарнәй исемендәге премиябез дә бар инде. Аны АлАЗ производство берләшмәсе булдырды. Берләшмәнең генераль директоры Равил әфәнде Зариповка рәхмәт инде.

Бу премия "Идел" журналында чыккан иң яхшы проза һәм публицистика әсәрләре өчен ел саен ике авторга биреләчәк. 100 әр доллар күләмендә. Беренче тапкыр премия "Идел"нең 1999 елгы саннары өчен 2000 ел башында тапшырылачак.

Фәиз Зөлкарнәй журнал ачылганнан алып 1990 ел азагына кадәр — баш мөхәррир урынбасары, аннары вафатына кадәр (1997 елның 17 июле) баш мөхәррир булып эшләде. Фәиз гел шәп әсәрләрне, талантлы авторларны барлап, аларны "Идел"гә тартырга омтылып яшәде. Бу эшен ул инде, димәк, үлеменнән соң да дәвам итәчәк.

Фәндәс Сафиуллин,
Татарстанның халык депутаты

Ун ел адәм баласы өчен әле сабыйлыктан чыгып килә торган яшь кенә булса, журнал өчен инде ул шактый күп вакыт. Ун ел эчендә университетлар аякка баса, яңа дәүләтләр оеша-тернәкләнә. Бу вакыт эчендә "Идел" дә җитлегеп өлгерде.

Журналыгыз һәр татар гаиләсенең өстәлендә ятсын иде. Шырдым-пырдым нәрсәләр, "мәгънәсе юк көлке-уен", анекдотлар-мәзәкләр басып укучыны җәлеп итү читен түгел, алай итсәң тиражны да бик тиз ун мәртәбә арттырып булыр иде. "Идел" — җитди уйландыра торган журнал. Аның чыннан да кирәклеге еллар үткәч, менә хәзер аеруча нык сизелә. Журналны алдыра башлаганда 16,17,18дә булган егетләр-кызлар җәмгыятебезнең төп көченә әйләнде инде. Әгәр бүген дәүләтебезне, татар мәнфәгатен якларлык кешеләребез бар икән, журнал моңа, мөгаен, бик зур өлеш керткәндер.

Ун ел элек, мөстәкыйльлек юлына аяк басканда, күкрәк тутырып азатлык һавасын сулаганда әнә шундый хөр фикерле, кыю журнал чыга башлау бик тә кирәк булган ул.

Халкыбызның тарихи хәтерен, милли аңын яңартуга, милли горурлыгын үстерүгә юнәлтелгән язмаларыгыз яшьләргә генә түгел, өлкәннәргә дә тансык. Алар бит яшьлекләрендә моны укып үсмәгән. "Идел" тәрбиясен алган яшьләр өлкәнәйгәч, ул, бәлкем, чыннан да яшьләр журналы гына булып калыр, ә бүген сез бөтен буыннарга да кирәк әле.

Бер нәрсә бик аяныч, журналга дәүләт җитәрлек игътибар бирми. Аңа бүген кәшәкәләр селтәп, шайба куып йөрүчеләр кирәгрәк бугай. Хәер, сез үзегезне, бер без генә түгел, бөтен татар мәдәнияте үги хәлендә бит, дип "юата" аласыз.

Бәлки, журнал редакциясенең үзенә дә, журналны рекламалау җәһәтеннән, активрак, әрсезрәк булырга кирәктер. Татарга хас тыйнаклыкның зыян китергән чаклары да була бит.

Зәки Зәйнуллин.

Дудай батыр.
1993, N1.

... —Икенче сыйныфта укыганда, Сталин үлгән яз иде, бик каты бозлы яңгыр яуды. Без мәктәптән кайтканда ярты юлда китереп бәрде бу яңгыр. Ышыкланыр урын юк — йөгерәбез үзебезнең якка. Урам буйлап түбәнгә шарлап гөрләвекләр ага, боз безнең такыр башларга биргәли — ә без йөгерәбез. Шулчак мин аккан су эчендә бер тере җан күреп алдым. Тукталып, иелеп карасам, нәкъ шушы көчек зурлыгында гына кәҗә бәтие. Яңа туган, күрәсең. Өшегән, күшеккән, кузгалыр көче калмаган мескеннең. Күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора бу. Күзе тулы ялвару: коткар!

Күтәреп алып, күлмәк эченә тыктым да, чаптым өйгә. Әнием кирәкми дә димәде, кирәк тә димәде. Әтиемә моңсу гына карап алды. Аның ул карашы, бу бәти исән калса, сөт кирәк булачак бит, дию иде. Әтиемә рәхмәт, күзләремә бакты да, калсын әйдә, дип башымнан сыйпады. Гаиләгә тиеш сөтне тагын бер җанга бүлә башладык...

Җаһар (*Дудаев — ред.*) үзенә терәлеп сүзсез генә басып торган малаеның чәчләреннән сыйпый. Президентның күз алдына ерак казакъ далаларында мәңгелеккә ятып калган әтисе килә, ахрысы... Мине ниндидер шом били башлый. Җаһар сүзен дәвам итә, аның тавышында җылылык пәйда була:

— "Коля" дип исем куштык үзенә. Ап-ак бәти иде. Аның акыллылыклары! Урамда әнигә берәр эт өрсә, ул эткә көн бетте. Өстенә менеп таптап китә! Куркуның нәрсә икәнен белми. Үзе тагын итагатьле — өйгә беркайчан рөхсәт алмыйча кермәс. Ишек төбенә килә дә, ишек ачык булса, башын сузып кына, бер генә тапкыр мәэлдәп аваз сала. Рөхсәтне әни бирсә генә керә. Башкаларның рөхсәтен рөхсәткә санамый — өй эчендәге эшләрдә әни командир булганын аңлый!

Әнигә ияреп базарга бара. Базарда төрле хәлләр була бит инде. Сату итүче берәр хатын әни белән телләшә, сүз көрәштерә башласа, безнең Коля ипләп кенә тегенең артына төшә дә, чигенә биреп, мөгезе белән китереп ора. Кайбер хатыннарны тәгәрәтеп үк җибәрә. Ә базар хатыннарына кызык. Әни базарга килеп керсә, аны төрле яклап чакыралар, көлешәләр.

Яше тулып узгач, урладылар Колябызны. Күтәреп алып китеп барганын күргәннәр каракның. Коля бик озак кычкырган. Тик без эзләп чыкканда ул юк иде инде...

Җаһар безгә күз йөртеп чыга да моңсу гына елмая.

— Кайгыбыз зур булды Коля югалгач. Әнием өчен бигрәк тә инде. Безгә сиздерми генә эзләргә дә чыгып киткәләде. Табылмады Коля. Ашадылар суеп...

Туфан Миңнуллин.

Татар мәдәнияте һәм Аурупа әкәмәте.
1995, N6.

...Нигә әле без сәнгать югарылыгы турында сүз чыккан саен Аурупага күз төбәргә, аңа табынырга тиешбез? Ә табыну бездә чыннан да бар. Аурупа тавыгының алтын йомырка гына салуына безне ышандырганнар. Югары уку йортларында чит илләр әдәбияты дип һәрвакыт Аурупа әдәбиятын гына укыталар. Әйтерсең лә Шәрекъта әдәбиятның эзе дә булмаган. Бактың исә, шәрекъ әдәбияты (бигрәк тә шигърият) белән чагыштырсаң, гареп әдәбияты бала гына.

Күптән түгел татар театрының бер артисты-режиссеры белән бәхәсләшеп киттек. Мин ул куйган спектакльдәге пошлость (татарчасын белмим) турында сүз кузгаткан идем, ул мине ханҗалыкта гаепләде. Аурупа мәдәниятеннән мисаллар китереп, сүзен дәлилләде. Янәсе, шәрә хатыннар, шәрә ирләрнең андагы сурәтләре, сыннары дөньяның мәдәни хәзинәсенә әйләнгәннәр. Алар классика имеш. Алар — эталон. Аларга тел тидерергә ярамый, тел тидерсәң, син надан һәм ахмак имеш. Шулайдыр. Алар чынлап та сәнгать әсәрләредер.

Ләкин ни өчен мин аларга табынырга тиеш әле? Аполлонның ике бот арасындагы чәчәге белән Афродитаның мәрмәрдән уелган имие ни өчен миңа үрнәк булырга тиешләр? Грекларда, римлыларда шәрәлек, бәлки, матурлык, инсафлык үрнәгедер, ә шәрекъ затыннан булган татар күңеле аны кабул итеп бетермидер. Ирләрнең һәм хатыннарның кайсы җирендә нәрсә барлыгын татар да белә, әмма аны күрсәтеп мактануны ул хайванлык дип бәялидер. Шулай булгач, Аполлонның нәмәрсәсе белән нигә минем күзгә төртергә?..

"Сезне "Идел" журналының элекке "Коммунист" журналына әйләнеп баруы борчымыйммы?.. Халык юләр түгел, түрәләрне мактап алар турында язмасагыз иде..." *— күптәнге укучыбыз һәм авторыбыз Тәфкил Нургалимов хатыннан бу. Моңа охшаш шелтә сүзләре башка укучыларыбыздан да килгәли.*

Республика районнары белән таныштыра торган "Илкәем-илгенәм" сәхифәсе — "Идел" үзе тикшереп, үз исеменнән чыгара торган сәхифә түгел. Анда район турында, үз эшләре турында район һәм оешма җитәкчеләре үзләре сөйли. Ошамый икән, укымаска гына киңәш итә алабыз. Ләкин "күп мәгълүмат табабыз", дип язучылар, сәхифәгә "бишле", хәтта "алтылы" куючылар да бар.

Нинди заманда яшәгәнебезне онытмыйк, җәмәгать. Сез, рәхмәт төшкерләре, ай саен журналны алып, шулай безне тирги-тирги укыйсыз икән, бу инде үзе үк могҗизага тиң эш.

Ашаган белми, тураган белә, ди. Әйдәгез, бергәләп турап карыйк. Сез (һәрхәлдә, Татарстандагылар) "Идел"гә ярты елга 37 сум түләп язылдыгыз. Ә бит журналның бер нөсхәсе 20 сумга баса. Димәк, 6 сан 120 сумлык (почта чыгымнарын искә алмаган килеш тә) була. Әгәр дә мәгәр шул хакка язылырга риза икәнсез, яисә журналны яшәтүнең бүтән юлларын күрсәтәсез икән, ул чагында сез дә журналда ул "тук чырайларны" (бер укучыбыз сүзе) күрмәссез, безнең тук ук булмаган чырайларга да, ниһаять, елмаю иңәр.



Марс Мөсаллим улы Миңлебаев,
җаваплылыгы чикле "Чистай" ширкәте директоры.

— Малай чакта каз көткәнем бар. Казларны чыбыркы белән дә, таяк белән дә борып булмый, үз туксаннары туксан, кая телиләр, шунда баралар, ашыксалар — очалар. "Идел" журналына да "каз холкы" телим...

Сафуан Мәһәсим улы Хаҗиев,
"Баулынефть" идарәсенең "Березовский" ярдәмче хуҗалыгы директоры

— Нигәдер миңа "Идел" авылда туып үскәндер сыман тоела. Мөгаен, әсәр-язмалары күбрәк авыл хакында булгандыр.

Җирдән ерагая, шәһәрләшә күрмәгез. Киләчәктә дә сез үстергән мул уңышны безгә урып-җыярга язсын.

Хөрмәтле укучылар!
Хәтерегездәдер әле, 1993 елны "Идел" журналы күмәкләп иҗат ителгән "Арысланнар араны" исемле гасыр романы бастырган иде. Шул шаян традицияне дәвам итеп быел да дүрт язучы — Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Ләбиб Лерон, Марат Закир гасыр бәяне "коеп куйдылар". Бу бәянне икеләтә игътибар белән укырга кирәк: кайсы бүлекне кайсы автор иҗат иткәнен белә алсагыз һәм иң беренче булып дөрес җавапны безгә юлласагыз, "Идел" журналына ярты еллык абунә белән бүләкләнерсез.



Әйтерхан чиләвеге

Гасыр бәяне

Фәлән ФӘЛӘНОВ

Бүләк яхтаның төбен карамыйлар

Ләбиб Лерон төш күреп ята иде. Саташа да иде бугай. Саташуын шуннан чамаларга мөмкин иде: әле боргалана, әле ятагыннан торырга итә, әле ниндидер сүзләр быдырдый, кайбер сүзләре аңлашылган да сыман... "Чайкала! Чайкала!" диме, әллә "Чайпала! Чайпала!" диме шунда. Хәер, ул күргән төшне син күрмәгәч, аның нидән гасабиланганын каян беләсең инде...

...Мөштәри урамындагы Язучылар йортында урнашкан "Салават күпере" журналханәсенә Ләбибнең, гадәттәгечә, эшкә килеше имеш... Гадәттәгечә, таң тишегеннән. Ул шулай өйрәнгән: бүлмәдәшләре килеп җиткәнче язасы-сызасы эшләрне әтмәлләп өлгерергә тырыша. Гадәттәгечә, Язучылар йорты ишегалдында аны җанлы киез катаны хәтерләткән биш-алты карасары әнчек, рәхәтләнеп чәңгелдәргә дип, түземсез-

ләнеп, дүрт күз белән көтеп тора... Әкият-мәкиятләрендә сөеп-яратып язгаласа да, Ходай биргән гомерендә эт-фәләнне җене сөймәгән Ләбиб, әнчекләргә ыргытырдай ризык-мазары булмаган буш кесәләрен капшаштыргалап, гадәттәгечә шүрли-шүрли генә аякларын алга таба кыймылдата. Гадәттәгечә, беркөнне сакаллы, икенче көнне сакалсыз килгән бу саран адәмнән сыңар ипи валчыгы да тәтемәячәген өч көн алдан сизенгән "киез каталар", җирдән метр ярым өскә сикергәли-сикергәли, Ләбиб мескенне һәр яктан кысрыклап та өлгергәннәр... Гадәттәгечә, "киез каталар"ның бер сыңары — үтә дә явызы, Мәдинә Маликова фондына ярдәм сорап килгән бер түтәйнең һәм "Салават күпере" журналханәсенә сугылган рәссам Юрий Денисовның Язучылар йортына бүтән мәңге аяк атламаслык итеп ботларын тешләгәне, галәмәт тәнык әсәренә, әшнәләренә карап ымлый: "Менә миннән, абзагыздан үрнәк алыгыз!" — дигәндәй, сальто-мальтолар да ясап ала, имеш...

Өеннән тәм-том ташып әнчекләрне үзенә ияләштергән Тетя Гашаны исенә төшерә дә Ләбиб: "Тетя Гашага әйтеп, иманыгызны укыттырам мин сезнең, сабакылар!" — дип уйлый...

Бу мизгелләрдә Ләбиб фәкыйрьнең хәл-әхвәле бүтән көннәргә караганда да аяныч, имеш... Шулчак искитмәле хәл була... Әле генә гайрәт чәчеп адарынган әнчек тәреләр, бата башлаган карабтан котылырга теләп чабышкан күселәрдәй, кайсы-кая шыла, югала. Хәвеф-хәтәрсез котылуына сөенергә дә, җиңел сулыш алырга да өлгермәгән Ләбиб, Язучылар йортының сул канатында урнашкан "Идел" журналханәсе бинасына карап, кинәт, янә шүрләп, баскан урынында катып кала имеш...

Башта иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып, пышылдатып, аннары кычкырып җибәрә Ләбиб:

— Чайкала! "Идел"ләр чайкала!

Чыннан да, "Идел" журналханәсенең бинасы, көчле штормга юлыккан җилкәнсез карабтай, уңга-сулга чайкала имеш...

— Чайкала-а-а! Чайкала-а-а!..

Ләбиб әле бармаклары, әле йодрыклары белән күзләрен угалый, "Бәлки төш кенәдер, өн түгелдер бу?!" — дип уйлый имеш...

Күзләрен бер ачып, бер йомып карый — бина чайкала... "Әллә үзем чайкаламмы соң?" — дип уйлый, имеш, Ләбиб. Гәүдәсен, кул-аякларын тотып карый — юк, үзе чайкалмый шикелле. Ләбиб, үзе чайкалмаганга сөенеп, бинага карый — чайкала бина, чайкала, нәгаләт!

— Яп-яланаяк! — дип кычкырып җибәрә Ләбиб. — "Идел"ләрнең Бурсык исемле сөекле мәчеләре шундадыр бит?! Җыештыручы Мәйсәрә апа килгән булса, ул да тәгаен шунда?!

"Коткарырга кирәк үзләрен!" — дип уйлый Ләбиб. Ул, өтәләнеп, өч-дүрт адым атлый да, икеләнеп дигәндәй, туктап кала. "Мәче ул, хәвеф-хәтәрне сизеп, алдан ук бәла буласы җирдән тая торган җан иясе, — дип уйлый-фараз кыла Ләбиб. — Хатын-кызга килгәндә... Алар любой положениедән чыгу җаен табалар... Тем более Мәйсәрә апа... Димәк, ноу проблем!"

Ләбиб, авыр мәсьәләне җиңел чишкән өченче сыйныф баласы шикелле куанып, канәгать елмаеп, тирә-юньгә карап ала... Шуннан соң ул:

— *Идел бит ул, Идел бит ул,*
Идел бит ул, киң бит ул... — дип, җеге-җеккә килмәгән ниндидер бер ят көй көйли-көйли, милли төсебез булган яшелнең яшелсезенә буялган тимер ишекне акыртып елата-елата ача да Язучылар йортының эченә уза имеш...

...Ләбиб, үткән-сүткән һәрбер кеше борылып карап китә торган тәрәзәсеннән тыштагы әнчекләргә йодрыгын күрсәтте дә, кулкуйгычының почмак башы ашалып беткән кәнәфиенә чумәште. "М-м-да-а, бүген күргән төшне нигә юрарга икән инде?" — дип уйланды ул. Шактый уйланды.

Шуннан соң Ләбиб, җитди бер карарга килгәндәй, урыныннан торды да "Идел"ләрнең хәл-әхвәлен белергә ашыкты...

* * *

...Әчтерхан каласыннан көтмәгәндә килеп ирешкән телеграмма-хәбәр "Идел" журналханәсендә эшләүче барча хезмәткәрне гаҗәпкә калдырды. "Хөрмәтле дуслар! "Идел" журналының чыга башлавына ун ел тулу уңаеннан әчтерханлылар сезгә яхта бүләк итә. Игелеген күрегез. Яхта бүген Казан елга портында булачак!" — диелгән иде әлеге телеграммада.

Куанычның иге-чиге юк иде. Һәркемнең яхтаны тизрәк барып күрәсе килә. "Журналханәнең көндәлек эшен җәһәт кенә тәмамлыйбыз да елга портына китәбез", дип мәш килеп, ашыгып-кабаланып йөргән арада хезмәттәшләре Әчтерхан кызы, баш мөхәррир урынбасары Роза Кожевникова-Баубекованы да мактап, аңа рәхмәтләр яудырып алырга онытмадылар. Моңарчы үзләрен Роза еш авыз иттергән Әчтерхан балыкларын да, шомырттай эре кара уылдыкларны да искә төшерделәр.

Баш мөхәррир Рашат Низами да, форсаттан файдаланып, Розага коллектив исеменнән рәхмәт әйтте.

— Заманалар әйбәтләнеп, хезмәт хакларын вакытында ала башлагач, шактый күләмдә акчалата бүләк тә бирербез әле бәлки үзеңә, — диде ул, сүзләрен кулларының кискен-кискен хәрәкәтләре белән җөпләп-куәтләп.

Көчле кул чабулар ташкыны астында үзләренең дә Әчтерханда тумаганнарына кайберәүләр эчтән генә үкенеп куйды.

— Рашат Мияссәрович, акчалата бүләк бирү турында дөрес әйттегез. Роза моңа бик лаек! — дип баш мөхәррирнең сүзләрен гамәли хезмәткәр Тетя Гаша да җөпләде.

— Фикерегез өчен рәхмәт, Гәүһәрия апа. Хәзер мин ашыгам, эшем күп. Барып киләсе җирләр бар, — диде баш мөхәррир. Аннары ул үзенең беренче урынбасары Рәфикъ Юныска карап эндәште:

— Рәфикъ, елга портына баруны оештыра торыгыз. Мин хәзер кайтам. Гәүһәрия апа, Рәфикъка оештыру мәсьәләләрендә булышырсыз, яме.

Рәфикъ Юныс: "Ярар, Рашат, оештырырбыз", —

димәкче генә иде, Тетя Гаша-Гәүһәрия өлгеррәк булып чыкты:

— Барысын да уңай хәл итәрбез, Рашат Миясәрович. Борчылмагыз, Рәфикъ Юнысович белән бергәләп оештырырбыз! Шулай бит, Рәфикъ Юнысович!

Баш мөхәррирнең беренче урынбасарына:

— Әйе, шулай, Гәүһәрия апа, — диюдән бүтән чара калмады...

Рашат Низами китүгә, хезмәткәрләр янә тыз-быз килә башлады.

Тетя Гаша "Ләис, Ләис!" дип, коридор башында Марат Закир белән сигарет төтәтә-төтәтә, көлешә-көлешә гәпләшеп торган Ләис Зөлкарнәйне эзләп китте...

— Нишләп тыз-быз киләсез? Бер-бер хәл булмагандыр бит? — дип сорады "көфер почмагы"на Тетя Гашадан алдарак килеп җитешкән Ләбиб Лерон. Ул янә үзенең кечәге төшен искә төшереп алды.

Марат Закир "Безгә...", Ләис Зөлкарнәй "...яхта..." дияргә өлгермәде, Тетя Гаша, Ләбибкә илтифат итмичә генә Ләискә карап:

— Сөйләшеп торырга вакыт юк, Ләбиб. Бүген безгә Әчтерханнан яхта хәтле яхта килә. Бүләк итеп җибәргәннәр! — диде. Аннары Ләбибкә карап Ләискә дәште:

— Сөйләшәсе сүз бар иде, Ләис. Әйдәле, Азнакайдан факс...

Ләис, әле генә кабызган сигаретын чүп савытына ташлап, Тетя Гашага иярде.

Аңлашылды. Ләбибкә төш юрыйсы калмады.

Бу вакытта Рәфикъ Юныс җаваплы сәркәтип Роза Шәрәфиева бүлмәсендә, журналның яңа санына нинди язмалар җитешмәве белән кызыксына иде. Аннары ул бүтән бүлмәләргә кереп, хезмәткәрләргә таләпчән фәрманнарын биреп чыкты. Шуннан соң ул елга портына бару мәсьәләсен хәл итәргә кереште...

Баш бухгалтер Альберт Сөләйманов бүлмәсе тирәсенә якын килерлек түгел иде. Бүлмә эчендә дә, коридорда да акча-фәлән, гонорар сорап йөрүчеләр мәш килә. Баш бухгалтер: "Акча юк бит әле. Барасы җир бар иде", — дип тәкърарлап торса да, берсенең дә китәсе килми, барыбер нәрсәдер өмет итәләр.

Элекке даһи юлбашчыбыз Ленин берьюлы әллә ничә эш башкарырга сәләтле булган, диләр. Хактыр. Моның шулай икәнлегенә Альбертка карап та ышанырга мөмкин. Кайчан күрсәң дә, аның бер колагында телефон булыр: үзе сөйләшә, үзе нидер яза, үзе йомыш белән керүчене тыңлый, елмая. "Бензинга да акча юк", — ди, гамәли хезмәткәр Резидә Әхмәтҗанова әзерләп алып кергән ниндидер исәп-хисап кәгазьләренә кул куя...

"Идел"нең баш рәссамы Фәридә Хәсъянова җаваплы сәркәтип белән Рәфикъ Юныс бүлмәсенә кереп чыкты да, чираттагы сан өчен бик тә ашыгыч кирәк булган фотосурәтләрнең кайдалыгын белергә теләп, кемнедер эзләп китте. Кемнедер дип... Әлеге дә баягы Ләисне инде... Азнакай спонсорларының фотограф Альберт Тәхәвиев төшергән сурәтләре бары тик Ләистә генә булырга тиеш!..

Һәрчак ашкынган, ашыккан Ркаил Зәйдулла эшкә төш вакытында ук кабаланып килеп җитте дә төгәлләнеп бетмәгән күләмле бер язмасына тиз генә нокта куйды. Шуннан соң эшкә килешли киосктан сатып алган калын бер гәҗитне тәмләп йотарга тотынды.

Озак вакыт та үтмәде, коридорда пәйда булды ул.

— Елга портына кайчан барабыз? — дип сорады Ркаил Рәфикъ Юныстан.

— Рашат кайтуга китәбез, Ркаил. Монда гына бул! — диде баш мөхәррирнең беренче урынбасары.

— Әйтергә онытмагыз, — диде Ркаил һәм коридор башында тәмәке көйрәтүчеләр янына таба атлады. Берәздән аның яңгыравык вә көчле көлү тавышы ишетелде.

— Ркаил, әллә кичә үк килгән идеңме эшкә? — дип каршы алды аны Ләбиб.

Журналханәнең Бурсык исемле мәчесе Ркаил Зәйдулланың көлү тавышыннан исәңгерәпме, әллә башка сәбәп беләндерме, кай тарафка барырга белмичә, үрсәләнеп йөри-чаба башлады...

Ниһаять, баш мөхәррир Рашат Низами, ашыгыч эшләрен тәмам хәл итеп, журналханәгә кайтып җитте.

— Барыгыз да әзерме? — дип сорады ул, үзен түземсезләнеп көтеп торучылар-

ның һәммәсенең дә терекөмештәй ялтыраган күзләренә җәһәт кенә карап.

— Әзер, Рашат Мияссәрович, барыбыз да әзер. Ләис тә, Марат Закир да, Нәгыйм дә монда. Ркаил да монда инде! — дип һәммәсе өчен дә җавап бирде Тетя Гаша.

Тетя Гашаның аякларына сырпаланып торган Бурсык, "Ркаил" исемен ишетүгә, бер як читкә тайпылды да як-ягына каранып алды.

— Яхшы. Киттек алайса, — диде баш мөхәррир. — Тик, җәмәгать, үзегез беләсез, барыгыз да "Волга"га сыймаячак. Альбертның "Нива"сына да өчегез генә эләгер. Калганнарыгызга үз хутыгыз белән барырга туры килер. Рәфикъ, Гәүһәрия апа һәм Фәридә, әйдәгез, сез — "Волга"га! Кампитрчы кызларыбызга "Волга"ны кире җибәрәм. Калганнарыгыз үзара хәл итегез. Елга портында очрашырбыз. Киттек!..

Киттеләр. Ркаил Зәйдулладан кала барчасы да елга портына килеп җитте. Ркаил Язучылар йорты китапханәсенә яңа гәҗит-журналлар алырга дип килгән язучы Ризван Хәмид белән сөйләшеп калган булып чыкты.

Бераздан аларның да килгәннәре күренде.

— Менә, син, Ркаил, "тибен тибү" дигән сүзләрне ничек аңлыйсың? — дип сорады Ризван Хәмид һәм, "белмисең" дигәндәй, хәйләкәр елмайды.

— Ха! — диде Ркаил. — Кар астыннан тибенеп үлән табу! Шул мәгънәне аңлатамы?

— Беләсең икән, афәрин! — диде Ризван Хәмид.

— Белмәскә! Ә менә син, Ризван абый, әйтеп кара: "көчегән" нәрсәне аңлата?

— Бөркет! Дөресме?

Икесе дә дәррәү көлеп җибәрделәр.

Алар үзләрен көтеп торучылар янына килеп җиткәннәр иде инде.

— Безнең яхта кайда соң? — дип сорады Ркаил янәшәсендә басып торган Рәфикъ Юныстан.

— Күрмисең мәллә? — диде Рәфикъ Юныс, башы белән күк йөзенә таба ишарәләп.

Күк йөзендә эленеп торган галәмәт зур вертолет трослар белән эләктерелгән яхтаны порттагы махсус җайланмага төшереп куярга азаплана иде.

— Әчтерханнан ук шушы вертолет алып килгән, — дип әйтеп куйды Нәбирә Гыйматдинова, белмәсәң — бел дигәндәй.

Шулай диде дә Нәбирә, өенә кайткач яза башлыйсы яңа повестенең сюжет-эчтәлеге хакында уйлануын дәвам итте.

— Әчтерханнан су аша гына кайтып була бит югыйсә. Нәрсә, әллә төбе юкмы яхтагызның? — диде Ризван Хәмид, Ркаилгә карап.

— Мин каян белим. Синең белән әле генә бергә килдек бит, — диде Ркаил.

— Төбе бар икәне күренә, — диде Марат Закир, йөзенә бик белдекле кыяфәт чыгарып. — Бик җиңел сыман әле бу яхта, мотор табарга туры килмәгәе!

— Мотор гына табасы булса — ерунда! — дип сүзгә кушылды Нәгыйм Шаһи. — Минем бер таныш бар. Әйтсәң, моторны җир астыннан табып бирәчәк.

— Аңа бит акча түлисе буладыр? — дип сораулы карашын Нәгыймгә текәде баш бухгалтер Альберт Сөләйманов.

Нәгыйм сәерсенеп аңа карады:

— Менә тиле! Бушка кем бирсен инде сиңа мотор хәтле мотор!

— Егетләр, сөйләшмәгез әле! — дип кискен генә әйтеп куйды Рашат Низами.

"Да-а, — дип уйлана калды баш бухгалтер, — кайдан акча табасы булыр инде?"

Ниһаять, ничек итсә итте вертолет, тәки яхтаны махсус җайланмага куя алды.

— Яхтасы ярыйсы гына күренә моның, — диде Рәфикъ Юныс.

— Сез бик дөрес әйттегез, Рәфикъ Юнысович, — диде Тетя Гаша, яхтадан күзләрен алмыйча гына.

— Эченә кереп карамыйча берни дә әйтеп булмый әле, җәмәгать! — диде баш мөхәррир.

— Сез дә бик дөрес әйттегез, Рашат Мияссәрович! Эченә кергәч, бөтенесе дә күренә инде аның, — дип, баш мөхәррирнең сүзләрен хуплады Тетя Гаша.

— Май чүлмәге тышыннан билгеле! — диде Ркаил һәм портны яңгыратып янә көләргә тотынды...

Вертолет китәргә дә өлгермәгән иде әле, әллә каян гына шагыйрь Мөдәррис Әгъләм килеп чыкты.

— Моны кеше итәргә була әле! — диде ул, яхтага бер күз төшереп алуга.

— Кеше түгел инде, Мөдәррис абый, яхта диегез! — диде гамәли хезмәткәр Гөлсинә Хәмидуллина, кулындагы көрән сумкасы эченнән нидер эзли-эзли.

— Барыбер инде, — диде Мөдәррис Әгъләм, — йөзәргә өйрәтсәң, кеше дә йөзә, вакыты җиткәч, яхта да үлә!..

Һәммәсе яхта янына ук якын килде. Яхтага орынгалап, кагылгалап алдылар, астын тикшергәләделәр, өстенә менделәр, анда-монда кереп чыктылар.

Җентекләп тикшерә торгач шул ачыкланды: чыннан да, яхтада мотор дигән нәмәрсәкәй юк икән! Шулай да, байтак кына прибор-мрибор, шөреп-мөреп юклыгын, ишектер-утыргычтыр ише нәрсәләрнең җитешмәгәнлеген, берничә урында тишек-мошык барлыгын, буярга-сыларга туры киләчәген исәпкә алмаганда, яхта үзе карап торышка күркәм тәэсир калдырырлык иде.

— Пиратлар эше бу! — дип нәтиҗә ясады Мөдәррис Әгъләм.

— Яхтаны вертолет алып килде бит! — диде Рашат Низами, Әгъләмнең нәтиҗәсе белән килешмичә.

— Алайса һава пиратлары кыланган инде монда! — диде Мөдәррис. — Хәзер бик нык азындылар алар... Күзгә күренмәгән нәрсәләрне дә чәлдерергә генә торалар...

— Пиратлармы, караклармы, барыбер монда алып килгән чакта талаганнар инде, — диде Тетя Гаша.

Тетя Гашаның сүзләре белән барысы да килешергә мәҗбүр булды. Дөрес, Мөдәррис Әгъләмнән кала һәммәсе дә дип әйтергә кирәк. Чөнки аның күпчелеккә каршы һәрчак үз фикере була.

— Иртәгәдән үк яхтаны рәткә китерергә тотынабыз,

җәмәгать, — диде Рашат Низами. — Кирәк-яраклар табу турында сез дә уйлагыз, эшләрем күп булса да, мин үзем дә уйлармын!.. Эштә кешеләр калдырмыйча булмый. Шуңа күрә, яхтага чиратлашып килербез. Оештыру эшләре, Рәфикъ, синең карамакта. Мин контрольдә тотармын...

— Яхшы. Аңладык! — диде Рәфикъ Юныс.

— Борчылмагыз, Рашат Мияссәрович. Менә дигән итеп башкарып чыгарбыз, — диде Тетя Гаша.

"Акча каян табасы булыр инде", — дип борчыла башлады баш бухгалтер һәм тиз генә телефон трубкасына сузылды. Ләкин һавада телефон юк иде. Акча турында гына уйлап башы каткан Альберт, ялгышканын аңлап, һавада эленеп торган кулын җәһәт кенә кәчтүм кесәсенә яшерде.

... Икенче көнне яхтада кызу эш башланды. Егетләр шөреп-мөреп борырга, тишек-мошык ямарга тотынды, кызлар кырасы урыннарны кырырга, сылыйсы җирләрне сыларга кереште.

Рәфикъ Юныс хезмәткәрләргә киңәш биргәләп йөри, үзе дә әле бер эшкә, әле икенче эшкә барып тотына.

Күп тә үтмәде, яхта янына бер үзбушаткыч "КамАЗ" килеп туктады. Кабинадан әлеге дә баягы Мөдәррис Әгъләм килеп төште. Аның артыннан ук Тетя Гаша пәйда булды.

— Кирәк-яраклар алып килдек, — диде Тетя Гаша һәм шоферга йөкне бушатырга кушты.

Кайда кемдер дача төзи, кайда кайсыдыр мунча сала, шунда Мөдәррис Әгъләм булыр. Менә бит, иренмәгән — яхтаны рәткә китерешергә дә килеп җиткән.

— Алла ярдәм бирсен! — дип кычкырды ул яхтадагыларга, ничектер өстән аска карап.

— Рәхмәт! Үзеңне дә монда бирсен! — диештеләр яхтадагылар.

"КамАЗ" калай ише, такта-мазар шикелле әйберләрне, ишек-урындыкларны бушатты да китеп тә барды.

— Мотор алып килергә китте, — диде тетя Гаша.

— Ул хәтле калай нәрсәгә? — дип кызыксынды Ркаил Зәйдулла.

— Яхта төбәсен киңәйтеп, әйбәтләп ябасы булыр, — диде Тетя Гаша. — Аннан соң яхтада "Волга"ны куярга да урын әзерләргә туры киләчәк. Рашат Мияссәровичка яхтада йөзгәндә Казанга кайтып килергә машина кирәк булачагын гына чамалыйсыздыр инде?

— Аңлашылды, — диде Ркаил. — Калай эше — Ләис белән безнең эш. Студент чактан ук шабашкаларда фермаларга калай түбә ябып юкка гына йөрмәдек. Ләис, тотындык түбә ябарга!

Алар калай ташыган арада Мөдәррис Әгъләм бүтәннәргә үзенең эшлекле киңәшләрен, күрсәтмәләрен биреп чыккан иде инде. Техниканы күреп үскән Марат Закирны шөреп сүтәргә, Нәгыйм Шаһины тишек-мошык ямарга өйрәтте. Марат белән Нәгыйм аңа рәхмәт әйттеләр дә, соңга калмагаек дип, калай ташучылар янына ашыктылар. Ярты сәгать дигәндә калай ташылып бетте.

— Ләис, баягынак калай күп күренгән иде, хәзер нишләптер аз тоела, — диде Ркаил.

— Минем дачам да, йортым да юк, Ркаил, — диде Ләис, бер кәкрәйгән калайны куллары белән турайтырга азаплана-азаплана.

— Бик борчылма, синеке дә булыр әле, — дип тынычландырды аны Нәгыйм.

— Ләискә берәү генә җитми аңа, өч-дүрт кирәк. Шулай бит, Ләис. Кыстати, каяле, бер тәмәке бир әле, — диде Марат, тузанга, калай тутыгына баткан кулларын кайда сөртеп алырга белмичә.

Ркаил хәлиткеч мизгелләрдә генә файдалана торган мәгънәви вә фәлсәфи күз карашын әле Маратка (ул җитди йөзенә битараф төсмер өстәп тыныч кына сигарет төтәтә иде), әле Нәгыймгә (ул бераздан барыбер тузанга тиенәчәк ботинкаларын нигәдер өрянә кульяулыгы белән сөртеп-чистартып азаплана иде) ташлап алды.

Ничек итсә итте Ләис, тәки җәфа калайны турайтты. Ркаил ул турайткан калайга нәүмизләнеп калган карашын төбәде. Әлеге караштан "Минем дә дача бар иде бит югыйсә. Түбәсез сарайны әйткән дә юк. Хәтерсез баш!" дигән уфтанулы уйларны укырга була иде...

Ул арада Мөдәррис Әгъләм яхта тирәсендә йөрийөри, аның астына кергәләп-чыккалап, бераз яткалап алып, Рәфикъ Юныс белән үзара бәхәсләшеп тә өлгерде.

— Яхта капитальный ремунттан соң ялт итеп торырга тиеш! — диде Мөдәррис.

— Аны син әйтмәсәң дә беләм мин! — диде Рәфикъ Юныс.

— Белгәч соң! Яхтаның астын күптән буяп куярга кирәк иде инде. Суга төшкәнче кибә торырга тиеш!

— Анда бер тишек бар. Шуны ямарга кирәк әле башта!

— Тишекне аны теләсә кайчан ямап була! — диде Әгъләм.

Алар, бәхәсләшә-бәхәсләшә, янә яхта тирәли йөри башладылар...

...Яхтадагы эш җитез генә башланса да атна-ун көнгә сузылды тагы. Инде эш бетте бугай дигәндә, әле тегесе, әле монысы кирәк булып чыга торды.

Менә, ниһаять, эшкә нокта куяр көн килеп җитте. Өр-яңа кебек балкып ялт итеп торган яшел түбәле яхтага матур, затлы исем генә табасы калды.

— "Иделлия" дип атыйк, — дип тәкъдим итте Ләис Зөлкарнәй. — Шигъри исем! "Идел" дигәне "Идел" журналыннан икәнлегебезне дә искәртеп торачак!..

— Тагын кемнәрдә нинди тәкъдимнәр бар? — диде Рашат Низами. — Бәлки "Идел" генә дияргәдер?!

— Уйлашыйк әле, җәмәгать, башка яхшырак исем табылмасмы? — диде Нәбирә Гыйматдинова, языласы повестеның тагын бер җөмләсенә нокта куеп. — "Идел" үзе начар исем түгел дә түгелен... Әмма без ул исем белән еш мавыгып, аның тәмен җибәрмик. Кинотеатр да шул исемне йөртә, ашамлык-эчемлек кибете дә, фильтрсыз сигарет та, сыра да, төнге клуб та...

— Бәлки "Казан" дип куяргадыр? Ни әйтсәң дә, үзебезнең бердәнбер башкалабызның исеме бит... — диде Гөлсирә Гайнанова.

Бик озак бәхәсләшә-фикерләшә, киңәш-табыш итешә торгач, уртак бер фикергә килделәр "Идел" хез-

мәткәрләре: яхтаны "Иделлия-Казан" дип атарга булдылар.

Бераздан яхтада әлеге сүзләр балкый иде инде.

— Җәмәгать, — диде шуннан соң баш мөхәррир, һәммәсенең игътибарын үзенә җәлеп итеп. — Хәзер мин сезгә куанычлы хәбәр әйтәм. Без кайбер иптәшләр белән сөйләшкәннән соң, шундый карарга килдек: ике көннән, ягъни дүшәмбе көнне Идел буйлап сәяхәткә чыгабыз!

"Ур-р-ра" диешеп, барчасы дәррәү кул чапты. Хәтта Мөдәррис тә. Бу юлы аның фикере башкаларныкы белән уртак иде.

— Тик, җәмәгать, тагын шунысын да әйтәм: без сәяхәт вакытында ял гына итмәячәкбез, эшләячәкбез дә. Мөдәррис, сиңа да эш табарбыз. Яхтада эш өчен барлык кирәк-яраклар да булачак. Кәгазь-каләм һәм язу машинкалары турында әйтеп тә тормыйм. Сәяхәттән без журналның махсус санын, юбилей санын эшләп кайтырга тиешбез. Аңлашылдымы барыгызга да? Аңлашылса, дүшәмбе көнне яхтада очрашабыз! — диде Рашат Низами...

* * *

...Дүшәмбе көнне "Идел" хезмәткәрләре барысы да бәйрәмчә киенеп килгән иде. Ркаил хәтта малае Баязитны да иярткән. Баязитны күргәч, баш мөхәррирнең сөмсере коелды, әлбәттә.

— Син нәрсә инде, Ркаил, — диде ул. — Әйттем бит инде, без ял итәргә генә түгел, эшләргә дә барабыз...

— Комачауламый ул, — дип акланды Ркаил. — Аннан соң мин аны кайда калдырыйм. Хатын таң белән эшкә китә, төнгә таба гына кайта. Балалар бакчасына кем алып барсын да кем алып кайтсын Баязитны. Артыксынсагыз калабыз алайса...

Рашат Низами йомшарды.

— Ярар, әйдә, барсын! — диде ул. — Кайда соң әле Баязит? Кая югалды?

Ркаил як-ягына карап алды да:

— Яхтага кереп тә киткән инде ул ташбаш малай! — диде.

— Ну, малай! Ну, Баязит! — диде Рашат Низами, башын чайкап. Шуннан соң ул җыйналып торучыларга эндәште:

— Затлы яхтабызга утырыштык, җәмәгать! Хәерле сәгатьтә!

...Яхтадагы "Иделлия-Казан" дигән язудан "н" хәрефе сәяхәт башында ук төшеп калачагын, Ркаилнең малае Баязитның шактый шуклыклар эшләячәген, үзләрен күп төрле маҗаралар көткәнен "Идел"дәшләр үзләре белми иде әле...

Фәлән ТӨГӘНЕВ

Ике җәпле әләм астында

Берничә көннән өр-яңа диярлек яхта Казан суы өстендә чайкалып тора иде инде. Мөдәррис Әгъләмов аңа карап тел шартлатып алды да бер мәлгә хатирәләргә бирелде:

— Моннан нәкъ унҗиде ел да өч ай элек мин шушындый көймәдә Әлмәткә йөзеп барган идем...

Марат аңа гадәттәгечә каш астыннан яратып карады:

— Әйдә, әкә, безнең белән Әчтерханга. Гаптери әйтмешли, бер яшьлектә, бер картлыкта...

Мөдәррис Әгъләмовтан пышт иткән тавыш чыкты. Тартылып беткән "Идел" тәмәкесе аның юеш иренендә шулай сүнгән икән. "Мокыт та мокыт, син дә мокыт", — дигәндәй ул фәлсәфи елмаеп куйды.

— Сез бит Әчтерханга түгел, Алтын Урданың башкаласы Сарай хәрабәләренә барасыз. Равил Фәхретдинов Чыңгыз хан Ясагыннан аның тәгаен урынын тапкан. Анда инде алты-ын... Борынгы кулъязмалалар... Сер итеп кенә әйтәм, аны сезгә тишәргә кушмаганнар иде.

— Соң, шулай булгач, әйдә бергә барып казыйбыз!

— Әкәнең бит паспорты юк, — дип, Ркаил Маратның татлы тарихи хыялларын коры чынбарлык чылбыры белән бүлде. — Аны Сембер таможнясы ук тотып алачак. — Салих Маннаповтан сорап торырга кирәк, аның Мөдәррис исеменә тагын бер паспорты бар диләр...

— Безгә командировочный бирәләрме икән? — диде Марат пошынып.

Шул вакытта машина тавышы ишетелде. "Идел"нең "Волга"сы хәтәр сызгырып яр кырыена ук килеп басты. Җыелган җәмәгать "тагын бер *баш* харап була күрмәсен", дип сагаеп машина ишегенә карадылар. Аннан атылып Рашат чыкты.

— Сезгә рәхәт, ә минем гел эш тә эш, — диде ул еш-еш сулап.

— Командировочный буламы? — дип Ркаил аның сүзен бүлде.

— Сез генә белдекле, менә минем урынга утырып карагыз!

— Рашат Мияссәрович, сезнең "Кызыл кар яугач" дигән китабыгызны укып чыктым, — диде Гаша. — Укымаганда күздән яшьләр килә...

— Бер тиенсез юлга чыгып булмый бит инде, — дип акланды Ркаил. Үзе эчтән хәвефләнде: "Алла сакласын, кәнәфи тәкъдим итә күрмәсен тагын!"

— Барысы да алдан уйланылган, — дип четердәп сөйләп китте Рашат. — Һәркемгә илле тәңкә! Калганын кайткач алырсыз. Мин әйттем!

"Кара син, — дип уйлады Мөдәррис Әгъләмов. — Сарай хәрабәләренә кузгалмаган, ханнар кебек сөйләшә башлаган бу".

— Илле тәңкә белән Киров районына да кайтып булмый бит, — дип мыгырданып куйды Ләис.

— "Волга"га утырып кайтырга кирәк, — диде Рашат. — Ринат бушлай алып кайта. Үзегез белән консервымонсервы, токмач-мокмач алыгыз. Ашау турында азрак уйларга кирәк, без бит эшләргә барабыз. Әнә Рәфикътан үрнәк алыгыз.

(Дәвамы 36 нче биттә)

Бәйрәм җитә, бәйрәм! Безнекеләр нишләп ята икән соң? Дөньяны шаулатачак олуг мәҗлескә әзерләнеп, ашыга-кабалана ательеларга, чәчтарашларга йөгерәләрдер әле. А как же. "Идел"гә ун яшь тула бит! Ни, бала-чага икән әле дип кимсетмәгез, яме! "Идел" инде ул җитлеккән сабый: ә бер карасаң, йөзьяшәр карт төсле үтә дә акыллы, ә бер карасаң — шат күңелле яшь егет. Шуңадыр, ахрысы, төгәл генә аның яшен билгеләве дә кыен. Әмма ни-нәрсә генә булса да "Идел" дөньяга чыга һәм аны "безнекеләр" әвәләп чыгара. Ә "безнекеләр" шәп халык! Алар белән сез укучыларыбызны да таныштырыйм дип иртәнге җидедә үк эшкә чаптым. Баскычтан менгәндә безнең тарафлардан җыр ишетелде. Әллә бәйрәм репетициясе башланган да инде?! Уф, соңардым бугай дисәм, аллага шөкер, җыештыручыбыз Мәйсәрә апа моңлана икән. Ул, мөгаен, артист булыр, "Зәңгәр шәл"дә Мәйсәрәне уйнап сәхнәләр шаулатыр иде, безнең бәхеткә "Идел"дә эшли менә. Аның тормышы маҗаралар белән тулган. Бервакыт туган авылыннан Казанга килгәндә чүт бүре авызына эләкмәгән Мәйсәрә апабыз, күчтәнәчкә дип әнисе сумкасына тыккан йомыркаларны атып бетергән. Бүре йомырка ашамаганны каян белсен ди ул!

Ә беркөнне, минем бүлмәне җыештырырга дип ишекне ачуы була, гөпелдәп түшәм ишелеп төшә.

"Мин Ак йортта да идән юа алам, анда да мондый уңган хатыннар кирәктер, Клинтон коридордан узганда туфлиләрен юеш чүпрәк белән сөртеп җиффәрер идем", — ди Мәйсәрә апа. Кирәкми, Мәйсәрә апа, китә күрмә, син аларга әрәм. Әнә Моникалары белән чиләнсеннәр.

Бу уеңны ташла да, бәйрәм уңаеннан сүз әйт лутчы.

Мәйсәрә Якупова:

— Иртәнге сәгать 5 тә эшкә чыгып китәм. Барасым килеп барам, атлаган саен үкчәмнән очкыннар чәчри. "Идел"челәр килгәнче бөтен җирне ялтыратам. Барыгызны да яратам. Һәммәгез дә ачык йөзле, тәмле телле. "Идел" мәңге яшәсен!

Мәйсәрә апаның теләкләрен кәгазьгә теркәп тә өлгермәдем, компьютер бүлмәсен ачтылар. Мөнирәбез килде. Ул компьютер дизайнеры, Казанга Урта Азиядән кайткан. Һөнәренең остасы. Без аны бик яратабыз. Аеруча сабыр холкы өчен. Ә самбуса кебек тәмле таҗик ризыклары пешереп безне сыйлаганда бигрәк тә. Иренмәгез, Мөнирәдән рецептын сорагыз. Ул самбуса дигәннәре телеңне йотарлык. Ашаганда күздән яшьләр атыла (борыч күп салына чөнки). Заманында Мөнирә биек-биек тауларга менәргә яраткан. Ә хәзер таулар төшенә генә керә, хыял исә һаман яши.

Мөнирә Кузиева:

— "Идел"дә мин 5 ел элек эшли башладым. Шунда ук эшкә чумдым. Кызык иде, баш мөхәрриребез мәрхүм Фәиз Зөлкарнәй мактап, күңелне күтәреп тора иде. Сагынып искә алырлык көннәрем күп. "Идел" төпкә батмасын, һаман үссен, күтәрелсен иде.

"Амин" дидем мин, сәгатемә карап. Тугыз тулып маташа икән.

Коридордан җил-җил атлап баш мөхәррир урынбасары Рәфикъ Юныс үтеп китте. Аның тиз йөрүенә хәйран калырсың. Югыйсә "Идел"нең иҗат йөге — Рәфикъ абый җилкәсендә. Әгәр Рәфикъ абый бер-ике көн эшкә килмәсә, редакция халкы дилбегәнең бушаганын сизеп иркенәя-тарала, чәчелә-сибелә, бүртә-кабара, кыскасы, "Идел"нең сөяк-санакларын җыеп алуы шактый авырлаша.

Рәфикъ Юныс:

— "Идел"гә күчәсең икән. "Идел"гә барсаң, бөтең үзең белән булсын!" — Рабит Батулла миңа шулай дигән иде. 1985 елга хәтле гәҗиттә эшләдем мин. Бөтнең, ягъни коткару кругының кирәге юк иде. Сайда чупырдыйсың, тирәнгәрәк керим дисәң, "коткаручылар" юлны кисә, бик үҗәтләнсәң, көймәләренә үк салып алкитәргә мөмкиннәр.

Чын журналистик иҗат ләззәтен "Идел"дә татыдым мин. Акылың, йөрәгең әйтеп торганны, дөресне язасың, һәм ул — вәт могҗиза! — нәкъ шундый булып басылып та чыга.

"Идел"не милли журнал, дөреслеккә йөз тоткан журнал буларак саклап каласы иде. Шул ук вакытта аңа үткенлек, терелек, чаялык, шаянлык — яшьлек рухы да өсти төшәсе иде.

Төпсез диңгезне хәтерләткән "Идел" дә зур авызлы акулалар да йөзгәнен шәт сез беләсездер. Ул акулалар безнең вакыт дигән кадерле нәрсәбезне хап-хоп йотып бара. Язучы Рашат Низамиев журналның баш мөхәррире итеп билгеләнгәч, иҗат планнарын сөйләп көнләштергән иде. Баксаң, аның язылачы повесть-романнары бихисап икән. Ләкин нишләптер романнар күренми әле. Гаеп теге акулада түгелме соң? Баш мөхәрребезнең әсәр язасы вакытын шул капкорсак ашый, күрәмсең. Югыйсә Рашат Низамиевның "Беренче мунча"ларында чабынган себеркеләребез тузды инде.

Рашат Низамиев:

— Моннан 6-7 ел элек, мин яшьләр журналына "Беренче мунча" дигән хикәямне алып килгән идем. Анда яңа өйләнешкән ике яшь парның беренче тапкыр мунча керүләре бәян ителә. Әдәби хезмәткәр, әсәр белән танышып чыкканнан соң, кашын җыерды да кыска гына әйтеп салды:

— Биредә секс юк бит, туганкай...

Язмамны ирексездән кире алырга мәҗбүр булдым.

Хуш, вакытлар узу белән "Беренче мунча" дигән бу хикәя "Казан утлары"нда, аннары "Кызыл кар яугач" дигән китабымда басылып чыкты. Укыганнар, игътибар иткәннәр икән үзенә. Укыган берсе очраган саен әйтә:

— Ну, маладис, нәкъ минем хакта язгансың, чукынчык!

Бервакыт теге әдәби хезмәткәрне очраткач, әлеге бәяләмәләр хакында әйтеп ташладым. Ә ул, мыек астыннан хәйләкәр елмаеп, болай диде:

— Минем хакта язмагансың, туганкай, минеке бит бүтәнчәрәк килеп чыккан иде...

Компьютер бүлмәсе җанланды. Операторларыбыз Рушания, Гөлфия, компьютер дизайнеры Светлана сүзләр һәм сурәтләр дулкынында тирбәләләр. Без кызларны дүрт күз белән көтәбез, чөнки кульязмалар иң әүвәл алар кулыннан уза. Гөлфиябез — тыйнак, ягымлы, аз сүзле. Бер кимчелеге бар: кызлар чәй эчкәндә тукылдатып утыра. Хатын-кызга картаймас өчен тәүлегенә 4 литр су эчәргә кирәк, дигәнне колагына да элми.

Рушаниябез соңгы елларда гына "Идел" дулкыннарына кушылып акса да, коллективка атна-ун көн эчендә үк ияләште. Туры сүзле, ялагайлана белми. Җитез, кульязмаларны редакция песие Барсук пес иткәнче бастыра.

Гөлфия Хәйруллина:

— Эшемне күңел биреп эшлим. Төрле чаклар була. Бервакыт 40 битле кульязманы җыеп бетергәч, ялгыш "сөрттем". Тик утырырга вакыт юк. "Малыш" (Сергей Малышев), язмаларын бастырганымны көтеп, минут саен безгә керә. Әгәр урынымда булмасам, артымнан эзләп йөри.

Дәвамы 42 биттә

Әчтерхан чикләвеге

(Дәвамы. Башы 28 нче биттә)

Әле генә хакимият ашханәсеннән әчегән ботка ашап килгән вегетариан-кысыраш Рәфикъ бик тырышып Казан елга портын өйрәнә иде. Ул ахмак сүзләргә кушылып тормады, җәнлек күргән сунарчы кебек, өскә, яшелләнеп күренгән куакларга таба омтылды. “Мин яр буйлап кына барам, Сарытауда куып җитәрмен”, — дигән сүзләре генә ишетелеп калды. Аның озын араларга йөгерүен белгән “Идел”челәр сокланып тел шартлаттылар. “Хәзер штурвалга кем басар инде?” — дип профсоюз рәисе Гөлсирә генә моңсуланып калды.

Бер төргәк акчаны биш тапкыр санап һәркемгә иллешәр тәңкә өләшеп чыккач, Рашатның тавышы сүрелде.

— Эш муеннан, — диде ул. — Сез кузгала торыгыз. Машина белән куып җитәрмен. Мин әйттем! — һәм утырып каядыр китеп тә барды.

“Акча мәсьәләсендә нindидер этлек булды бугай”, — дип машинистка Рушания үзалдына сөйләнеп куйды. Ул кайчандыр хисапчылар курсын бетергән иде.

Казан суы өстендә Мөдәррис Әгъләмовнең хөр тавышы яңгырады:

Сез китәргә тиеш таңга чаклы!

— Карабны беренче тапкыр суга төшергәч, аңа шампан шешәсен бәреп ваталар, — диде һәр өлкәдә мәгълүматлы Ләис.

— Шампан хәзер кыйммәт инде ул кыйммәтен, — дип Ркаил кесәсенә тыгылды. — Җыелышырга кирәк.

Һәммәсе кесәләрен капшарга тотынды. Марат кына бер читкәрәк китеп басты. Бераздан, һәммәсенең үзенә төбәлгән күз карашын тоеп, Ркаилгә таба борылды:

— Бурычка биреп торалмыйсыңдыр, абзый?

— Соң, — диде тегесе гаҗәпләнеп, — әле генә Рашат илле сум биреп китте ич.

— Мин аны хатынга җибәрдем шул инде, — диде Марат. — Ике малай бар бит. Өйдә ач яталар. Син генә ул Баязитны үзеңнән калдырмыйсың.

Баягынак, болар юк-барны сөйләшкән арада, Марат почтамтны урап килгән иде инде.

Икесенең дә бабалары Чүтидә туганлыгын искә алып, Ркаил авыр сулады. “Бирмичә ярамас, акчасызлыгына караганда, зур шагыйрь булуы мөмкин”, — дип уйлады ул.

— Акча да кушмадың, яшьлегең дә бар, кибеткә син барасың инде.

Рәфикъ яр буйлап Осланга да җитмәгән иде әле, Марат кибетне урап та килде. Тик кулында шампан шешәсе түгел, “Чистай малае” иде.

— Шампан юк анда, — диде ул акланмыйча гына.

“Чумара эшләде!” — дип көнләшеп уйлады Нәгыйм.

— Бөкеле икән... — Ләис мәгънәле генә шешәне әйләндергәләде. — Башта без моны бушатыйк. Аннары су тутырып бортка бәрербез. Яхта һәрвакыт су өстеннән йөзсен, дигән мәгънә булачак.

Мондый матур мәгънәгә каршы килүче булмады.

Шешәгә су тутырганда телләр тагын да ачылган иде инде.

— Атлантида Идел астында калган булырга тиеш, — дип сүзгә кушылды Солтан Шәмси. Ул эзотерика белән шөгыльләнә иде. — Платонда моңа бер ишарә бар. Мин үзем дә шундый нәтиҗәгә килдем. Чөнки Атлантида халкы татар телендә сөйләшкән.

Мачтага бау белән тоташтырылган шешәне бортка томырдылар. Тик ул, ходайның хикмәте, ватылмады, ә корпуска батып керде.

— Монда да нindидер мәгънә бар, — диде Ләис.

Дөрес әйткән икән, ул шешә әле “Идел” командасын күп бәлаләрдән коткарачак.

— Безнең бит яхтага байрак эленмәгән! — Ркаил Зиннур Хөсниярдан алып торган бозау кадәр букчасын бер җилкәсеннән икенчесенә күчерде. Андагы консерва савытлары бер-берсенә бәрелеп тешләрен шыгырдатып алдылар. Ул нәкъ шул букчаны күтәреп күптән түгел Финляндиягә дә барган иде. Берничә тушунка савыты исән-имин килеш кире Казанга да кайтты. Баязит аларны “Куян күчтәнәче” дип бик тәмләп ашаган иде.

— Байракка тукыма кайдан табабыз соң?

— Аптырамагыз, — диде Нәгыйм үзенә эш чыгуга сөенеп. Һәм кайдандыр Мөдәррис Әгъләмовның былтыргы бүрегенә охшаган нәмәрсәкәй табып килде. Аны алар Марат белән бик озак турайттылар.

— Бәтәч, бу бит җыештыручы Мәйсәрә апаның идән чүпрәге, — диде Нәбирә. — Бер ел почмакта тора инде ул.

— Хәзер тормас, — диде Ләис һәрвакыттагыча мәгънәле итеп.

Турайткач, төзәткәч, чүпрәкнең хатын-кыз ыштаны икәне мәгълүм булды. Ләкин төсе генә ачык түгел иде.

— Анысы уйланырга калсын, — диде Ләис.

— Балакларын кисеп ташлыйк мәллә? — дип Марат нигәдер Нәбирәгә карады.

— Кисмә, — диде Ркаил. — Чыңгыз хан байрагы тугыз җәпле булган, безнекендә ике җәп булсын.

Ашказаны авыртуга карамастан, байрак тоткан Нәгыйм мачта башына үрмәләп менеп тә китте. Тикмәгә генә безнең бабайлар рейхстагка беренче булып байрак кадамаган шул!

— Борынгы бабайлар байракны ту дип атаганнар, — дип, Ркаил тарихтан дусларын агартып алмакчы булган иде дә, Нәбирә аның сүзен бүлде.

— Кузгалабызмы без, җәмәгать, юкмы? — дип кычкырды ул. — Бүген төшемдә күрше авылның сихерче карчыгын күрдем. Ак күлмәк кигән факир. Төшкә кадәр кузгалмасагыз, бөтенләй кузгала алмассыз, диде.

— Бүтән яссылыкта бөтенләй бүтән тормыш бара, — дип аның сүзен җөпләде Солтан Шәмси. — Дефак Рәхмәтинең соңгы эзләнүләре буенча.

— Килә, килә! — дип кычкырды Марат. Ул ярга таба якынлашучы Альбертны күреп алган иде. Тегесе гадәттәгечә култык астына папкасын кыстырган, яңа гына банктан чыкканга охшап тора. Ләкин аның кисек чырае якынлашкан саен Маратның мул сөенече күзгә күренеп кими бара иде.

— Акчасы юк, — дип офтанды ул. Ул инде Альбертның аяк атлау рәвешенә карап, кесәсендә ни барын белергә өйрәнгән иде.

Бухгалтер янәшәсендә Сергей Малышев та бар икән. Сакалы чуалган, төне буе укыганлыктан күз кабаклары шешенке. Үзе мыдыр-мыдыр килә:

— Жирафы, газели... Я уже 143 страницы отредактировал. А они чай пьют... — Үзенең җилкәсенә аскан буаз букчасы тезенә бәрелә. Анда Евгений Суховның кичә генә язган романы белән Розага дип алынган сыра шешәсе кочаклашып ята иде.

Ниһаять, кузгалдылар. Иделгә чыгарга да өлгермәделәр, Нәгыйм кайсыдыр танышыннан тапкан мотор (әле аның өчен шактый акча түлисе бар!) пышыкпышык килде дә сүнде.

Нәгыйм билдән үк мотор эченә чумды. Бик озак кайнашканнан соң дегеткә батып кире дә чыкты. Йөрәге әрнүдән яшерен серен әйтеп тә ташлады:

— Редакциядән алып кайткан тимер-томырдан үз кулым белән җыйган идем югыйсә...

— Безнең бабайлар моторсыз да яшәгән әле, — дип юатты аны Ркаил.

— Җилкән исән булсын, — диде Ләис.

Идел өстеннән җиләс җил исә иде, җилкәнен күтәргән яхта җиңел сулап алга омтылды.

Ярдагы комлыкта ялангач бер адәм тиз-тиз нидер казып маташа иде. Кара чуен тәнле, тузган чәчле, сакалы таралып күкрәгенә төшкән. "Бәтәч, бездә дә кыргыйлар пәйда булган түгелме соң?" — дип Нәбирә үзенең блокнотына иелде. Ул инде журналда чыгасы сәяхәтнамәсен башлап җибәргән иде. Язмасын ул болай башлады: "Җитмеш төрле эшем сиксән җирдә таралып калганга күрә, сәяхәткә мин теләр-теләмәс кенә чыгып киттем..."

— Заһид Мәхмүди түгелме соң бу? — дип Ркаил ярдагы теге "Кыргый"га ымлады. Калганнар да "шул, шул" диешеп аны җөпләделәр.

— Ханнарның яшергән алтынын табам дип былтыр чыгып киткән иде шул ул, — дип Марат үзенең һәрнәрсәдән хәбәрдар икәнен күрсәтте.

Җил яхшы исә, көймә алга йөзә, тик барыбер җанга нидер җитенкерәми иде. Бик озак уйланганнан соң гына барысы да төшенделәр: "Идел" яхтасында җитәкчеләр юк икән бит! Ни шкипер юк, ни штурман, ни боцман... Ә яхта һич исе китмичә алга йөзә.

— Алай ярамый, барысын да үзем оештырам, — дип Гаша штурвал янына менеп китте. Үзе күкрәгенә нindидер ялтыравык кәгазь дә аскан иде. Үткен күзле Роза Шәрәфиева аны шунда ук укып та алды: "Капитанның хуҗалык эшләре буенча ярдәмчесе Гаша Ивановна Кәримуллина". Барысы да җиңел сулап куйды. Җитәкче бөтенләй үк юк түгел икән ич.

Шул вакытта суга "шап" иткән тавыш ишетелде. Идел дулкыннары ярларыннан чыгып хәтта "кыргый" Заһид Мәхмүдине дә күмеп киттеләр.

— Ураган чыга, наверное, — дип рәссам Фәридә күк йөзенә күз салды. "Бакый Урманче премиясен алгач кына", — дип моңсуланып уйлады ул.

Ул арада Иделдән кемнеңдер "Ләис, Ләис!" — дип ачыргаланып кычкырганы ишетелде.

— Гаша түгелме соң бу? — дип сорап куйды Нәгыйм.

Ул аның тавышыннан түгел, ә "Ләис!" дип кычкырганыннан танып алган иде.

— Хәзер! — дип җавап өне салды Ләис. Тик үзе кузгалырга ашыкмады. Иренеп кенә башкалар палубага чыктылар. Штурвал тәгәрмәче әйләнеп китеп Гашаны суга сыптырып төшергән икән.

Дулкыннар арасыннан "Ләис, Ләис!" — дигән аваз гел ишетелеп тора иде. Ниһаять, Ләис тә Ыкта йөзеп өйрәнгән гәүдәсен Иделгә ыргытты. Ул батучыны өстерәп чыгарды. Тик күкрәктәге теге ялтыравык кәгазь генә ычкынып Иделгә агып киткән иде.

— Рәхмәт, Ләис Мәүлидич, — дип сулкылдады Гаша. — Рәхмәт, күздән яшьләр килде.

Чыннан да аның керфекләрендә әллә яшь, әллә Идел суының тамчылары җемелди иде.

Төгән ФӘЛӘНЕВ

Импичмент

Урман-кәгелле башын иеп Идел белән Кама суын эчкән Айгыр тавы моңсу кешнәп куйды. Тәртәсе күтәртеп бәйләнгән арба — "Иделлия-Казан" ерагайганнанерагая иде. Тау кашында озатып калучы өч ир-егет инде кул изәми — яхтага ияреп аккан мунчаның күгелҗем төтене дә тиздән офык артына кереп югалачак.

"Әчтерханга сәяхәтнең кайнар истәлеге итеп. Н.Гыйматдиновадан". "Идел" журналы тышына язылган әлеге кадерле сүзләрне Рафаэль Гыймадиев кабат укыды да авыр сулады.

— Зерә җибәрдек, Туфан абый.

— Мунчанымы? — дип ачыклады Туфан Миңнуллин.

Сүзгә Миннур Насыйбуллин кушылды:

— Аркасы кычыткан Әчтерханга киткән, ди Минһаҗ абзый. "Идел"ләргә мунча биреп каты төрттерден, Туфан Абдуллович.

— Минһаҗ абзаң ул гыйбарәне җиллерәк итеп әйтә. Рәхәтләнеп чапсыннар кычыткан урыннарын.

— Кызганыч... — дип уфтанды Рафаэль.

— Мунчамы? — дип төпченде Туфан. — Бер дә жәлке түгел. Мәрәтхуҗада атна-ун көн ашап-эчеп ятып, "Идел" егетләре үзләре корыштырган нәрсә ул.

— Бигрәк кайнар иде...

— Мунчамы? Юкны сөйләмә инде, Рафаэль. Чабыныйм дисәң ни пары тормады, юыныйм дисәң ни суы җылынмады. Келәттән арыга ярамады ул.

...Айгыр тавы күздән югалуга баш мөхәррир "Волга" түбәсеннән сикереп төште дә: "Ике минуттан барыгыз да миңа керегез", — дип каютасына җил-җил атлап китте. Гөлсирә апасы "Досья" порошогы белән агарт-

кан Бурсыкны күтәреп, кают-компаниягә Баязит та керергә мәҗбүр булды. Рашат Мияссәрович бүлмәдәгеләрне күзе белән барлап-сынап чыкты, сәяхәт уңаеннан малаеннан прокатка алып торган костюмын җилкә сикертеп арткарак авыштырды; тавышы Равил Фәйзуллинныкына охшар дәрәҗәгә җиткәнче тамак кырды.

— Көн тәртибендә ике җитди мәсьәлә бар. Дөресме?

Соңгы сүзеннән тәрәзә пыялалары зеңләп куйды. Баязит куркуыннан идәнне юешләтеп елап җибәрде.

— Энекәш, бу сорау әтиеңә һәм башкаларга да кагыла. Бар, әтиең белән чыгып тор...

Күнегелгән елгырлык белән костюм тагын артка авышты, баш мөхәррирнең күкрәге киңәеп китте.

— Белүегезчә, мин банкта бер ай эшләп алган кеше. Шуңа күрә беренче мәсьәләгә — акча табу мәсьәләсенә күчәбез. Каршылар юкмы? Булырга да тиеш түгел. Чөнки минем артта космос тора. Мунча бүләк иткәне өчен Туфан Миңнуллинга коллектив исеменнән рәхмәт белдерәм. Артыгын көтмәсен. Мин әйттем. Сораулар юкмы?

— Күптән акча да күргән юк, мунчаны миңа бирмәссез микән? — дип күзләрен ялтыратты редакция шоферы Ринат Насыйбуллин.

— Яңарак кына редакциядән тимер гараж алдың. Безгә тере акча кирәк.

— Чехов базарында бер танышым бар, Рашат Мияссәрович, — дип сүз алды Гаша. — Аңа биреп саттырсак кына инде.

— Чехов базары моннан ераграк шул. Безгә акчаны хәзер үк табарга кирәк. Ярар, үземнең фикерне әйтеп карыйм. Мунчаны сатсак, Туфан Миңнуллин дөрес аңламас. Мунча эшләргә, тере акча китерергә тиеш. Күпләрегез белмидер дә әле, безнең трюмда Әнәс Баталовның "Идел" бастырып чыгарган "Конец кровавого дьявола" дигән китабы тулып ята. Кеше ашаучы турында. Аны бер адәм дә алмады һәм алмас та, утын юнәтеп акча туздырганчы, мунчага шуны ягарга киңәш итәм.

Берьюлы бухгалтер, кассир, склад мөдире вазифаларын башкаручы Резидә Әхмәтҗанова бер агарды, бер кызарды, бер күгәрде:

— Рашат Мияссәрович, ул китапның 35049 данәсе дә минем өстә, ничек отчет бирермен? Үз җаваплылыгыгызга алсагыз гына.

— Хәзер үк списәт итәбез. Бар, актын төзеп керт.

— Рашат Мияссәрович, елатасыз хәзер мине. — Тетя Гашаның йөзе мул итеп гәрчич ашагандагы сыман сытылды. — Әрәм итмик кәгазьне. Бер тоннасы 40 мең тора бит аның.

Нәбирә Гыйматдинова күлмәк итәгеннән күзгә күренмәс чүп бөртеген селтәп төшерде:

— Гәүһәрия ханым, кайчан кеше фикерен тыңлап бетерергә өйрәнәсез!

— Дөрес, Нәбирә, макулатура заманы узды, — дип кистерде Рашат Низами. — Ягабыз!

— Ну, зачем это надо? — Почмакка кысылып утыручы Роза Кожевникова күзләрен тутырып торып басты. Әлеге триллерны үзе редакцияләгәне исенә төшкән иде аның. — Китап яндырып акча эшләп буламыни?!

— Ничек кенә була әле. Беренчедән, трюм бушап калачак. Икенчедән...

— Рашат Мияссәрович, Рашат Мияссәрович, сүзегезне бүлдергән өчен гафу итегез, "икенчедән" дигәнен икәү генә сөйләшә алабызмы?

— Җыелыш беткәч, бер минуттан керерсең, Гәүһәрия ханым... Өченчедән, мунча түләүле булачак. Монысын кистереп әйтәм. Мин әйттем!

— Күпме торачак инде билет бәһасе? — Машинистка Рушаниянең бу соравында җавап ишетергә теләүдән битәр, тагын безне төп башына утырталар инде, дигән үпкә-рәнҗү катыш алданасын алдан ук белеп тору куанычы да бар иде.

— Шәһәрдәгечә. Коммуналь хуҗалык министрына шылтыратып белештем — эш көннәрендә 6 сум 50 тиен, ял көннәрендә 13 тәңкә! Рәфикъ белән килештек. Кстати, ул җәяүләп инде Сембер каласына якынлашып килә. Күп сәлам әйтте. Атна арасында мунча якмасагыз иде, журналның эшенә комачау итәр, диде. Хак сөйли. Без ял итәргә түгел, эшләргә дип Әчтерханга сәяхәткә чыктык. Шуңа күрә мунчаны шимбә, якшәмбе керәчәкбез.

— Мөселманга җомга көнне мунча фарыз.

— Дөрес әйттең, Марат. Җомгада да мунча ягарбыз. Тик ял көн тарифы белән.

— Нинди оятсызлык инде бу, җәмәгать! — Профсоюз җитәкчесе Гөлсирә Гайнанова ничек сикереп торганын сизми дә калды. — 50 тәңкә командировочныйны ашарга тотаргамы, әллә мунча керергәме? Туфан Миңнуллин ул мунчаны редакция коллективына бүләк итеп бирде ләса! Редакция хезмәткәрләрен талап акча эшләргә җыенасыз.

— Мин дә акча түләп керәчәкмен, — дип тынычландырды баш мөхәррир. — Үземне мунча директоры итеп куям, Альберт — бухгалтер, Резидә — кассир, ә Нәгыйм белән Гөлсинәне мунчачылар итеп штатка алам. Башка бу сорауга кайтып тормыйбыз.

— Мунча директорының акча түләп мунча керүе — нонсенс!

— Гөлсирәнең сүзендә хаклык бар, — диде оеп утырган Мәгъсум Хуҗин. — Шуңа күрә директор итеп мунча керми торган кешене куярга кирәк.

— Йә, кайсыгыз мунча кермим дип әйтә ала. Неужели безнең арада чукчалар да бар инде, — дип кеткелдәде Нәбирә.

— Мәсәлән, Сергей Малышев, — диде Роза Кожевникова. — Мунчага ул аерылышкан ирем Лева белән генә йөри. Анысы да Казанның 3 нче мунчасына гына.

— Татар мунчасына татарны түрә итеп куясы иде, егетләр, — дип сүзгә кушылды Солтан Шәмси. — Мәсәлән, Атлантида мунчаларына атлантлар гына хуҗа булган.

— Бетте! Шаулашмагыз! — Баш мөхәррирнең җилкәсе елгыр уйнап, костюмны кабат артка чөйде. — Әллә мине бик тә директор буласы килә дип уйлыйсызмы? Болай да эшем күп. Күрәсезме менә бу кәгазьләрне?! Һәр юлы — бер эш. Сары төс белән сы-

зылганнары гына башкарылган. Ә мунчаны мин любой начальникның аркасын ышкып керә алам.

— Рашат правильно говорит. — Һәммәсе дә Һәр җыелыш ахырында саллы сүзен әйтергә яраткан Фәридә Хәсъянова ягына карады. — Коллектив та в чем то прав, — дип өстәргә мәҗбүр булды баш рәссам. — Поэтому министрга или даже президентка обращаться итәргә нужно, советоваться. Тогда беркем дә в обиде не будет.

— Ярар, киңәшермен, — диде Рашат Низами, әлеге төпле сүзләрдән соң. — Әлегә мәсьәлә ачык кала.

— Ә мунча ябык тора... — дип өстәде Марат.

Кемдер авыр, кемдер җиңел сулап урыннарыннан куба башладылар.

— Ашыкмагыз әле. Берничә производство мәсьәләсен хәл итәсе бар. Компьютерларны эшләтер өчен бензин ягып, өр-яңа "Волга" генераторын туздырып булмый. Шуның өчен Нәгыйм яр буеннан табып алган иске велосипедтан минем инициатива белән электростанция ясады. Гөлсирә ханым, сез бик принципиаль хезмәткәр. Педаль әйләндерү чиратын төзегез һәм эшнең барышын каты контрольдә тотыгыз. Ут булмыйча компьютерларның хәтере очса, сез генә гаепле буласыз. Бу — приказ.

Баш мөхәррирнең күз карашы коллектив өстеннән шуып үтте дә Мәгъсум Хуҗинга тукталды.

— Мәгъсүм абый, сез безнең даими автор, бик хөрмәтле кешебез. Сәяхәткә дә шуның өчен алдык. Оста балыкчы икәнегезне дә истә тоткан идек. Азык запасы да, акча да төкәнеп килә. Шуңа күрә бүгеннән үк балык каптыра башласагыз яхшы булыр иде.

Аптыраудан Мәгъсум Хуҗинның калын кашлары маңгай уртасына хәтле калыкты.

— Туктале, Рашат туган, мин бит кыш көне генә балык тота беләм. Хәстәрләгән кармакларым да бәкедән сала торган. Үзем белән алган киемнәрем дә — тышланган тун да, сырган чалбар, колакчын бүрек тә олтанлы итек.

Консерва-монсерва, токмач-мокмачлары булганнар пырхылдады, булмаганнар мыгырдады. "Ачның ачуы яман" дип юкка гына әйтмиләрдер шул.

— Җәй көне сәяхәткә чыгып киткәнне искәрмәдеңмени, Мәгъсум абый?

— Кыш көне боз өсләтә җәяү кайтасын искәрдем... Идел өстеннән көтмәгәндә көчле җил үттемени — бүлмәдәгеләрнең бер өше утырган җирләреннән шаулап калыкты, бер ише куырылып төште.

Баш мөхәррирнең ачудан муены кызарып чыкты.

— Провокатор!

Нәбирәнең ике какланган казы, ике ай ярымга җитәрлек әчтерхан чикләвеге бар иде әле — ышанычлы тавыш белән серен чиште:

— Төшемдә күктән ишелеп йолдыз яуганын күрдем. 30 нчы августта Республика бәйрәме көнне Казанга кайтып җитәбез!

Бүлмәдәгеләр җиңел сулап куйдылар. Нәбирәнең төшләре юш килә. Провокаторны беренче очраган утрауда төшереп калдырырга карар кылып таралышабыз дигәндә, башын иеп утырган Мәгъсум Хуҗин телгә килде:

— Бүген үк балык тотып ашатам. Калдырмагыз гына. "Идел"дән аерыласым килми минем.

Гөлсинә белән Гөлфиянең күңеле тулышты. Ни дисәң дә, якташлары бит. Аннан соң бик тә, бик тә балык шулпасы ашыйсы килә.

— Рашат абый, бер юлга гафу итегез инде уртак якташыбызны, — диде алар, елый язып.

Баш мөхәррир, муенындагы кызыллыгы алсулана төшкәч, бераз юашланды.

— Капитан буларак, яхтада калдыра алмасам да, салга утырып баруын рөхсәт итә алам.

Бер сәгатьтән мунча түбәсен сүтеп корыштырылган сал әзер иде инде. Мәгъсум Хуҗин кушуы буенча салның нәкъ уртасында түгәрәкләп бәке тиштеләр. Өске ягын да, аскы ягын да зәңгәр төскә буяп куйгач, салны боздан аерып булмый башлады. Балыкчы буяу кипшенгәнен дә көтмәстән, барлык хуҗалыгын төяп, яхтага аркан белән тагылган салга күченде. Сырган ыштан, олтанлы итек, тышланган тун, колакчын бүрек киеп җәйге Идел уртасындагы "бозда" утырган бу балыкчыны күргәч, акчарлаклар сәерсенеп кычкырыша, тизрәк бу тирәдән китү ягын карый иде...

* * *

...Гәүһәрия ханым Идел буйлап Әчтерханга сәяхәткә чыгасын белгәч, ныклы карарга килде: дачада да ял итә алам, Казаннан Әчтерханга кадәр барлык районнарны да колачларга, Альберт, Нәбирә өлгергәнче, барсы белән дә алдан сөйләшеп, килешеп, кул сугышып куярга, һәммәсенә йомшак реклама ясап "Окайока", гараж алырлык акча эшләргә кирәк, дип уйлады. Тегеләй итте,

болай итте, хәтта Әчтерхан өлкәсендәге вак-төяк оешмаларга кадәр җитеп, телефон, адрес-мазарларын табып, кемнең күпме бирәчәген, кемнән нәрсә алып булачагын сәяхәткә киткәнче үк ачыклап куйды. Җәмгысе 2847 предприятие, завод, фабрика, кумәк хуҗалык, авыл җирле үзидарәсен сайлап алды ул. Сайлап алды да аптырашка калды: журналның һәр санында берсен бирсәң дә, 270 ел вакыт кирәк икән ләбаса! Яхшыларын, байларын гына калдырырга теләп, тагын күңел иләгеннән үткәрде. Әмма коелган берен, процентлар эләкми кала дип жәлләп, кире күңеленә сала барды. Шулай шактый изалана торгач, үзем тагын 270 ел яши алмасам да, журнал яшәсен, кәгазьгә, акчага кытлык кичермәсен дип юанып һәм куанып, сәяхәт вакытында әлеге оешмаларның һәммәсен дә күреп чыгарга булды.

Югары Осланда ук хыяллары кителә башлады аның. Сәяхәткә кирәкле барлык вак-төякне, азык-төлекне, җитәрлек акчаны андагы оешмалардан яхтага төяп китәргә алдан килешенгән булса да, җиде чалгы, 243 тырма теше, бер сабан төрәне һәм "К-700" көпчәгеннән битәр берни дә ала алмады.

Чираттагы пристаньда ярга сикереп төшкәч, беренче эш итеп, яссы чуер ташны су өстеннән тездерде. Чуер таш ике тапкыр чупылдап сикерде дә, барлык калган өметләрне үзе белән алып, су төбенә китте. Ике генә спонсор тәти икән монда.

"Халыкка күрсәткән яхшылыкларыгызны ишеткәч, сөенечтән күзгә яшьләр килә, әйдәгез, журналда сыңар бит түгел, куш бит бирик", — дип Тетя Гаша үгетләсә дә, беренче спонсор юмартланып китмәде: "Чирек банка сургычтан арттыра алмыйм", — диде.

Икенче спонсор гәүдәгә тазарак иде. Юан кешенең юмарт икәнен бик яхшы белгәнгә, Тетя Гаша, күз яшьләре хакында әйтеп тормый гына, алты капчык арыш һәм ике тартма чүпрә каерып ала алды.

...Тауарны трюмга төшереп бикләгәч, трюм капкачын сургычлап куйдылар. "Дөрес эшләдек, шулай бит, Рашат Мияссәрович, — дип баш мөхәррирнең күзенә карады Тетя Гаша. — Редакциядән иярә килгән алты капчык писүк янына әйбәт кенә төшеп яттылар".

Бер-берсенә кушылырга яраткан арыш, чүпрә, шикәр комының нинди хикмәт чыгарасылары берәүнең дә башына килмәде...

Ашказаны кечкенә булса да, Нәгыймнең үтереп ашыйсы килә иде. Казаннан алып чыккан булканы бүлешеп Резидә, Роза, Ләис белән Осланда ук чәй эчкәннәр иде шул.

— Гәүһәрия апа, сиңа бер сүз бар иде. — Нәгыйм кесәсеннән кайчы белән тарак чыгарды. — Чәчеңне тагын алмыйбызмы?

— Иртән генә кыскарттың бит.

— Алды озынрак калган кебек.

Кайчы кат-кат уйнаса да, зур гамьнәр белән тулышкан башның һәр чәч бөртеге үзе генә белгән тарафка — Татарстан, Сембер, Самара, Әчтерхан авылларына карап торуын дәвам итте. Инде чәч тарак юкалыгы калып килсә дә, авызга су китерүче гозерен әйтә алмый җәфа чикте Нәгыйм. Ниһаять, колак яфрагына үскән чәч бөртеген кыркыганда: "Бер уч арыш биреп тора алмассың микән?.." дип пышылдады.

Ни кызганыч, нәкъ шул мизгелдә "Ухват" кушаматлы Гәүһәрия ханымның башын шаулатып шәп уй килде.

— Синең монда дрелең бар түгелме, Нәгыйм?!

— Барын бар да... ашап булмый аны...

— Башта эшләргә кирәк... Минем көймәгә мотор итеп көйләп куй әле шуны. Хәзер үк. Юлга кузгаласым бар. Казанга урап кайтканчы түзсәң — рәнҗетмәм.

Әмма Тетя Гаша ул көнне дә, бер атна үткәч тә яхтаны калдырып зур юлга кузгала алмады. Осланнан үзе алып кайткан чалгылар белән кемнәрдер резин көймәсен тураклаган иде аның. Мәгъсум Хуҗинга "Идел"ләр сал ясап биргәч, кызыгу катыш матур көнләшү белән көн саен балыкчыны күзәтте ул. Балыкчының атна узып сыңар шыртлака да каптыра алмаганын күргәч, өметләнеп, баш мөхәррир каютасын шакыды.

— Рашат Мияссәрович, салны миңа бирсәгез яхшы булыр иде. Сембергә алдан барып эшне көйли торыр идем.

Тиз арада Хуҗинны чакыртып алдылар.

— Бирмим, — дип кырт кисте балыкчы.

— Коллектив ачтан үлгәнче, салыңны бир инде, Мәгъсум абый, — дип ялварды баш мөхәррир.

— Казанны чыгу белән кара бакен тора. Шуның янында балык яхшы каба иде, — дип хатирәгә бирелде карт балыкчы. — Кара бакен табып салыма бәйләсәгез, бүген үк тамагыгыз тук булыр.

Сембергә бер көн юл кала, яхтада Нәбирә Гыйматдинованың Әчтерхан чикләвекләреннән һәм Ләиснең сохариларыннан битәр сыңар тәгам дә юк иде. Ачлыктан бетәшүчеләр көпә-көндез саташа, күз күрмәгәнне күрә, колак ишетмәгәнне ишетә башладылар.

Гөлсинә үзенең кушаматы "Кара телефон" икәнен белгәндерме-юкмы, "Данное направление перегружено", "Данное направление перегружено..." дип палуба, каюталар буйлап сөйләнеп йөри башлады. Болай гына калса ярар иде бахыр, "Безгә Моника Левински килә, мунча керергә Моника килә!" дип шәрран кычкыра-кычкыра яңа хәбәр ирештерде.

Аның болай кычкырганын ишеткән саен баш мөхәррир,, күкрәгенә сугып: "Моника — минеке! Моника — минеке!" дип такмаклый-такмаклый, батып кергән күзләреннән сөенеч яшьләре агызырга керешә иде. Ратат кабиләсенең бөек шагыйре Ташар Имазин булып алышынган иде ул бахыркай. Имеш, Моника алар кабиләсеннән, имеш, Моника аның беренче мәхәббәте булган.

Фәридә Хәсъянова йөгереп йөргән җиреннән таякка калды. Нәгыймнең чүкеч, өтерге, зубилаларын үзләштерде. Судан тотып алынган юан агач төбен төн уртасына кадәр шакылдап уя, кыра башлады. Үзенең кем булып алышынганын әйтә алмаса да, яңарак зур исемгә лаек булганын искә төшереп, күпләр аны Бакый Урманчедыр бу диделәр.

Җаваплы сәркәтип Роза Шәрәфиева иртәнге тугызда шикәр комы болгатып чәй эчү, тоз сибеп чикмәнле бәрәңге ашау күренешләрен буш өстәл каршында оста башкарырга күнекте. Шулай уйнап-хыялланып утыргач, нәкъ уникенче яртыда кисәк сикереп

тора да, сумка, пакет, капчыкларын барлап палубага ыргыла. Суга ташлана бу бичара дип үзен тотып калгач: "Чехов базарына барасым бар, кыяр, суган, ит, сельдерей аласым бар", — дип гасабиланып үкси.

Роза Кожевникова Казан елга портында ук бушаган сыра шешәсен өстәл астында гына ача да, беркем дә күрмәгәндә кырлы стаканга сала, Әчтерхан балыкларын сагынып авызын чапылдата-чапылдата салкын сыра шәүләсен уртлый.

...Сембер каласына барып җитәргә бер сәгать, ә яхта шартларга 12 минут вакыт бар иде әле...

Бераз ушларына килүчеләр кабат кают-компаниягә җыелдылар: көн кадагында һаман бер мәсьәлә — трюмны ачып бирәр уч арыш һәм бирәр уч шикәр комы алып ашау иде.

— Түзегез инде, балалар, — диде Тетя Гаша елый язып. — Тиздән Сембергә килеп җитәбез. Анда безне, бәлки, бушка ашатырлар. Шулай бит, Рашат Миясәрович?

— Моника дөрес әйтә, — дип раслады баш мөхәррир.

Тагын бер бөртек ризыксыз таралыштылар.

Яхта шартларга 3 минут кына калган иде инде.

3 минут узды.

Яхта шартламады.

Казан портыннан кузгалып китәр алдыннан шешә бәргәндә бортның яньчелгән урыны "Иделлия-Казан"ны үлемнән алып калды.

Диверсантлар Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла, Марат Закир һәм иң гаҗәбе — баш бухгалтер Альберт Сөләйманов иде.

Кама Тамагындагы тауарлар трюмдагы шикәр янына төшеп яту белән, төнлә палубаны тишеп, таң атканга кадәр трюмга су тутырды алар. Тишекне тимер чөй белән кагып бөкеләгәч, Ләбиб Лерон канәгать елмаеп вәгъдә итте:

— Унбиш көннән бәйрәм ясыйбыз, егетләр!

Тимер чөй бүрткән булып чыкты. Унбиш көннән соң аны тартып ала алмадылар.

Яхтаның аскы өлеше, палубасы, буяулары чатныйчатный, көннән-көн кабара барганын диверсантлар күреп, тоеп йөрде.

— Ничек дөбердәп кайный — аякны калтырата... — диде Ләбиб, гасабиланып.

— Синең аркада серкәгә әйләнә инде. — Бөкене катырак каккан Ләбибнең үзен дә каккаларга әзер иде Ркаил.

Әфган сугышын үткән Марат үзалдына сөйләнеп куйды:

— Өч чирекле брашкаң шартлаганда хәлеңне аңламаганмын, эти...

Нәкъ шул мизгелдә бөке атылгандай тавыш яңгырады, нәрсәдер чажлаганы, шаулаганы, гүләгәне ишетелде — яхта иңрәп янтая башлады. Палубадагылар кайсы кая тотынып, куркудан зур ачылган күзләрен күккә текәп катып калды: яхта төбеннән Сембер ягына таба дугалап галәмәт биек фонтан бәрә иде.

Эшнең нәрсәдә икәнен беренче аңлап, Ләбиб фонтан ягына үрмәләде. Бераздан шау-гөр арасыннан өзек-өзек сүзләре ишетелде:

— Аяктан... Әрәм була...

Ургылып аккан чишмәдән су эчкән шикелле фонтанны ул уртламакчы иде ахры. Менә ташкын аны үзенә ияртеп күккә чөйде — Сембер ягына таба ажгыртып алып китте.

Ничек кисәк башланса, шулай тынды фонтан — Идел өстенә аксыл күпер салып төшеп ятты. Яхта тураеп баскач Ркаил телгә килде:

— Ләбиб бәхетле. Очып киткәндә канәгать елмаюын күреп калдым. Аягыннан тотсак, үпкәләгән булыр иде.

Марат бау бәйләнгән чиләкне Иделгә чумырып алды, түшеннән агыза-агыза йотлыгып эчеп бетерде, сипкелләре күзгә күренеп кызарды.

— Су кушылгач бераз слабыйланган, — диде ул, ниһаять.

Үрмәләп каютадагылар палубага чыга башлады, "Нәрсә булды, нәрсә булды?" диештеләр.

— Хуҗин салы белән яхтага бәрелде, — дип сукранды Альберт, — чак кына аудармады.

Барсы да бәкегә бөгелеп оеган Хуҗин ягына ачулы караш аттылар.

— Балык капмый имеш... — Рушаниянең иреннәре юкарды. — Бар тотканын төнлә үзе ашый да көне буе йоклый.

— Карагыз әле, карагыз! — Мәйсәрә апа идән чүпрәге таягын Иделгә төбәде. — Балыклар су өстенә чыккан. Әнә монда, әнә тегендә!

— Минем аквариум балыклары Кырым шәрабы эчсә шулай мәш килә иде, — кампитрчы Светлана Латыйпова авыр сулады.

— Смотрите, — дип кул чапты Мөнирә Кузиева. — Идел өсте тулы рыбалар.

— Эзотериканы белмисез шул. — Солтан Шәмси үтергеч елмаеп Хуҗин ягына ымлады. — Әнә, бер ай инде кармак сала — мәгънә юк. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, дигән посвященныйлар. Авыр юллар, ачлык сынаулары үттек — шуңа хәзер балыкларны кул белән дә тота алабыз.

Алпан-тилпән йөзгән чөгә балыгын Мәйсәрә апа швабрасына эләктереп палубага атты.

— Минем бүген 60 еллык юбәләй. Барыгызны да бәйрәмгә чакырам!

Альберт Идел суы эчеп шактый хәлләнгән иде.

— Мәйсәрә апа, аракысы редакция хисабыннан булыр, мә, ал, налогын тотып калырбыз, — дип чиләк белән Иделдән су чумырып идән җыештыручыга сузды.

Әчтерхан губернаторы белән мәҗлестә утырсам, уйнап егетлегемне күрсәтермен дип, баш мөхәррир сәяхәткә гармун алган иде. Менә репетиция ясарга җай туды — Идел өстенә бию көйләре сибелде. Халыкта чи балык ашау, чүмечләп Идел суы эчү кайгысы иде әле, көй уңаена авызлар гына чәпелдәде. Бераздан буыннарга хәл керде, күзләр елтырый башлады, иреннәр онытылган елмаю ымнарын искә төшерде — тиздән кемдер җырлый, кемдер бии, кемдер акырып көлә, кемдер шатлык яше коеп елый иде.

(Дәвамы 44 нче биттә)

Дәвамы. Башы 34 биттә

Рушания Харисова:

— Мин кульязмаларны чиратка тезәм. Ә мөхәррирләр чиратымны вата-җимерә, һәрберсе үзенекен беренче бастырмакчы. Шунда чират та, баш та бутала инде. Йә Ркаил, йә Нәбирә, йә Рәфикъ абый "минеке әзерме?" дип тинтерәтәләр. Атнаның 5 көне чират бозучылар белән көрәшеп үтә.

Компьютерның бөтен нечкәлекләрен аңлап эш йөртүче белгечебез Светлананың бездә абруе зур. Тәҗрибәле, белемле. "Моны белмим" дигәне юк. Өендә дә уңган хуҗабикә икәненә ышанабыз. Светланабызның бәйләү-тегүләргә кулы ята, шуңадыр, үзе дә матур һәм килешле итеп киенә.

Светлана Латыйпова:

— "Идел"дә тупланган зур тәҗрибәмне бүтән урыннарда да кулланыр идем. Түләүсез белдерү бирәм: эш эзлим. Шылтыратыгыз!

Сез, мөгаен, "Идел"нең беркайда да кабатланмаган бизәлешенә карап сокланасыздыр. Зәвекълы рәссам кулы сизелә, әйеме? Баш рәссам Фәридәбез тырышлыгы нәтиҗәсе бу. Ул "Идел"гә килде дә аны өр-яңадан иҗат итте. Төс-кыяфәтен үзгәрткәч, матураеп китте "сабыебыз". Фәридә әле редакциядә чәчтараш ролен дә үти: иң модный прическасы белән авторларны аяктан еккан Рушания — аның "иҗат җимеше". Танылган рәссам берьюлы остаз да. Яшь рәссамнарны үз янына алып эшкә өйрәтә, тегеләре, канат яргач, очып китеп бара. Ә менә сәләтле, яшь рәссамыбыз Диләрәне җибәрмәсен, канатларын "Идел"гә ныграк бәйләсен иде. Диләрәбез, сөбханалла, итагатьле, тыныч һәм бик акыллы кыз. Аның өметле киләчәгенә шигебез юк.

Фәридә Хәсъянова:

— "Идел"челәр Репин картинасындагы бурлакларга охшаган. Бу журналны чыгару, яшәтү өчен һәммәсенә дә, бурлаклар сыман, җигелеп тартырга туры килә. Үземне дә шул бурлакларның берсе итеп тоям.

Диләрә Нәүрүзова:

— "Идел" — алдынгы журнал, аның киләчәге бар. Һәм мин ул киләчәккә оптимизм белән карыйм. Биредә танылган язучылар, рәссамнар эшли. Алар журналыбызның данын югары күтәрәчәк.

Балконлы ян бүлмәдән елаган, көлгән яки үкергән тавышлар ишетсәгез, гаҗәпләнмәгез. Ул безнең корректорыбыз Гөлсинә Хәмидуллина булыр. Гөлсинә хәреф хаталары гына төзәтми, һәр язмага, һәр әсәргә үз бәясен дә биреп утыра. Ошаса — күңеле хисләнеп елый, ошамаса, авторны Каф таулары түбәсенә "озата". Үкерүе — журналга бик пүчтәк әйбер килеп керүеннән. "Идел"дә чума-бата йөзә-йөзә, Гөлсинәбез шәхси тормышын да җайлады. Фатирлы кияү тапты. Айтуган исемле малай үстерәләр.

Гөлсинә Хәмидуллина:

— "Идел"гә мәрхүм Фәиз Зөлкарнәй чакырган иде. Сүзен аяк астына салып таптамыйм дип, аңардан куркып кына ризалаштым. "Идел" тиз арада үзенә суырып алды. Хәзер журналдан башка тормышымны күз алдына да китермим.

Гөлсинәне бәрәүгә дә тәтемәгән "бәхет" басты. Аның өстәлдәш күршесе — танылган шагыйрь һәм прозаик Ркаил Зәйдулла. Ркаил күбрәк өйдә яза, "Идел"гә сирәк килә, ләкин берәгәйле килә. Шагыйрьнең көлүен сеңдергән хезмәткәрләр, тфү, диварлар атналар буе калтырап тора.

Ркаил Зәйдулла:

— Татар яшьләре өчен махсус журнал чыгару турындагы сүз илленче еллардан соң ук башлана. "Идел" өчен көрәш берничә дистә елга сузылды... Шундый зур авырлыклар белән нәшер ителә башлаган журналның тиражы тәүге елларда йөз меңнән артып китте. Әмма хәзер, икътисади кыенлыклар аркасындамы, башка сәбәптәнме, безне укучылар даирәсе бик тә тарайды. Тик борынны төшермәскә кирәк. Татар әдәбияты өчен беркайчан да ал да гөл заманнар булмады. Безгә бөек

остазларыбызның карашы төбәлгән. Зирәклек һәм кыюлыкны бергә куша белсәк, "Идел"нең кадере һичкайчан кимемәс...

Сезнең кырмыскаларны күзәткәнегез бардыр. Гел хәрәкәттә алар. Мөхәррир, шагыйрь Маратыбыз да шундый. Әфган сугышларын кичеп тә рухын сындырмаган егет. Бик тырыш. Шигырьләр, хикәяләр яза, интервьюлар ала, кызык-мызыклар уйлап таба.

Марат Закир:

— Түрәләр — халыкны, эшкуар — эшкуарны, сәүдәгәр — сәүдәгәрне, ир — хатынны, хатын — ирне, дус — дусны кәкре каенга терәтә хәзер. Һәммәсе безне — яшьләрне терәтә. Кем-кем, ә менә "Идел" безне беркайчан да кәкре каенга терәтмәс!

Урыс телле, татар җанлы "Идел" бүлмәсенә күз салыйк әле. Сулда мөхәррир Гөлсирә утыра. Тәрҗемә итә бугай, бик җитди. Гөлсирәбезнең күңеле Идел кебек киң. Ходай аны кешелекле һәм мәрхәмәтле итеп яраткан. Моңзарларыбызны без күбрәк аңа сөйлибез, мөһим белешмә-хатларны да аңардан яздырабыз. Ул халык медицинасы белән кызыксына: Су-Джок ысулларын өйрәнә.

Ә уртадагы өстәлне мөхәррир Сергей Малышев били. Сергей — талантлы шагыйрь. Байтак кына татар шагыйрьләрен тәрҗемә кылды. Бик итагатьле ир-егет. Компьютер кызлары аны яратып "Малыш" диләр. "Озак яшисегез килсә, яшел чәй эчегез", — ди ул безгә. Шәхсән мин аның киңәшен гел истә тотам.

Уңда баш мөхәррир урынбасары — Роза гөлебез балкый. Кыз чактагы фамилиясе Баубекова. Әчтерханда туган. Кара уылдык илендә үскәнгә күрә тыныч һәм сабыр. Бәрәңге ашап үскән кешеләр сыман кабынып-ярсып китмәс. Нәрсәгәдер кәефе кырылса: "Да ну его", — дип кул гына селти шагыйрә. Шигырьләре хистән генә тукыла.

Гөлсирә Гайнанова:

— "Идел"гә эшкә урнашкач, туганнарым янына кайткан кебек булдым. Без алдагы елларда зур рухи күтәрелеш кичердек. Бер җилкән астына берләшеп, бер максат белән яшәдек. Хәзер матди яктан сәхтиян күне төсле кысыла барабыз. Хөкүмәт журналы саналсак та, бүре кебек үз тамагыбызны үзебез туйдырырга мәҗбүр. Көлсәң көл, еласаң ела: халыкның мәдәниятен үстерергә тиешле бүлек мөхәррире 600 сум хезмәт хакы алсын инде, йә!

Сергей Малышев:

— Журнал — живое существо, он как растение, собака, маленький ребенок. От твоих действий или бездействия зависят его жизнь и самочувствие. А если деятельность твоя не идет ему на пользу, он ведь ничего не скажет, просто начнет хиреть.

С каждым месяцем он становится на месяц старше, ты же на месяц стареешь. А все равно приятно, что он есть на свете. Даже диковинные опечатки вроде "*Зверь* татарской эстрады" вместо *"Звезда"* — не смущают. Свои, все-таки, родные.

Роза Кожевникова:

— С февраля 1989-го, еще несколько месяцев до выхода первого номера, мы (тогда Ахат Мушинский, Майя Валеева, Фаяз Фаизов, Адель Хаиров и я), собравшись в пустом кабинете, где еще и стола не было, завели "амбарную книгу" для регистрации поступающих рукописей, и эта толстая тетрадь до сих пор фиксирует все, что к нам приносили и присылали на русском языке самые разные авторы. Листаешь эту тетрадь и перед глазами встает биография журнала и наша собственная...

Мы были и есть фанаты своего дела, своего журнала.

Әйе, дөрес әйтәсең, Роза. Без фанатлар шул. Мөгаен, башыбызга "Идел" тае типкәндер. Җаваплы сәркәтибебез, икенче Розабызни дияр тагы. "Идел"гә килгәч аның иҗаты тагын да чәчәк атты: кызыклы-кызыклы интервьюлар авторы ул безнең, шулай ук оста тәрҗемәче. Розаның ягымлы тавышы радиотыңлаучыларга да таныш: ул еш кына журналга айлык күзәтүләр ясый.

Роза Шәрәфиева:

— Ун ел, әлбәттә, әллә ни зур вакыт түгел. Ләкин журнал шушы вакыт эчендә күп нәрсәләр аша узган. Бу вакыйгалар арасында күңелсезләре күбрәк, минемчә. Нишләмәк кирәк, тормыш. Фәизне югалтканнан соң без сыгылып төштек. Турая алырбызмы, белмим.

Ахыры 50 нче биттә

Әчтерхан чикләвеге

(Дәвамы. Башы 28 нче биттә)

Кызганыч, Мәйсәрә апаның гомер буе көтеп алган юбилее озакка сузылмады — биш килолы сазанны комсызланып ашап куйгач биергә дип калкынган иде, башы әйләнеп чүкте, җырлыйм дип авыз ачкан иде, гырлап йокыга китте. Бераздан барысы да кайсы-кая егылышып тирән йокыга талдылар — караңгы иңеп килгән Идел өстенә гырлау, мышнау, саташып мыгырдау тавышлары гына таралды. Шул шул, ач карынга күп ашарга ярамый — азык исереклеге аяктан ега.

Сохариен аз-азлап кабып, ачлык галәмәтен җиңелрәк кичергән Ләис кенә бирешмәде. Сөйләшеп утырырлык берәр кеше табып булмасмы дип, палубада аунап ятучыларны аяк очы белән уяткалап йөрде дә, баш калкытучы күренмәгәч, "Кемнәр белән эшлим мин?!" — дип үртәлеп, каютасына реклама язарга кереп китте.

"Әчтерханга барып җитә алмабыз, ахры, күпме спонсор әрәм кала..." дигән сүзләр кәгазьгә төшкәндә, өстәлнең, каютаның каты чайкала башлавын абайлап, палубага йөгереп чыкты.

Иделдә давыл купкан иде. Дулкыннар палубада ятучыларны сыпырып алырга теләгәндәй ыргылалар да кемнеңдер туфлиен, кемнеңдер ашалып бетмәгән балыгын йолкып артка чигенәләр. Ләис иң башта хатын-кызларны каюталарына ташыды — кайсын култыклады, кайсын җилкәсенә салды, кайсын күтәрде, иң авырын аягыннан сөйрәде. Ир-атларны ташырга көч тә, вакыт та калмаган иде инде — аркан белән барсын бергә бәйләп яхтага беркетте. Туктале, бик аз күренәләр болар, дигән уй бәгырен телеп үтте дә иелеп барлады. Гамьсез мышнаган "көлтәдә" таныш чалымнар — Ркаилнең ялан аягы, Альбертның папкасын төшермәс кулы, Маратның стрелкасыз чалбары шәйләнмәде.

— Хуҗин! Хуҗин! — дип ачыргаланып кычкырды Ләис.

Караңгы дулкыннар кочагыннан карлыккан тавыш чалымланды:

— Әү, улым!

— Егетләр синең салда түгелме?

"Ю-у-у-ук", — дип дулады давыл.

"Безне коткара күр, тәңрем!" — Ләис каютасына кереп бикләнде. Су иясен, җил иясен чакырды. Ләкин алар әллә ишетмәде, әллә тыңларга теләмәде — яхта тагын да катырак чайкалды, калтырады, һәр җөенә кадәр шыгырдады. Тәненең авыраеп китүен тойды Ләис. Бетүләрем шул микәнни?! Кукурузникта очкандагы кебек колаклары зеңли-зеңгелди башлады. Күккә ашуларым шул микәнни?! Ирексездән иллюминаторга капланды. Аста бихисап йолдызлар җемелди. Шәһәр утлары сыман мыжгып торалар. Йә, Тәңрем, күктәге калаңа күчерәсеңме әллә мине?! Бераздан йолдызларны караңгылык упты. Аяк-балтырлар җиңеләеп калды. Күбәләк булып очасы килә башлады. Тән белән аерылышыр вакыт җитте дәмени?! И җаным-күбәләгем! Чү, ашыкма, күбәләгем-җаным!

Шул чакта өскә шапалак килеп төшкәндәй булды — бик авыр, бик авыр шапалак — бар дөнья сытылды...

Ләис аңына килгәндә иллюминатордан төшкән кояш көлтәсе коңгырт чәчләрне сыйпый, иркәли иде. Саташылды, ахры. Алай дисәң, ник идәндә ята соң әле ул? Бар җире сызлый, авырта. Көчкә торып басты да алпан-тилпән палубага чыкты. Мең кояшы белән күзне чагып Идел җәйрәп ята. Чыннан да, саташканмын! Күк катына очам, имеш. Әнә, аркан белән бәйләнгән егетләр әрдәнәсе дә үз урынында. Әнә, Мәгъсум Хуҗин да салында оеп утыра.

— Привет, Хуҗин!

— Чү! Чү !Дәшмә! — Хуҗинның тавышы шомлы калтырап чыкты. Бәке өстенә тагын да бөкшәя төшеп тынсыз калды, тагын да катырак иелде, кисәк тураеп кармагын тартты. Йөзе балкып китте. — Капты, капты, улым! Әйттем бит мин сезгә балык ашатам, дип. Болай булса ачтан үлмим икән әле...

— Нинди кара балык ул, Мәгъсум абый?

— Балык түгел икән бу, улым... карга икән...

— Карга?!

Шулчак аяз күктән шыбырдап Идел өстенә ниләрдер коела башлады. Аяк астына да берсе төште. Төште дә читкә сикерде. Бака лабаса?! Күктән бака ява! Егетләр әрдәнәсе өстенә ялтыр таяк очып төште. Чуртан?! Күктән балык ява!

"Су астында карга оча, күктә балык-бака йөзә..." — Башын учлап Ләис бу сүзләрне кат-кат кабатлады. Изүеннән сохариен алып дару итеп капты. Озак кына күзләрен йомып торды. Бу саташудан тизрәк котыласы килә иде аның. Менә хәзер уяныр ул. Күзләрен ачар. Ачты — әмма һаман күктән шыбыр-шыбыр яшел бакалар, елтыр балыклар коела иде.

— Рашат Мияссәрович! — дип шырыйлап кычкырды ул. — Тизрәк төшегез әле!

Әмма яхта түбәсендәге "Волга" машинасыннан баш мөхәррир төшмәде — чөнки машина үзе дә юк иде.

— Рашат Мияссәрович! Тизрәк чыгыгыз әле!

Әмма яхтага бау белән тагылган мунчадан баш мөхәррир чыкмады — чөнки мунча үзе дә юк иде.

— Хуҗин! Хуҗин! "Волга" белән мунчаны күрмәдеңме?

Хуҗин дәшмәде. Ул карганы ботарлый-ботарлый Ләискә каш астыннан сөзеп карады...

— Ахырзаман! Ахырзаман!

Ахырзаманда үлгәннәр дә торып чыга дигән сүз хак икән — иңрәүле тавыш үлеп йоклаучы сәяхәтчеләрнең һәммәсен дә уятты.

Йодрыклары белән күкне төйгән Ләисне уратып алдылар, "Бу бахыр да ычкынды", диештеләр.

— Ахырзаманда безне ташлап Рашат Мияссәрович ычкынды, — дип ачыргаланды Ләис.

— Ничек җитәкче хакында шундый сүз әйтә ала-

сың?! — Тетя Гаша ачуыннан бүртенеп чыкты.

— Качмаса, кая соң ул?

Шунда гына "Идел"ләр баш мөхәррирнең юклыгын абайлап алдылар.

— Альберт та качкан! — Рушаниянең тавышында сөенү чаткылары биеште.

— Ркаил дә юк... — Гөлсирә Баязитны тагын да кысыбрак кочты.

— Вот черт! Марат та удрал. — Роза Кожевникова ачу катыш үпкә белән өстәп куйды. — Биш сум долгы бар килеш.

— "Волга"га мунчаны тагып качканнар! — дип ачыклык кертте Нәбирә. — Шушы минуттан капитанлык вазифасын үз өстемә алам. Качакларны куып җитеп "Волга" белән мунчаны тартып алырга кирәк. Алай гына булмый ул.

* * *

... Яр буенда туктап торган таныш "Волга"ны күреп, Ләбиб адымнарын тизләтте. "Мине эзләп чыккан егетләр, ташламауларына рәхмәт..."

Машина эчендә Марат, Альберт, Ркаил таралып йоклый иде. Машина түбәсен йодрык белән төйгәч кенә уяндылар.

— Ләбиб кайткан, Марат, ач ишекне. — Ркаил кабат йоклап китте.

Ләбибнең иртә таңнан фатир ишеге шакуына Марат күнеккән иде.

— Алып кердеңме, әзи? — диде ул гадәттәгечә.

Альбертка да җан инде — күзләрен ачты.

— Бармы су-у-н? — дип сузды ул.

— Эзләп табуыгызга рәхмәт. — Ләбиб үзен кочаклап "сөеп" алды. — Катып беттем бу яр буенда.

Марат белән Альберт бер-берсенә карашып алдылар.

— Нинди яр буенда?!

— Менә бу. Пивнушка түгел, адәм заты да юк.

Күзләр тәрәзәгә текәлде.

— ?!.

Әфган Маратның тавышы калтырамады:

— Ркаил, тор, безне яр буена ташлап киткәннәр.

— Юкны сөйләмә. Берсәк йоклыйм әле.

Альберт авыр сулады.

— Баш редактор әйткән иде аны, машинага кереп йокламагыз дип. Ачуы килгәндер инде...

— Безне эштән куарга күптән кызыга иде. — Маратның маңгае тәрәз пыяласыдай парланды. — Теләгенә иреште якташ...

Ләбиб өмет сүнеп барган күзләрен Ркаилгә текәде.

— Тор әле. Боларның сүзләрендә ни иман, ни мәгънә...

— Машинага керткән өчен рәхмәт әйт, — дип мыгырдады Ркаил йокы аралаш. — Бар, салкын каютаңа кереп йокла...

Шулай шактый тарткалашканнан соң, ниһаять, дуслар аңлаштылар. Ркаилнең генә йокысыннан бүленәсе килмәде. Машинаны "турыга ялгап" кабызгач кына күзләрен шарландырып торып утырды.

— Нишлисез?! Машинаны яхтадан төшерәсез, фәләннәр!

Ниһаять, ул да уянды.

— Бездән котылыр өчен машинасын да җәлләмәгән Ташар. Бавырына таш булып утырганбыз, ахры. Бавырдан ташны алай җиңел генә чыгарып булмый ул. Бигрәк тә минем кебек зур ташны. Белә торсын. Бавыр үзе чыгып очарга мөмкин! Куып җитик яхтаны.

Руль артына кемне утырту хакында бәхәс китте. Альберт белән Ләбибнең шоферлар курсына йөреп, машина белән цирк тирәли берничә кат ураганнары бар иде.

Ркаил бәхәсне тиз өзде:

— Ләбиб, син җәяү йөргәндә дә кызу атлыйсың, рульгә син утыр.

Комлы яр буйлап "Волга" алга ыргылды. Ярты сәгатьтән аркасына биштәр аскан юлчы күренде. "Тырттырт" атлаулары, ара-тирә салулап китүләре бик тә таныш иде.

— Рәфикъ абый түгелме соң бу, егетләр?

Якынлашып килүче машинаны күреп, юлчы кырт борылды да куаклар арасына кереп югалды.

— Тач шул. Безне таныды — утырасы килми. Әчтерханга тәки җәяүләп барып җитәр бу.

Яр буйлап җилдерә торгач, машина эзе күренде.

— Зур юл да якын булырга тиеш, — диде Ләбиб. — Бензин бетеп килә. Кырык градуслысын салырга кирәк.

Ярты сәгатьтән аркасына биштәр аскан юлчы күренде. "Кырт-кырт" атлаулары, янтаебрак барулары бик тә таныш иде.

— Тагын Рәфикъ абый түгелме соң бу, егетләр?!

— Үзе шул...

— Кайчан безне узды соң әле ул?

— Мин җитмештән төшермәдем, — диде Ләбиб. — Безне узып бу кадәр ара китәр өчен ул җәяүләп иң кимендә йөз кырык белән барырга тиеш...

Ажгырып килүче машинаны күреп, юлчы кабат куаклар арасына каерды.

Тиздән яр буе комында ике машина эзе ярылып ята иде инде.

Ләбиб кипкән иреннәрен ялап алды:

— Әйттем бит, зур юл якын, дип.

Кабат таныш юлчы күренде...

Түземе төкәнде Ркаилнең:

— Төш, Ләбиб, машина белән Рәфикъ Юнысны да уза алмадың. Утыр, Альберт, рульгә.

Альберт юлчыны күз ачып йомганчы куып җитте, хәтта таптый язды, чөнки юлчы бу юлы куаклыкка качмады, учакта ялан аягын җылытып кәһва эчүен дәвам итте.

Егетләр машинадан сикерешеп төштеләр.

— Сәлам, Рәфикъ абый!

— Все-таки нашли меня, — дип үзалдына мыгырданды кәһва эчүче.

Кәһва исе борынны һәм хәтерне кытыклады.

— Илгиз Хәбибҗанов ?!

— Как видите...

Дүрт-биш ел элек "Идел" журналында "Камытсызга — камыт" исемле романын бастырган, романда бер вагон кәһва кая югалганын белүчегә дүрт миллион акча вәгъдә иткән, акча бирер вакыт җиткәч Казаннан чыгып

качкан, милиция дә, Интерпол да таба алмаган Илгиз Хәбибҗанов иде бу мосафир. Бер вагон кәһваның соңгы чеметемнәрен ашыгып-ашыгып эчеп утырган чагы иде.

Кәһва эчәсе килми иде Ләбибнең.

— Зур юлга ничек чыгып була?

— Никак...

— Бөгештереп утырма, Илгиз. — Ркаил йодрыкларын төйнәде.

— Это — необитаемый остров...

Илгиз Хәбибҗановны аяк-кулларын бәйләп "Волга"ның артына салдылар.

— Утрау, имеш. Тагын безне алдамакчы. Дүрт миллионыңны түләмичә моннан чыгасың юк, — Ркаил капотны шапылдатып япты.

... Әйләнчек сарык шикелле утрау тирәли йөргән "Волга"ны иң беренче шофер Ринат Насыйбуллин күреп алды. "ГАИ тотса, правамны алдыралар болар — кара, ничек җилдерәләр!"

Ярга төшү белән яңа капитан әмер бирде:

— Кулга-кул тотынышып машина каршына басыгыз!

Волга "тере чылбырга" терәлеп үк туктады. Машинадан Ркаил атылып чыкты:

— Кая Ташар?!

Ркаилнең каршысына "туп" итеп Нәбирә килеп басты.

— Качаклар! Сезнең белән бергә качты бит Рашат. Кая ул? Кая куйдыгыз редакция мунчасын?

— Нигә безне ташлап киттегез?

— Сез киттегез безне ташлап!

Шулай озак бәхәсләшкәннән соң гаеплене таптылар — үзе юкның күзе юк, диләр бит — баш мөхәррир "Волга"ны яр буена төртеп төшергән, үзе мунчага утырып киткән.

Машинаны яхтага урнаштырып, мунчаны эзләргә кузгалдылар. Кояш баеп барганда табылды мунча — шәһәр дамбасына килеп бәялгән иде ул.

Мунча эченнән пиннек белән шап-шоп чабынган, "ах-ух" иткән тавышлар килә. Гөлсинә дикъкать белән тыңлап торды да:

— Мунчада ике кеше. Берсе хатын-кыз. Тавышы Моника Левинскиныкына охшаган. Икенчесе кем икәнне әйтеп тору да кирәкми, — диде.

Ркаил күкле-яшелле итеп көлде:

— "Импичмент"ның татар сүзе икәнен беләсезме?

— "Мин эчмим бит". Шулмы? — диде Ринат.

— "Мин печмим бит". Шул сүзме, әзи? — диде Марат.

— Юк. Импичмент өч тамырдан тора. Ягъни, башта ИМәләр, аннан ПЕЧәләр, шуннан соң МЕНТ килә.

— Мунчадан куып чыгарыйк шул оятсызларны, — дип шаулаша башлады кызлар.

Каен себеркесе белән бил турларын каплаган ике бомжны мунчадан җилтерәтеп чыгарганда, яхтаның трюм капкачы шыгырдап ачылды, бер сугуда кирпеч вата торган таныш кул күренде.

— Әнәс Баталовның "Канлы Иблисен" укып яттым. Әйбәт китап икән ул...

Төгән ТӨГӘНОВ

Кыямәт җиле

Сембер каласы кунакчыл кала булып чыкты.

Нигә дисезме?

Соң, узган атна башында ук калага чыгып киткән кунакларның әле һаман да карабка әйләнеп кайтканнары юк. Кунак дигәнебез — Рашат белән Тетя Гаша да, Ләис белән шофер Ринат, һәм дә Ркаилнең улы кечкенә Баязит иде.

— Эш белән йөри торгандыр инде алар, — диде кемдер, икеләнеп кенә.

— Бер атна элек чыгып киткән кеше әллә бар, әллә юк дигәндәй, әйдәгез булмаса, кузгала торыйк, җәмәгать? — диде Гөлсинә.

— Ярамас, сүзе булыр, проезднойга акча бирмәсләр, сезнең ГЖИга барасыгыз юк, — дип кайчандыр бию ансамбленә йөргән аяклары белән чечеткага басып куйды Нәгыйм.

— Гаша тавыксыз калдырыр дип куркасыңмы әллә? Егетләрне ярата ул, син куштанны бигрәк тә, — дип усал карап куйды Рушания. — Безнең бүлмәгә аның рөхсәте белән генә керәсең түгелме соң инде хәзер?

— Баш авырта... — диде Ләбиб.

— Кызганыч, ярдәм итә алмыйм, теге югалган 500 тәңкәнең йөзе генә кайтса да мин синең якын дустыңа әверелә алыр идем, — дип сулкылдап елап җибәрде Гөлсинә.

— Баш авыртканнан дарда дару сорамыйлар! — диде Ркаил, акча югалу вакыйгасыннан читкә китү өчен. — Кемнеке?

— Юк баш авыртмый ул! — дип кырт кисте Мөдәррис.

— Кемнеке дим — шигырь кемнеке? — диде Ркаил, гасабиланып.

— Нинди шигырь? — диештеләр палубадагылар.

Ркаил кабатлады.

— Даруы аңлашыла, — диде Ләбиб, — тик юк бит әле ул...

— Фәйзуллин булса кирәк бу, — диде Мәгъсум абый, калын кашларына мәгънә салып, — Шушылай итеп берьюллыкларны бу көенчә ул гына сырлый ала торгандыр инде, мөгаен.

— ... Аннары китап итеп тә чыгара, — диде Марат.

— Французның атаклы шагыйре Франсуа Вийон моннан биш гасыр элек шәп итеп язып калдырган — ничу аны кабатлап торырга! — дип янә кырт кисте Мөдәррис әкә.

— Коллар без — үзара хан булып кыланабыз! — Бу мәлдә Ркаилнең тавышы ачыргаланып кычкырган акчарлак тавышына охшаган иде.

— Ярый әле проза яза башлады! — дип уйлады Марат, — югыйсә тора-бара өч-ике-бер сүзлек шигырьләргә дә күчкән булыр иде...

Тагы нидер әйтергә дип авыз ачкан Ркаил кинәт кенә туктап калды. Хәер, палубадагыларның бөтен игътибары Марат кулында ялтыраган сырлы шешәгә төбәлгән иде.

— Дуләнә төнәтмәсе — дип аңлатты Марат, — теге

чакта, Казанда, әптиккә сугылдым да, почтамтка барып та тормадым инде.

Сырлы шешә Ләбиб кулына күчте.

— Кырык тамчыдан да артыгы ярамый — әрмән коньягы белән бер чама, — дип кисәтте Марат.

Ниһаять, Ләбибкә дә җан керде. Хәер, башкаларның да йөзе яктыра, теле ачыла төшкән иде.

— Сине, Марат, карабның табибы итеп кенә куярга кирәк! — диде кемдер.

— Бавыр-бөерләрегез эштән чыга калса, миңа үпкәләмәгез түлке, — диде тегесе.

— Хаҗитарханга бару сәяхәтнамәсен кайсыгыз язарга булды соң инде, җегетләр? — дип, Мәгъсум Хуҗин әңгәмәне башка юнәлешкә борып җибәрде.

— Нәбирә белән Ркаилдән дә шәп язучысы булмас, — диде Солтан Шәмси, — Станбулын-Лондонын, Финляндиясен аркылыга-буйга йөреп чыккан кешеләр бит...

— Әнә, Ләбиб язсын! Ул теләсә нәрсә турында теләсә ни яза ала, — диде Ркаил.

— "Идел" тартып кына язарсың, пычагым! "Мальборо", йә булмаса "Парламент" тартсаң бер хәл иде әле... — дип аягын болгап алды Ләбиб. — Сезгә рәхәт, сез — җүләр...

— Бездән соң да эз кала дип көймәләр сөенә, — диде Ркаил, сүнә башлаган әңгәмәнең дилбегәсен үз кулына бөтәрләп. — Кемнеке?

Тик бу юлы да аңа колак салучы булмады.

Һәммәсе дә эре балык тәңкәләредәй җемелдәүче Идел суына текәлгәннәр иде.

— Боралак! — дип кычкырып җибәрде Марат, — суга тияр-тимәс кенә бара минсиңайтим!

"Боралак"ны "бурлак" дип аңлаган бухгалтер Альберт Идел ярына карап алды. Дөрестән дә, бик еракта — Иделнең сул ярында биш адәм кырмыскадай нидер сөйрәп маташа иде.

— Да-а, бурлаклар заманы да кире кайтты бит, — дип уйлады Альберт, аннары исә мыек астыннан гына көлемсерәп куйды: "Су-ун, бөтен кешегә дә бухгалтер булырга димәгән лә — акча санау өчен иң әлек аркан тартучыларның булуы кирәк".

Озын баржа сөйрәп килүче вертолетны күргәч, барысы да "аһ" иттеләр.

— Кем булыр икән бу? — диде Нәгыйм, башын кашып.

— МИ-8! — диде Марат.

— Кем булса да, безне барыбер узып китәчәк! — дип гадәтенчә кырт кисте Әкә.

— Болар Югославуга гуманитар ярдәм алып баручылар түгел микән, дип уйлыйм мин, — диде салмак кына Мәгъсум Хуҗин.

Берничә минуттан вертолет Идел өстендә чайкалган яхтаны куып та җитте. Озын баржа яхтага килеп терәлде. Боралак җиленнән чыккан көчле һава дулкыны һәммәсен дә палубага сузып салды. Ул да булмады, вертолет уемында ярым ялангач бер адәм күренде. Ләис иде бу!

— Суга сикерергә җыена! — дип чыркылдашты кайбер кызлар.

— О, Боже! — диде рәссам Фәридә, күзен йомып.

— Ну, зачем это надо? — диде Идел буенда туып үскән Әчтерхан кызы Роза.

Чыннан да, астагыларның бөтен игътибарын үзенә туплаган Ләис, теләр-теләмәс кенә, "ярар инде, тик сезнең өчен генә" ди-



гәндәй, тук гәүдәсен Иделгә ыргытты һәм бик тәмләп йөзеп тә китте.

— Ну бу номеры белән борынга шәп чиртте Ләис, — дип уйлады Ркаил, дустыннан ак күңелләшү белән көнләшеп, — әгәр дә баскыч төшерсәләр, миңа да менеп сикерәсе булыр. Мондый форсат сирәк эләгә...

Аркан баскыч төшеп килә иде инде. Тәгәлрәге, мичкә төшеп килә иде — имән мичкә! Әмма мичкә дигәннәре Тетя Гаша булып чыкты. Тагы да төгәлрәге, аны баскычка бәйләнгән мичкәгә утырткан иде.

Гаша үзе төшеп бара, үзе кычкыра:

— Ләис, Ләис дим, бата күрмә берүк, суык тидерәсең бит, чык тизрәк!

Бөтен игътибарның үзенә түгел, ә мичкәгә, әй лә, шул мичкәгә утырган Тетя Гашага юнәлүен абайлап алган Ләис инде карабка үрмәли иде.

Гаша төшеп тә җитте, тезә дә башлады:

— Егетләр-кызлар, чатыр җәегез тизрәк, хәзер Рашат Мияссәребич төшәчәк, егыла-нитә калса, чатыр әзер булсын ыштубы!

— Кем-кем, Баязит Ркаилевич бар әле анда! — диде Ркаил, нигәдер йөзен чытып.

Тиздән боралак уемында Рашат үзе дә күренде. Ул Баязитны култык астына кыстырган иде.

Алар утырган имән мичкә палубага төшеп җиткәч, барысы да җиңел сулап куйдылар:

Ниһаять, һәммәбез дә бергә җыелдык!

Имән мичкәгә утырып яхтага төшеп барган чагында Рашатның башына даһи фикер килгән иде. "Идел"нең "Волга"сы белән яхтаны сатарга! Сатып, шушы вертолетны алырга! Соң, хатыныңны, бала-чагаңны төяп вертолетта туган авылыңа кайтып төшүе үзе ни тора! "Баш мөхәррирләрнең бөтенесенең дә борынына чиртәм болай булса", — дип уйлады ул мичкәдән сикереп чыкканда.

Сикереп тә чыкты, үз кырына Гаша белән Альбертны чакырып та алды. Беркавым чыш-пыш килгәннең соңында, Гашаның тавышы ишетелде:

— Зинһар өчен, Рашат Мияссәребич, кирәкми, берүк кирәкми, һавада йөрүләре хәзер би-ик куркыныч!

Рашат: "Шулай дисезмени инде, ярар, алай булгачтын, нишләмәк кирәк..." — дигәндәй башын кыңгыр салып бераз уйланып торды да, кинәт кенә уң кулын югары селтәде. Уң кулы белән эш итәргә ярата иде ул.

Боралак башта югарыга томырылды, аннары исә үзе генә белгән бер юнәлешен табып, тыр-тыр килеп күздән дә югалды.

Тимер-бетон плитә өелгән озын баржаны яхтага тагып куйдылар. Баржа түрендә "Идел"нең "Волга"сы тора иде.

Рашат капитан күперчегенә күтәрелде:

— Җәмәгать! — диде ул, бик мәгънәле итеп, — Без, ягъни мәсәлән, мин, Гәүһәрия апа һәм Ләис...

— Һәм Баязит! — дип өстәде астан кемдер.

Баш мөхәррир аңа карамый сүзен дәвам итте:

— ...Бик зур эш башкарып кайттык бит әле. Үтә затлы итеп эшләнгән тимер-бетон плитәләр алып кайттык. Баржасы-ние белән!

— Һәр кеше башына икешәр плитә тия! — дип сүзгә кысылды Гаша. — Берәм-берәм генә килегез дә, менә монда кул куегыз!

Әмма кул куярга уйлаучы да булмады. Анысы, вакыт-вакыт йомырка-тавык, шикәр комы, кәнфит-мәнфит ише нәрсәләргә кул куйсалар да, бу мәлдә "Идел"челәр, башларына тимер-бетон плитә төшкәндәй, тәмам исәңгерәп калганнар иде.

Безнең халык юкка гына: "Киңәшле эш таркалмас" дими ләбаса — "Идел"дәшләр дә киңәш-табыш итә торгач, беркавымнан уртак фикергә килделәр: "Әчтерханга төшеп җиткәч тә тимер-бетон плитәләрне баржасы ние белән карбызга алыштырырга!"

Шәп фикер иде бу!

— Әчтерханда гектарыннан җиде тонна карбыз җыеп алалар! — дип, аларның фикерен Әкә дә ныгытып куйды.

Бераздан бүләк баржаның төбе тишек булуы ачыкланды. "Идел"нең бөтен көче баржаны ямауга юнәлде.

* * *

Гадәттәгечә, Света бик иртә уянды һәм иңенә сөлге салып палубага чыкты. Менә хәзер Иделдән бер чиләк су чумырып алыр да өстенә кояр. Шунда аның иркенлеккә күнегеп өлгергән күз карашы тал-тирәкләр үсеп утырган сөзәк ярга төртелде. Света артка борылып карады. Икенче яр тегесеннән дә якынрак иде.

— Гульфия! Гульсина! Рушания! Рашат Мияссарович!

Баш мөхәррир гадәттәгечә сак йоклый иде.

— Нәрсә тагын?! — дип мыгырдады ул машина тәрәзәсеннән башын тыгып. — Гонорарыңны кискәнем исеңә төштеме, таң тишегеннән уятып үчләшмәсәң?!

— Иван Сусанин! Куда ты нас ведешь?

— Өйрәтмә син мине яме, редакцияне нинди юл белән алып барасын сиңа караганда яхшырак беләм мин.

— Иделдән в болото завлек, не видите что ли?!

Рашат күзләренә ышанмады: Идел тарайган иде. Нык тарайган иде. Хәтта "бик нык" дигәндә дә, арттыру түгел, киметү генә булачак иде...

Баш мөхәррир ушына килгәнче Бурсык белән танышa торыйк әле.

"Идел" журналы ишегалдындагы корама агач йортта Ринат атлы елгачы матрос яши иде. Шуның мәчесе иде Бурсык. Һәр җәй саен хуҗасы белән Идел гиздe мачы, теплоход туктаган саен ярга төшеп үз тамгасын салды, һәр шәһәр саен нәселен ишәйтте.

Матрос Ринат пенсиягә чыккач Бурсыкны "Идел" журналына тапшырды. "Иделсез яши алмый, бахыр. Редакциягез дә теплоходка охшаган — адым саен кумырык бүлмә-каюта. Егетләрегез дә карабтагы сыман чайкала. Алыгыз Бурсыкны "Идел"гә", — диде. Иделнең һәр борылышын белгән Бурсыкны баш мөхәррир "Иделлия-Казан" яхтасына лоцман итеп алды. Мачы капитан күперчегенең кайсы ягына барып ятса, штурвалны шул якка борды.

...Капитан күперчегенә эленгән сабан төрәне — "Иделлия-Казан" чаңы шомлы аваз салгач, яхта эчендә сукранган тавышлар ишетелә башлады:

— Тагын Баязит йокы бирми инде!

— Ркаил, алып кайтып кит шул ташбашыңны!

Света каютадан каютага яңалык таратмаса, Баязитны һаман да талкыйлар иде әле.

Һәммәсе дә палубага җыелды.

Суга кереп юеш койрыгы белән чебен куган сыерның маңгаена төкерде Ркаил:

— Килеп җиттек Әчтерханга!

Гөлфия икенче як ярдагы казларны чакыра башлады.

— Гәз-гәз-гәз, гәз-гәз-гәз! Бигрәк тә әниемнең казларына охшагансыз.

— Куда мы плывем?! — Роза Кожевникова ушына килде. — Это же не Идель?!

— Идел булмый ни булсын! — Бурсыкны күтәреп баш мөхәррир капитан күперчегенә менеп басты. — Агамы? Ага! Агым уңаена йөзәбезме?! Агым уңаена йөзәбез!

— Аңлатып сөйлә! — дип кычкырдылар астан.

— Беренчедән, Иделгә бик күп елгалар коя. Икенчедән, шуларның берсенә ялгышып кергән булсак, без агымга каршы йөзәр идек.

"Идел"ләр аптырашып калдылар.

— Но это же не Идель? — Роза Кожевникова гасабиланып елый ук башлады. — Идел широ-о-окая...

— Никадәр авыр булса да, чынбарлыкның йөзенә туры карарга кирәк, Роза ханым. Дастаннарда данланган бөек елгабыз күз алдында кибеп-корып ята. Фаҗигамe бу? Фаҗига бу! Мин әлеге сәяхәт-экспедицияне шуңа оештырдым да инде. Иделне "Идел" журналы гына коткара ала. Журнал битләрендә чаң сугарга кирәк! Баш мәкаләне үзем язам.

Идел генәме, дөньясы корып-кырылып ята бит аның, — диде Гөлсирә. — Нинди Алла каргаган заман булды инде бу!

— Карагыз әле, җәмәгать, карагыз! — Солтан Шәмсинең тавышы нечкәреп, калтырап чыкты. Бик нык дулкынланганда гына шулай үзгәрә иде аның тавышы. — Бүре тамгасы, Көнбатыштан күтәрелә!

Дәррәү көнбатышка таба карадылар.

— Әстәгъфирулла! — диде Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Ркаил Зәйдулла агарынып. — Кояш көнбатыштан калка!

— Нәрсәгә булыр бу?!

— Ахырзаман җитте микәнни?

— Ахырзаман кайчан була дигәч, Гайса пәйгамбәр ике бармагын күрсәткән!

— Ә Нострадамус дөнья быел бетә дигән. — Марат көйләп укып та җибәрде: — *Туксан тугызынчы елны җиргә олы курку иңәр!*

Җиргә ничектер, белмим, ә менә "Иделлия-Казан" экипажына иңүе хак. Хәтта Бурсык та күккә карап бик сәер мияулый башлады.

Бурсык мияулап бетерүгә Нәбирәнең бәгырь түреннән иңрәп чыккан сүзләре ишетелде:

— Повестем бетмичә кала инде... Иң шәбе буласы иде...

— Ичмасам унъеллык җитеп рәхәтләнеп бер типтереп тә кала алмадык! Соңгы тапкыр! — бусы Светлана сылуның җан авазы иде. Чибәребез бу сүзләрне чатнатып саф ана телендә әйтте. Әйтте дә, үзе дә аптырап калды. Ләкин хезмәттәшләре гаҗәпләнерлек хәлдә түгел иде инде.

— Паникага бирелмәскә! Билгеләнгән планны бозарга не поз—во—лю! Бераүгә дә! — Баш мөхәррир башта палубадагыларга, аннары шомлы рәвештә куч-кылланган күк йөзенә йодрык изәп алды. — Әлегә монда без капитан. Ә суднода капитан ул — патша да, Алл... — капитанның башта бик гайрәтле чыккан тавышы йомшарганнан-йошара барып, ахырдан бөтенләй киселде. Запастагы өлкән лейтенантның кайчандыр Тоцкидагы учениедә баш бирмәс солдатны бәреп еккан саллы йодрыгы күктәге Бүре тамгасы янында бик мескен күренә иде шул.

Җаннарга шом йөгерде. Белгәннәрен укый башладылар.

Солтан Шәмсинең йөзендә генә курку әсәре юк иде. "Томана шул безнең халык, эзотериканы белмиләр", дип уфтанды ул. Кызлар куркып елаша башлагач, тынычландырырга булды.

— Тыңлагыз әле мине. Бүген кояшның көнбатыштан чыгуына бер дә аптырарга һәм куркырга кирәкми. Җир шарының полюсы үзгәргәнгә, ягъни төньяк котып көньякка, ә көньяк котып төньякка күчкәнгә кояш көнбатыштан чыга ул. Мондый үзгәреш 12-13 мең ел саен кабатланып тора. Без бик бәхетле кешеләр. Шундый сирәк күренешне үз күзебез белән күрергә насыйп булды.

Әмма шунысы да бар: котыплар алышынганда Җир шарының өслеге сәгатенә 4 мең километр тизлек белән хәрәкәт итә башлый. Ә җилләр сәгатенә 2 мең километр тизлек белән исә һәм юлындагы бөтен нәрсәне себереп түгә. Югары акыллы, җаны чиста кешеләр генә әле без тормыш иткән өч үлчәмле яссылыктан дүрт үлчәмле яссылыкка күчеп исән калалар.

Шулай да төшенкелеккә бирелмәгез. Әле үзгәрергә, яхшырырга вакыт бар. Кыямәт җиле монда бер айдан, ә иң тиз дигәндә 20 сәгатьтән, килеп җитәчәк.

...һәркем күңеленә бикләнеп гөнаһларын барлый башлады, чистару юлларын эзләде. Бик күпләр уразага керде. "Идел"дә Ркаил Зәйдулла белән мәрхүм Фәиз Зөлкарнәй аны элек тә калдырмыйлар иде. Ләбиб Лерон әбисеннән отып алган догаларны исенә төшереп яхтаның мулласы булып китте. Ркаил машина багажнигында тоткынлыкта ятучы Илгиз Хәбибҗановны иреккә чыгарды, бар булган киемен салып бирде, дәрвишлек юлына басты. Шулай 30 көн үтеп тә китте.

Кешеләр яхшырды. Идел кабат киңәйде. Кояш көнчыгыштан чыга башлады. Кыямәт җиле исмәде.

* * *

Көн аяз. Тирә-юньдә су. Күктә — кояш. Кыскасы, хозурлык. Яхта да шәп кенә алга элдерә. Күңелләре тулышкан кызлар җыр суздылар:

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

Әйе, табигатьнең бер генә чалымы да давыл буласын искәртми иде әле.

(Ахыры 52 нче биттә)

Ахыры. Башы 34 биттә

Унъеллык уңаеннан мин хезмәттәшләремә күбрәк мөстәкыйльлек, эш өчен күбрәк җаваплылык һәм иҗатка омтылышлары сүнмәвен теләр идем. Әлбәттә инде, үземә дә.

Розаның уң кулы, урынбасары Нәгыйм булмаса, журнал бөтенләй чыкмас, нәшрият ишек төбендә терәлеп калыр иде. Имеш, 9 ел "Идел" белән типография арасында килеп сарып йөри-йөри, Нәгыймебез 100 пар башмак туздырган ди. Журналны төпләтә-ямата, кистерә-тектерә аптырагач, ул хикәяләр язарга кереште. Романга да күчкән бугай, бу көннәрдә озак кына югалып торды. "Иҗади абзарда бикләнеп яткан", — дип сөйли гайбәтчеләр.

Нәгыйм Шаһи:

— Мин "Идел"не җигелеп тартучылар төркеменә килеп кушылганга 9 ел үтте. Бәйрәмебез көннәрендә тәртәләр арасыннан чыгып, бераз төшереп-мөшереп, кәефләнеп алгач, яңадан җигелеп алга таба җилдерергә исәп. Коллективка исәнлек-саулык, бәхет телим!

"Идел"нең машинасы да "Идел", ягъни "Волга". Шоферыбыз — чибәр, ыспай Ринат "ак караб"ны кадерләп кенә йөртә. Юкка-барга тәгәрмәч туздырмый. Ирләр машинаны хатын-кыздан да артыграк ярата диләр, хак бугай. Ринатта да шундыйрак мәхәббәт сизелә.

Ринат Насыйбуллин:

— "Идел" — туган йортым кебек. Юл фаҗигасенә эләккәч, мине үлем хәлендә хастаханәгә озаталар*. Айлар буе түшәктә ятканда коллектив ташламады, рәхмәт яусын аларга! Савыгып аякка баскач мин сөенә-сөенә кире "Идел"челәр янына кайттым.

Чираттагы "безнеке" — Резидә. Диңгезне хәтерләткән зәңгәр күзле, димәк чып-чын Идел кызы. Ә "Идел"дә — чып-чын хуҗалык мөдире. Каләм, бетергеч, җылыткыч, каптыргыч, элэктергеч һ.б. әйберләр сорап без аңа йөгерәбез. Журналга язылмаган авторлар өчен фәләненче саннарны да аңардан таптырабыз. Резидәбез подписканы да кайгырта, төрлетөрле документлар, приказлар белән әвәрә килә, кассир вазифасын да башкара.

Резидә Әхмәтҗанова:

— "Идел"дә эшли башлаган көннәр иде. "Иртәгә өмә", диделәр. Элек эшләгән җиремдә түрә-мазар өмәгә катнашмый иде, ә монда ни күрим, баш мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй дә, Рәфикъ абый Юныс та, бүлек мөхәррирләре дә — һәммәсе, һәммәсе эш киемнәреннән килгәннәр, берсендә дә "мин — баш", "мин — язучы" дигән масаю юк.

Икътисад буенча урынбасарыбыз, баш бухгалтер Альберт Сөләйманов — акча капчыгы. (Ләкин еш кына аның капчыгы буш була.) Хезмәт хакы аласы көнне Альбертны күтә-күтә күзләр күгәрә. Ярый әле ул, бер атнадан, бер айдан, дип күңелне җылытып тора. Ала каргадан алачагың булсын, ди бит. Альбертыбыз безне кайгыртыр инде. Юкка гына аңа Мәскәү абзый "Профессиональ баш бухгалтер, консультант" дигән дәрәҗәле аттестат тоттырмагандыр ич!

---

* Ф. Зөлкарнәй шул хәлләрдән соң дөнья куйды.

Альберт Сөләйманов:

— "Идел"гә искиткеч кызык шәхесләр җыелган. Шуларны ачялангач итмим дип, көн-төн акча табу турында уйлыйм да, шундый нәтиҗә ясыйм: акча булыр, исәнлек кирәк. Күңелегезне төшермәгез, "Идел"челәр! Бәйрәм белән котлыйм сезне!

Бүлек мөхәррире Солтаныбыз "Идел"дән китеп торды да, янә әйләнеп кайтты. "Кызыклы эзотерика" дигән яңа сәхифә ачып, "Теге дөньядан иңгән хатлар"ны саннан санга ул тәкъдим итеп барды. Аның әле ачылып бетмәгән серләре күп бугай. Бәлки Галәм белән бәйләнешкә кергән танышлары турында да язмалар әзерләр. Ул — тарихи темаларны да үз иткән, даими эзләнгән, иҗат утын сүндермәгән талантлы язучы.

Солтан Шәмси:

— Мин 90-91 елларда "Идел"дә эшләп алып, җиде елдан соң, бумеранг сыман, кире әйләнеп кайттым. "Идел"нең сихри тарту көче бар — ул журналның беренче саннарында ук үзен сиздерде: кыюлык, милләтпәрвәрлек, көн кадагына суга белү, тарихи язмалар аша халкыбызның күзен, аңын ачу...

"Идел" — әдәбиятка килүче яшь көчләрне тарта, аларга мәйдан бирә...

"Идел" — милләтпәрвәр басма. Миңа аның шушы сыйфатлары якын.

"Идел" өчен язу зур канәгатьләнү китерә, чөнки шушы ун ел эчендә журналның даими укучылары барлыкка килде. Аларның ни көткәнен күңел сизә, укучыларыбызның өметен аклыйсы килә...

"Кәгазьче" Гәүһәрия ханым пенсиягә чыкса да "Идел"дә "йөзә". Иделнең күңеле киң шул.

Гәүһәрия Кәримуллина:

— Гәзит-журнал нәшриятында кәгазь белгече булгангадыр, "Идел"нең беренче саны өчен кәгазь табып бирүемне үтенгәннәр иде. Пермь өлкәсенең Краснокамск шәһәренә киттем. Нәшриятта мин Галина Ивановна булып йөрдем. "Идел"гә килгәч, Гәүһәрия ханым икәнемне белдем.

Инде чират Ләискә җитте. Ул безнең шагыйрь. Бик чибәр. (Кызлар, борчылмагыз, егетебез өйләнгән). Ләис шигырьләр генә түгел, хикәяләр дә яза. Тик соңгы елларда иҗатның бүтән төре белән мәшгуль әле. Авыл хуҗалыгы тормышын өйрәнә...

Ләис Зөлкарнәй:

— Тәмәке, сыра, реклама фирмасыннан битәр Казанда төнге клуб та "Идел" исемен йөртә бит әле. Шул төнге клубның соңгы вакытта "л" хәрефе янмый башлады.

Журналның яңа саны чыккан саен исеменә карыйм: соңгы хәрефе урынындамы, янәсе. "Идел" журналы хакында "иде" дип сөйлисе килмәүдән, ахры.

Менә җәмәгать, "безнекеләр" шундый халык инде. Ничек бар, шулай кабул итегез аларны. Бигайбә!

"Безнекеләр" белән Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА сөйләште.

Ә Нәбирә Гыйматдинова белән "без" сөйләшәчәкбез.

Үзебезнең "шәп халык" икәнне белгәч, җиңел сулап куйдык әле без. Ни дисәң дә, Нәбирәбез тасма телләр кавеменнән түгел ул.

"Ә кем соң әле ул Нәбирә Гыйматдинова?" — татар дөньясында мондый сорауны бирүче табылмастыр. Чыгарган китаплары да әнә "иң популяр китап" исемен ала тора. "Идел"гә килгән мактау сүзләренең дә күбесе Нәбирә өлешенә тия. Көнләшмәс җиреңнән көнләшерсең, билләһи!

Нәбирә Гыйматдинова — төрле очрашуларда иң алга чыгара торган "примабыз" да, төпкә җигелеп тартучы эш атыбыз да.

Нәбирә Гыйматдинова:

— "Идел"нең беренче эш көне иде. Утырырга урындык, язарга өстәл юк. Комсомол өлкә комитетыннан иске-москы китереп ташладылар. Ә миңа Язучылар берлегенең ул чактагы рәисе Туфан Миңнуллин үз бүлмәсеннән өр-яңа яшел кәнәфи бүләк итте. Балалар кебек сөендем, бөтенесенә мактандым. Туфан абый рәислектән китте, минем кәнәфи дә очты. Берлекнең яңа җитәкчеләре: " бу безнеке" дип алып чыктылар. Ярый алып чыкканнар, йомшакка утырып бозылып бетәр идең. Кәнәфи аркасында харап булучылар әзмени!

Әчтерхан чикләвеге

(Ахыры. Башы 28 нче биттә)

Әнә, палуба буйлап тыныч кына күсе малае үтеп бара. Бурсык аны, мыегын җыерып кына, капитан күперчегеннән озатып кала.

— Күселәр карабтан шыларга җыенмый. Димәк, батмаячакбыз. Давыл да булмас, — дигән нәтиҗәгә килә боларны күзәтеп утырган Гөлсирә.

Давыл исә көтмәгәндә, кинәт кенә купты. Ерак кыйтгалардан көч-дәһшәт туплап килгән циклон иде бу. Тыныч кына йокымсырап, изрәп яткан Идел бер мизгелдә уянды да куйды, минсиңайтим!

— Җәмәгать, барыгыз да — кают-компаниягә! — диде Рашат. — Ә мин "Волга"ны ташлый алмыйм инде — журнал мөлкәте бит.

Барысы да бергә җыелды. Урын тапканы утырды, тапмаганы басып калды.

Кают-компания дигәч тә... Хәер, соң булса да уң булсын дигәндәй, караб белән дә таныштырыйм әле үзегезне. Иң аста — трюм. Бар булмыш мал-мөлкәт, азык-төлек, ягулык шунда сакланырга тиеш. Өстәрәк кают-компания, бәдрәф һәм дә шуның ише вак-төяк бүлмәләр урнашкан. Палуба да шушы яссылыкта ята. Иң өстә — капитан күперчеге — Бурсыкның яраткан урыны. Анысын юлга кузгалыр алдыннан Рашат теләге белән егетләр укмаштырып куйган иде.

Кыскасы, караб та караб, бу да — чын караб!

Инде кают-компаниягә кайтык. Тезеп салсаң, утыз "Идел" журналы сыярлык иркен урын иде бу, җәмәгать. "Идел"нең форматын үзегез беләсез инде — шуны утызга гына тапкырлыйсы кала.

Һәммәсе дә кают-компаниянең бердәнбер түгәрәк тәрәзәсеннән тышны — Иделне күзәтә. Инде әңгермеңгер беленә, дәрья ду килеп шаулый, котырына иде. Бер-бер артлы ябырылган куәтле дулкыннар карабка килеп сыланалар да, тагын чигенәләр, яңа көч белән тагын алга ыргылалар. Күк йөзен кургашындай авыр кара болыт гаскәре яулап алган.

— Кояш кызарып баеса давыл булачак дип уйлаган идем аны, — диде Нәбирә, сер бирмәскә тырышып. Ләкин барысын да шом, төшенкелек шаукымы биләп алган иде инде. Кыямәт җиле була күрмәсен.

Ләбиб тә:

— Акчарлак та яр тирәсендәрәк очты шул — штормга булган икән... — дип ап-аек уй уйлап куйды.

Бу сынамышны ул Хуҗи Мәхмүтовның "Ел фасылы — унике ай" дигән китабыннан укып белә иде. Аннары Мөслимдә туып Актаныш та үскән Ләбиб авылдашы Наил Әюповның кайчандыр әйткән сүзләрен исенә төшерде: "Апаем, безнең якның казлары да суда батып үлә торган бит аның", — дигән иде аңа Наил абыйсы. Шуны исенә төшерде дә, әйтеп бетергесез тирән төшенкелек дәрьясына чумды.

Кают-компаниянең яртысын ук биләп алган көрсидә җәелеп утырган Ркаил, кинәт кенә бөтенесен дә сискәндереп, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Баязит! Баязит кая?

Шунда "Идел" халкы җиңел сулап куйды: ахырзаман ук түгел икән ич әле! Юкса ата улны белер идеме?

Баязит юк иде.

— Рашат янындадыр ул... — диде кемдер, икеләнеп кенә.

— Әйе, әйе, "Волга"да утыра торгандыр әле, — диеште бераз җанланып киткән "Идел"дәшләр.

Ркаил тышка ыргылды. Берничә минуттан исә караб дерт итеп сискәнеп куйды һәм акрын гына кыйшая башлады. Тышта Ркаилнең ни диптер кычкырганы ишетелә, әмма җил, дулкын шавы аның тавышын эчтәгеләргә ишеттерми иде.

...Караб торган саен ныграк кыйшая бара. Җитмәсә, ут та сүнде. Әйтерсең лә һәммәсе дә бер мизгел эчендә дөм караңгы чоңгылга чумдылар.

— Болай булмый, — диде кемдер, Әкә иде ахрысы, — егетләр, минем арттан!

Егетләр, кармалана-кармалана, палубага чыктылар. Палуба аша су таулары тәгәрәшә иде. Ул да булмады, караб, ике аягы белән үрә баскан Салават Юлай айгырыдай, танавы белән өскә ыргылды. Тимер-бетон плитәләр төялгән тишек баржа карабның койрыгын үзе белән су төбенә өстери иде.

— Бетәбез болай булса, — диде кемдер. — Баржадан котылырга кирәк.

Кемдер, баржаны карабтан аерырга дип, суга сикерде.

Голливуд төшергән "Титаник" фильмын күбегезнең караганы бардыр, җәмәгать. Берничә мең кешене утырткан биниһая зур караб океанга чумып бара. Тирә-юньдә иге-чиге булмаган төпсез чоңгыл. Ярдәм күренми. Биниһая зур фаҗига... Инде "Титаник"ны йөз мәртәбә кечерәйтегез дә, безнең каһарманнар утырган "Иделлия" чамасында калдырыгыз. Иксез-чиксез Идел уртасында нәни караб... Кайчандыр әнә шул фильмны җылый-җылый караган кызлар хәзер дөм караңгы кают-компаниядә өнсез утыралар, егетләр исә ни эшләргә дә белмичә әрле-бирле палубада чабыша, Ркаил улын эзли, Рашатның күз карасыдай ак "Волга"сы инде шактыйдан ук үзе белән бергә дуамал Идел кочагында тибрәнә. Үтә кызганыч, бәгырьләрне телә торган күренеш. Шулай бит?

Ниһаять, бераздан караб турая башлады. Теге чакта суга сикергән кемдер аны баржадан аерган иде. Озак та үтмәде, тимер-бетон плитәләр төялгән тишек баржа су төбенә китеп тә барды. Яхтаны каһәр суккан баржадан коткаручы "кемдер" дигәннәре Роза Кожевникова булып чыкты.

— Афәрин! Җегет икәнсең! — диештеләр егетләр. — Юкка гына Идел буенда туып-үсмәгәнсең!

— Баязит! — дип пышылдады, инде кычкыра-кычкыра тамагы беткән Ркаил.

Барысы да дәррәү дулкын сыртында чайкалган "Волга"га карадылар. Машина белән яхта арасы ун

метр чамасы иде. Әкә тиз генә бау табып килде. "Волга"ны буксирга алырга булдылар.

Беркавымнан ак аргамакны карабка арканлап та куйдылар. Машина белән карабтагылар ишарә ярдәмендә генә аңлаша башладылар. Чөнки көчле җил белән дулкын шавы авазларны йота иде.

— "Волга"да Баязит юк. Кая икәнен белмибез", — бу хәбәр килеп ирешүгә, карабтагыларны гүя ток сукты. Ркаил, аңын җуеп, палуба идәненә ауды...

Карабны су төбенә сөйрәүче тишек баржа бербөтен бәланың яртысы гына булган икән әле. Бераз тынып торган Идел янә котыра башлады. Берничә минуттан тау-тау дулкыннар нәни карабны кагып-сугып йөртә, шаркылдап көлгән ак күбекләр палуба идәнен юа иде инде. "Волга"ның багаж капоты бер ачыла, бер ябыла, ә ике арадагы арканга исә бер-берсенә такта белән кадаклап куелган пар мичкә менеп кунаклаган иде.

Бу күренешкә игътибар итүче дә булмады. Чөнки сәяхәтчеләребез ниндидер әйтеп бетергесез татлы, илаһи вә тылсымлы йокыга талып, Галиҗәнаб Вакыт тирәли киләчәккә сәфәр чыкканнар иде.

Ләбиб Лерон төшендә үзен илле яшьлек юбилеенда итеп күрде. Камал театрының сәхнә түрендә утыра икән имеш. Барсы да аны күккә чөеп мактыйлар, илле яшеңдә илле китап чыгардың, афәрин, диләр имеш. Татарстан китап нәшрияты директоры аның кулына әле генә "табадан төшкән" илленче китабын — кроссвордлар җыентыгын тапшыра икән имеш.

Ләис Зөлкарнәй дә төш күрде. Илле яшьлек юбилеена әзерләнеп йөргән көннәрнең берсендә аны Казанның мең дә беренче татар балалар бакчасына очрашуга чакырганнар да, балаларның барсы да: "Бабакай, дәү әти" дип Ләискә килеп сарылалар икән имеш.

Ркаил Зәйдулла күргән төш болайрак иде. Тукай һәйкәле янында шигырь бәйрәме гөрли. Әле гыйнвар аенда гына илле яшен тутырган драматургка "Татарстан" телеканалында җиде ел барган телесериал сценариесе өчен Тукай бүләген тапшыралар имеш.

Әмма кинәт кенә Ркаилнең татлы төше мәхшәр белән алышынды. Һәммәсе дә дөбер-шатыр, пыранзаран килә башлады. Әйтерсең лә Каф тавы ишелә иде. Каяндыр (әллә күктәнме) гөбедән чыккандай көчле тавыш яңгырады:

Тимер ага эреп ярмәкләрдән,
Күк гөмбәзе күптән чәрдәкләнгән,
Бер сүнә дә офык, бер яктыра,
Адәми зат!
Ярлыкауны сора...

— 99 нчы сүрәдән — дип уйлады Ркаил. — Йә Ходам, дөрес тәрҗемә итмәдем микәнни... — Шулай дип уйлап та бетерергә өлгермәде ул, өстенә ишелгән авырлыктан башта өнсез калды, аннары исә, уянып китеп, күзен ачты.

Идел тынган, тирә-юнь тып-тыныч, ерак-еракта таң сызылып килә. Ркаилнең сыртында исә саллы ике мичкә ята иде.

Әле генә безнең каһарман сәяхәтчеләребез Галиҗәнаб Вакыт тирәли киләчәккә сәяхәтләрен тәмамлап, ошбу дөньяга кире кайтып төшкәннәр иде.

Озак кына матавыкланганнан соң, ниһаять, Ркаил мичкәләрне палубага бастырды. Палуба уртасында исә ике капоты да ачылган "Волга" җәйрәп утыра. Ркаил сак кына дөбер-шатыр килеп машинага ыргылды. Багаж капотында, үзе чаклы сазан балыгын кочаклап, аның улы Баязит йоклап ята иде.

— Әйдә, йокласын! — дип пышылдады Ркаил, мыек астыннан гына елмаеп. Улы табылу сөенечен кем беләндер уртаклашырга теләсә дә, мичкәләр янына атлады.

— Хан хәзинәсе шушы мичкәләрдә булмагае, — дип уйлады ул, өметләнеп. Вакыт-вакыт Язмыш Галиҗәнабләре аның да аркасыннан сөйгәләп куя лабаса. Уянып киткәндә ике саллы мичкәнең сыртында ятуын ул, һәрхәлдә, яхшыга юрады. Аннары, тарих китапларын күп укыган кеше буларак, хан хәзинәсенең Кабан күленнән түгел, ә Идел төбеннән килеп чыгачагына нык инанган иде. "Хан хәзинәсенең Зариф Бәшири белән Фәтхи Бурнаш токымына насыйп булуы бер дә гаҗәп түгел анысы", — дип уйлады ул, горурланып.

Ниһаять, бисмилласын әйтеп, Ркаил эшкә кереште. Юлдашларын юкка-барга уятып борчыйсы килми иде аның. "Йокласыннар, — дип уйлады ул, — хәзинә ачу бик нәзакәтле, бик нәзберек эш, теләсә кемнең кулы да ятмый әле аңа".

Озак кына, сак кына маташа торгач, кулындагы тугры корыч каләме белән имән мичкәнең бер тактасын каезлап та өлгерде бу. Аннан, сулышын тыеп, тактаны каерып алды. Чыгып килүче кояшның самимисадә, саф нурлары кул сыярлык ара аша мичкәнең эчен яктыртты. Йә Ходa! Бар син, бер син, бердәнбер син! — Мичкә эченнән көмеш нур сирпелә иде!

Каһарманыбыз, дөп-дөп капкан йөрәген тынычландырырга теләп тирән сулу алды да, яза торган кулын мичкә эченә тыкты.

Икенче мизгелдә исә аның кулында бер уч тере тамчы... терекөмеш җемелди иде. Инде каһарманыбызга аты-юлы белән тәмләп, тозлап-борычлап сүгенүдән, һәм дә мичкәләргә шәплап бер тибүдән дә гайре чара калмаган иде. Нишлисең бит... Туктале, ашыкма! Икенче мичкә дә бар бит әле! Беренче мичкәдәге хәзинәнең, озак еллар ята торгач, терекөмешкә әверелүе дә ихтимал. Белмәссең... Тишек-тошыктан фенолы керә, тегесе-монысы. Химик реакцияләр казаны бит ул хәзерге Идел...

Каһарманыбыз түш кесәсеннән корыч каләмен алырга да өлгермәде, икенче мичкә (Йә Раббым!) үзе... телгә килде:

— Оркаил! Бүтән типмә! Мин бу, мин!

Монысын ук көтмәгән иде ул. Шулай да, көч-хәл белән:

— Кем син? — дип, телен тибрәтте.

— Заһид мин, Заһид!

— Нинди Заһид?

— Мәхмүди!

Боларны шушы урында калдырып, Ләбиб Лерон кырына килик әле.

Ул янә төш күреп ята иде. Дусты Газинур Морат аңа шигырь сөйли икән имеш:

Ярык тагаракта Идел кичеп

Яткан мәле әле халыкның...
...Аваз килә Идел төпләреннән:
Сез кичәргә тиеш Иделне!

— Бу шигырьгә мин пародия язарга тиеш! — дип уйлый икән дә Ләбиб, тәмәкегә дип кесәсенә тыгыл, имеш. Тик аннан бөгәрләнеп беткән буш "Идел" кабы гына килеп чыга. "Идел" тартып кына барыбер юньле әйбер язып булмый инде ул", — дип үз-үзен юата икән имеш. Кыскасы, Ләбиб тәмәке тартасы килеп уянды. Уянды-каранды да, Ркаилнең ниндидер тузган чәчле, сакалы биленә җиткән ялангач бер адәм белән гәпләшеп торуын күреп, тәмәке сорарга дип, алар тарафына атлады.

Хан хәзинәсен эзләү стажы Ркаилнекеннән зуррак булган Заһид, очына-очына, аңа нидер сөйләп маташа иде.

— ...Шуннан ни булды? — ди Ркаил.

— Булды да шылды! — ди Заһид, сакалын кашып. — Мин казып чыгарган бөтен хәзинәне вертолетка төяп, үземне имән мичкәгә тыгып авызын кадакладылар да, әллүр — вертолеттан Идел уртасына. Җитмәсә, терекөмеш мичкәсен дә беркеткәннәр, кабихләр. Берзаманны шапылдап килеп төштем суга, минсиңайтим. Суларга тишек калган дип сөенеп кенә тора идем — су керә башлады. Нишләргә? Тишеккә имән бармакны тыктым. Тыгуым булды — чуртан тешләп алды.

— Чуртанын каян күрдең? — ди Ркаил.

— Чуртан инде, чуртан! — ди Заһид, кызып. — Син нәрсә, Оркаил, мине җүләргә саныйсың мәллә? — мичкә әһленең йодрыклары йомарлана.

Болар сөйләшкән арада барысы да уянып беттеләр һәм берәм-берәм терекөмеш мичкәсе янына җыела башладылар.

— Менә сиңа мә!

— Бер мичкә терекөмеш!

— Тарала күрмәсен берүк!

— Илле килодан артык бу! — диештеләр алар.

— Иделгә ташлыйк! — диде Ркаил.

— Ташласак, Иделне генә түгел, бөтен Рәсәйне харап итәчәкбез — диде Әкә, пеләшен сыпырып. — Кая карама — татар бит...

— МЧС чакыртырга кирәк, — диде кемдер.

— Реклама өчен дә тиешле әҗерләрен биргәннәре юк әле. Аларга ышансаң... — диде Ләис, көрсенеп.

— Тагы нинди әҗер ул? Кемгә? — диде Рушания, кызыксынып.

Караб палубасында бер мичкә терекөмеш җәйрәп утыруга карамастан, "Идел"челәрнең кәефе шәп иде бүген. Кояшлы иртә! Иделдән салмак, рәхәт җил исә. Яхта алга ыргыла. Тамак тук, өс бөтен. Ни кирәк тагын?! Нигә сөенмәскә? Кичә булып узган вакыйгаларга ышанасы да килми иде хәтта...

Үзара шулай чөкердәшеп-сөенешеп йөзә торгач, төш туры җиткәне дә сизелми калды.

— Җәмәгать, Әчтерханга җитеп киләбез! — дип, берзаманны Әкә эшлекле генә сөрән салды. Һәммәсенең дә күз карашы алга төбәлде. Чыннан да, алда — әле шактый ук ераклыкта Кремльнең ак диварлары шәйләнә иде.

Хәзер инде сүзнең бары тик Әчтерхан турында гына булачагы беркемгә дә гаҗәп тоелмады.

— Бу якларда гектарыннан сигезәр тонна карбыз җыеп алалар, — диде Әкә, — елы әйбәт килсә, тугызны да!

— Каспий да Каспий, диләр. Әгәр дә безнең Идел булмаса, бу Каспий нишләр иде икән? — диде Гөлфия, пошынып.

— Заманында, әле бик тә борынгы заманнарда Каспий диңгезе дә, Кара диңгез дә булмаган — диде ерак тарихтан бай мәгълүматлы Солтан Шәмси. — Алар урынында Сармат диңгезе булган. Әнә шул борынгы диңгезнең бер калдыгы гына ди Каспий.

Роза Кожевникова никтер пошаманда иде.

— Странно...странно...— дип кабатлады ул. Әле уңга, әле сулга карап, туган ягының яшел җилкәнле утрауларын эзләде. — Доплыли Астраханьга, а дельты нет... Ах, как ты изменилась, Родина минем...

Ләис юк-бар сүзгә катышып тормады. Олы балыкка кармак хәстәрләү белән мәшгуль иде әле ул. Хатыны аңа бер ун-унбиш кило кара икра алып кайтырга кушкан иде. Барып җиткәч, әллә җае чыга, әллә юк, дип, Ләис бәхетен хәзер үк сынап карарга булды.

"Суалчан су өстенә чыкса — явымга, төпкә китсә — аязга", — диде дә, кармагына төкереп, суга ташлады.

Аның янына Резидә килеп басты.

— Их, китәргә иде хәзер кыргый утрауга! — диде Резидә, хыялга чумып.

— Күрәмсең, ул минем утрау икәнлегемне белми икән әле, белми... — дип эченнән генә офтанып куйды Ләис.

Кремль диварлары торган саен якыная бара иде. Ул гынамы?! Хәтта горур аен болытларга күтәргән Сөембикә манарасы да ерактан ук балкып күренә иде.

— Ну егетләр, ну егетләр, — дип, хозурланып сөрән салды Рашат капитан күперчегеннән. — Безне каршы алырга Әчтерхан югары дәрәҗәдә әзерләнгән!

— Мин армиядә хезмәт иткәндә, маршал киләсе булса, чирәм буяталар иде. Монда да шуның ише хәлгә охшаган. — Хәер, бу минутларда баш мөхәррир үзен маршалдан да ким хис итми иде.

— Күпме катыргы киткәндер бу манараны ясарга! — диде рәссам Диләрә Нәүрүзова.

Сүзне бервакытта да "әйе" дип башламаучы Ркаил:

— Юк! Катыргыдан булмас, — диде. — Хәзерге төзелешләрнең таштан салганы да ишелеп төшә. Аннан, ни пычагыма дип Әчтерханда Казан манарасы ясасыннар?! Кино-фәлән төшерсәләр генә инде.

— Академик Гомәр Саттар Мулилле әл Болгари әл Казани әл Буалыйда булган мантыйк җитми сезгә, — диде укымышлы Марат. — Йә, кайсыгыз белә, Сөембикә манарасының борынгы исеме нинди?

Ркаил авызларына су капкан сәфәрдәшләренә мәсхәрәле караш атты:

— Хан мәчете!

— Безгә шулай кыскарып килеп җиткән ул. — диде Марат, Ркаил абыйсының борынына чиртәчәгенә куанып. — Чынлыкта хан мәчете... Әчтерхан мәчете!

— Карагыз әле, карагыз! Колшәриф мәчете!

Чыннан да Казандагысына бик тә, бик тә охшаган иде бу мәчет. Ләкин тегесе әле төзелеп бетеп кенә

килсә, Әчтерханныкы очланган карандаш кебек манараларын зәңгәр күккә гүяки инде гасырлар буе терәп тора иде.

— Казан белән Әчтерхан — уртак язмышка дучар шәһәрләр, — дип сүз башлады Солтан Шәмси. — Шуңа күрә Әчтерханда Сөембикә манарасы, Колшәриф мәчете булу бер дә гаҗәп түгел. Эзотериклар Әчтерхандагы Колшәриф мәчетен XVI гасыр азагында ук төзелгән диләр. Тик аны күрү өчен өченче күз кирәк булган, чөнки урыслар җимермәсен өчен менталь үлчәмдә салган аны эзотерик бабаларыбыз. Менә хәзер татар иркенрәк сулыш ала башлагач менталь мәчет безнең үлчәмдә проявляться иткән.

Баш бухгалтер Альбертның абстракт фикерләүгә көйләнмәгән башы мәсьәләнең гамәли ягын әләктереп алды:

— Колшәриф мәчетен проектлау конкурсында җиңүчеләр никадәр акча-премия алдылар. Әчтерханнан чәлдергәннәр икән бит!

Кайсысыдыр, Резидә булды, ахрысы:

— Чиртә, чиртә, Ләис! — дип кинәт кычкырып җибәрде.

Ләис, кулларын угалап, караб койрыгына атлады. "Әләккән балык ычкынмый ул", — дип уйлады тәҗрибәле балыкчы.

Зур калага якынлашып килә иде инде. Күк йөзе самолетлар, вертолетлар, һава шарлары белән тулган. "Иделлия"нең борын төбеннән генә очып узган боралакка ниндидер зур язу эленгән иде. "Идел"челәр андагы: "Идел" журналына 10 яшь!" дигән язуны укырга тырышсалар да, укый алмадылар — кояшның алтын нурлары күзләрен чакты.

— Ну җегетләр, без килә дип бөтен Әчтерханга бәйрәм ясаганнар бит болар, ә! — диде әйтерсең лә күкнең җиденче катында гизгән Рашат.

— А какже?! — диде Роза, — минем якташлар бит. Аннары миңа да ике ай переговорлар алып барырга туры килде.

— Әйтәм аны, кайчан кермә телефонда утырасың, — диде Ләбиб.

Сәфәрдәшләр, бер тиң булып, күзләре белән Әчтерхан каласына йотылдылар.

— Таныш урыннар байтак икән, — диде Ркаил, — югыйсә Әчтерханда бер мәртәбә дә булган юк иде әле.

Бу вакытта исә Ләис томырып аска төшеп киткән калкавычны күтәрергә тырыша иде. Әнә, була-була, һоп! Кармак сабы сыгылса сыгылды, әмма сынмады — саллы гына балыкны палубага күтәреп салды. Тик менә... Тик менә балык дигәне генә... Тишелеп, тетелеп беткән, тешсез авызын ачкан мескен кроссовка иде.

— Бәтәч, бу минеке бит! — диде, кай арада килеп җиткән Ләбиб. — Нәкъ үзе — кырык өченче размер! Узган ел Казансу буенда кәефләнеп утырганда аяктан төшеп калган иде. Менә сиңа мә!

Ләис тирә-ягына каранды. Шөкер, Ләбибтән, һәм дә моңсу гына елмаеп торучы Резидәдән гайре шаһитләр юк иде.

"Иделлия-Казан" яхтасы причалга сөялү белән капитан күперчегендә гасабиланып әрле-бирле йөргән Бурсык ярга сикерде. Маңгаена "Казан елга порты" дип язылган бинаның таныш нигезен иснәде дә койрыгын югары чөйде. Зөя елгасы сыман борганланып агучы бәвеле белән яхтаның ничек Казанга урап кайтуын аңлатмакчы иде бугай лоцман мачы...

— Эзотерик-мезотерик, дип миннән көлгән булалар әле тагы, — дип, мыек астыннан гына елмаеп куйды Солтан Шәмси. — Башта түгел, азактан көлү хәерле, җәмәгать!

Кремль сәгате 30 нчы августның көндезге дүртен сугып маташа иде.

Йомгаклау сүзе

Хөрмәтле укучыларбыз!

Шәт, аңлагансыздыр: без, "Идел"челәр, Идел елгасы буйлап хыялый сәяхәт кылырга уйлаган идек. Ничек, ни рәвешле килеп чыккандыр, монысын инде үзегез хөкем итәрсез. Тик онытмагыз, биредә фантазия белән чынбарлык бергә кушылган. Дүрт авторның кумәкләшеп тулаем бер әсәр язуы — монысы да үзенә күрә яңалык, яңалык ачарга тырышу.

Кыйссаның исемен "Әчтерхан чикләвеге" дип атадык. Күрмәдек, ә әчтерхан чикләвеге кайда соң, дигән сорау туарга мөмкин. Мондый сорауга без болай дип җавап бирә алабыз. Балачакны хәтерләсәк, төрле бәйрәмнәрдә яисә сабан туе көнне әниләр, апалар безнең кесәләргә, бәйрәм күчтәнәче итеп, әчтерхан чикләвеге салалар иде. Конфет-мазар ише "хәзинә"ләр янында шуңардан да кызыклысы, серлесе булмый торган иде! Йомры кабыгында гына да никадәрле сырлар уелып ята. Ә инде ватып, эчен ачып карасаң, андагы сырлар-уемнарның санына чыгарлык түгел. Менә шундый хикмәтле чикләвек.

Уйлаштык-уйлаштык та, "Идел" журналына 10 яшь тулган көннәрдә, укучыларыбызны әнә шундый күчтәнәч — "Әчтерхан чикләвеге" белән сыйларга булдык. Сыйның гаебе юк, диләр халыкта. Шулай итеп, бигайбә, дуслар!





Заһид МӘҺМҮДИ

Дүртьюллыкка сыйдырылган яисә билгеле бер рифма-ритмга гына буйсындырылган шигырь минем өчен читлектәге кош кебек. Фикер шул читлектән очып чыга алмый, аның чын ирке, чын рухы кысыла. Шуңа да мин шигырьләремне кәгазьнең буеннан-буена язам, фикерләрем рифма-ритмга түгел, киресенчә — рифма-ритмнар минем фикергә буйсына.

Дәһидиләр

Соңгы сүз

Туктап алды беркөн йөрәк. Соңгы сүзем булыр ниндиерәк? Ничек, ничек? Юк, бусы артык гади, бусы томанлырак. Шул, шул, соңгы сүзне әйтүе һәрчакны катлаулырак.

Их, син, йөрәк, ашыгасың бигрәк! Килгән юлым томанлы, кыйблам кая югалды? Узганнарым бик ерак, китәр юлым моңсурак: яшәүдән соң яшәүгә ышану кыенрак. Соңгы сүзне әйтүе һәрчакны катлаулырак.

Соңгы сүзем булыр нинди?.. Фикерем томанлырак... Әй, йөрәк, син тукта инде, синең сүзең саллырак.

Дөнья

Аһ, нигә караңгы, нигә пычрак соң бу дөнья? Шулай булгач, нигә җирдә чишмәләр ага, нигә кояш чыга?! Шулай булгач, нигә кирәк былбыл җыры?! Шулай булгач, нигә кирәк бишек моңы?! Барыбер караңгылык баса барсын да, барыбер пычрак суда бата барсы да.

Аһ, нигә караңгы, нигә пычрак соң бу дөнья! Нигә диңгез шаулый, кая чакыра? Күлләвеккә тама сабый яше, күлләвектә яшен батыра.

Каләмдәшкә

Акча бирмиләр имеш. И әнем, син бит юләр! Сөенеп яшә, әле ярый һаваны банкларда бирмиләр. Әле ярый кояшны Мәскәүдән китермиләр. Әле ярый аякка да салым салмый хакимнәр. Әле ярый хатыннарны банкларда бирмиләр.

Сүтелә тарих

Кабан артында мәзин кычкыра азанын. Сүтелә йортлар, сүтелә тарих. Алгы тешләрен коялар Казанның.

Яшим инде мин дә

Яшим инде мин дә. Зәңгәр төтен белән тулган бүлмә... Кара диңгез күрмәгән малай дөнья турында сүз йөртә. Әйтерсең каләмем Пентагонга акыл кертә. Әйтерсең каләмем әхлак иңдерә Җиргә. Әйтерсең сугышлар анда бетә. Әйтерсең каләмемне татар абзые көтә. Аның үз эше, ул мал асрый, йорт сала, көтү көтә. Әйтерсең каләм белән Казан суы чистара. Әйтерсең милләт агара.

Яшим инде мин дә... Зәңгәр төтен белән тулган бүлмә. Минзәләдә булмаган малай сәнгать турында сүз йөртә. Әйтерсең каләмем аңа зур яңалык кертә. Әйтерсең лә аны "Нью Йорк таймс"лар көтә. Маршруты — Казан-Балтач. шуның белән сәфәр бетә.

Синең өчен шигырь

Кызыкма син алтын-көмешләргә, кызыкма син ул бай бәндәләргә. Җир астында ята күп хәзинә, адәм гомере була тик бер генә. Бездән соң да булыр якут ташлар, бездән соң да туар явыз затлар: алтын өчен кеше үтерелер, намус утын шулай сүндерерләр. Кызыкма син алтын-көмешләргә, кызыкма син ул бай бәндәләргә. Аяк асты тулы гел хәзинә, аңа хуҗа Шайтан үзе генә. Бездән соң да алтын чыгарырлар, һәм комсызлар юкка куанырлар: бу шигырем кыйммәт көмешләрдән, көлеп яшим мәнсез бәндәләрдән. Сөям сине, җаным, чын күңелдән! Син баш тарта күрмә шигырьдән! Бу газәлем синең өчен генә, ул да синең кебек берәү генә. Сәгать сугар, сулыр әле йөзләр, күккә багар безнең моңсу күзләр. Хисләр мәңге, мәңгелек шигырь! Балчык йотмас аны, үлмәс мондый фигыль! Гөлләр үстер, бу да матур шөгыль. Һәм бер көнне ерак оныкларың әйтер: "Бу — саф алтын, бу — чын шигырь!"

"Идел" журналы мөхәррирләренең һәммәсе дә, Язучылар берлеге әгъзалары гына түгел, гамәли хезмәткәрләр дә, хәтта җыештыручы Мәйсәрә апа да бездә шигырь яза яки язган. Әгәр аларның иҗат җимешләрен дә куймасак, түгәрәк бәйрәм табыны китек булып тоелыр иде.
Аннан соң, безнең элеккеге баш мөхәрриребезнең "Яшьлегендә шигырь язмаган кешене табибка күрсәтергә кирәк" дигән сүзе бар иде. Беребезнең дә табибка күренәсе килми...

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

Томан балыгы

Күзләрем кара түгел,
Күзалларым кара.
Акылым да ак түгел,
Томаланып бара.

Күзләрем кара ни дә,
Ак, кызыл, сары ни.
Әйләнгән дә шәйләнгән
Дөньяга барыбер.

Акылымның аклыгы ни,
Томаналыгы ни —
төпкә төшә алмаган
Томан балыгы мин.

1996 ел

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Түркләр

Да, скифы мы...
Блок.

"Түркләр без!" —
Кысан бу дөньяга
Тудырган да безне Ашина,
Җилдергәнбез җитез толпарларда
Җилләр, зилзиләләр каршына.

Түркләр без! —
Күзебез дә хәтта
Ук төзәргә диеп уелган.
Офыкларда югалабыз, чыгып
Тормыш дигән затсыз уеннан.

Түркләр без! —
Дөм караңгы төндә
Дала бүресенең юлдашы.
Таш диварлар кыса хәзер җанны,
Ерагая Күлтәгин ташы.

Түркләр без! —
Хәтер корбаннары:
Күзне йомып тып-тын тор гына,
Йөз меңнәрчә кылыч күтәрелә,
Һәм төмәннәр яуга ыргыла.

Түркләр без! —
Аларның да әле
Иң чыдамы икән ләбаса! —
Татар атын авыр аркан белән
Өстерибез гасырлар аша.

Түркләр без! —
Кеше арбасында...
Кулдан төште күптән дилбегә.
Сиздермичә әрнеп күз ташлыйбыз
Дөнья дигән атның биленә.

Түркләр без! —
Урман җәяүлесе
Адымнарын тыеп атласын! —
Арган җайдак камчы сабы белән
Кага яңа гасыр капкасын.

Роза КОЖЕВНИКОВА

Дога

"Бисмилла иррахман иррахим..."
Тоепмы ниндидер көч барын,
Әйтәләр шул сихри тәкъбирне
Йокыга талганда кичләрен.

Шып-шыксыз, кап-кара төннәрдә
Сырхаулап ятканда өйдә мин,
Әнием тибрәтте бишекне:
"Бисмилла иррахман иррахим..."

Хәтерли борынгы заманнар:
Килгәндә куаныч, йә кайгы,
Айга шул сүзләрне пышылдап,
ничәмә иреннәр ялварды...

Кайвакыт, ышанып йөрсәң дә,
Юк диеп гайре көч, илаһи —
Үзең дә сизмәстән әйтәсең:
"Бисмилла иррахман иррахим..."

Ләбиб ЛЕРОН тәрҗемәсе

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА

Сагыну

Офыкларга җәелеп кояш елый,
Үтә тагын көннең гомере.
Әйтерсең лә дөнья янып бара.
Калыр бары утлы күмере.

Тупылларның моңсу ботагында
Сискәнешә көзге яфраклар.
Үткән елның бөресеннән иде,
Тик бу язга никтер ятраклар.

Башка кичләр төсле кич бит инде,
Төн киләсе таулар ягыннан.
Сагышларым эчкә йота-йота,
Бүген сине шундый сагынам.

Ахыры 74 нче биттә

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА

Югалту

Хикәя

Н. Граханцева рәсеме

— Син гаепле, барысына да син гаепле, эт баласы! Бет, дөмек!

Бала елый, ярсый-ярсый елый. Ә хатынның йөзендә җиңү тантанасы, үч алу ләззәте. Барысы да ул уйлаганча, уңышлы килеп чыкты. Бу эштә аңа гүя Ходай үзе ярдәм итте: баланы арбасыннан алган чакта урамда бер җан иясе дә юк иде, урлаучыны беркем күрмәде. Ә бала йоклый иде, аның "ых" иткән тавышы да ишетелмәде. Юка одеялга төрелгән сабыйны куенына кысып, хатын машина эченә чумды. Хәзер әнә аяклары белән тибенә-тибенә акырып ята бала, әйдә, акырсын — беркем дә ишетми аны. Үзе матур, кабахәт, атасына охшаган. Әй чабышалардыр инде хәзер, теге нәзберегә һушсыз ятадыр. Аларның да йөрәге янсын әле бер, аңа гына өзгәләнергә димәгән...

* * *

— Аерым билгеләре бар идеме?

Каршында утыручыларга милиция лейтенанты шундый сорау бирде. Тик яшь хатын җавап тотарлык хәлдә түгел, елый-елый күзләре шешенеп беткән, хәзер дә үксеп утыра. Куллары калтырый. Хәсрәте йөзенә чыкса да, ире үзен кулга алырга, уй-фикер сәләтен югалтмаска тырыша. Тик, бик теләсә дә, лейтенантның соравына җавап бирә алмый. Чөнки хәтерләми: бар идеме соң баланың аерым билгеләре? Ир сораулы карашын хатынына төбәгән.

Ә милиционер һаман төпченә:

— Өч айлык баланы, мәсәлән, нинди билгеләре буенча табып була? Без аны ничек итеп танырга тиеш? Миңа, мәсәлән, алар барысы да бертөсле кебек. Аерым билгесе, мәсәлән, миңе булса..

"Юк, аны башка балалар белән бутау мөмкин түгел! Ул җир йөзендә иң матур бала. Ул — бердәнбер! Аның күзләре кыңгырау чәчәк, иреннәре пешкән каен җиләге, тәне ак каймак. Тагы нинди аерым билге кирәк? Бер колаклы, алты бармаклы яки кылый күзле — шулармы аерым билге?" Хатын күңенә мең тапкыр кочагына алып иркәләгән-назлаган сабыеның әгъзаларын гына түгел, борын тишекләренә кадәр күз алдына китерде. Аның улы сау-сәламәт, бар җире бөтен, камил, бернинди аерым билге дә, миң дә юк иде аның бәрхет кебек тәнендә. Хатынның йөрәге генә түгел, сөт тулган күкрәкләре дә сызлап куйды. "Аһ, улым, син ачтыр, имәсең киләдер... Кайларда, кем кулларында интегәсең икән?!" Хатын тагын сулкылдап елап җибәрде.

Кабартма битле, сирәк тешле тикшерүче, гәрчә милициядә беренче елын гына эшләмәсә дә, гомерендә бер тапкыр да мондый җинаять белән очрашмаган, шуңа бераз аптырап калган иде.

Колхоз фермаларыннан сарык-бозау да югалган очраклар булды, ялгыз карчыкларның су буенда йөрүче казлары да юкка чыккалады... Урланган каз, бозаулар исән килеш кире кайтмаса да, каракларны, шул кош-мал белән сыйланучыларны тота алдылар бит! Ә монда адәм баласы югалган... Адашкандыр, теген-дәдер-мондадыр дия торган түгел, сабый әле төпи дә басмаган. Әнкәсе хатын-кызлар консультациясенә кереп чыккан арада урамда калган арбадан алып киткәннәр. Нәрсәдән, кайдан башларга эзләүне? Ичмасам, ник бер шаһит булсын! Һәр имчәк баласын тикшереп йөрмәссең бит. Әле аерым билгеләре дә юк икән. Тикшерүче икеләнеп кенә, уңай җавапка бик өметләнмичә генә сорап куйды:

— Бәлки фоторәсеме бардыр?

Шөкер, бар икән. Япуннарга рәхмәт: ялкаулар фотоаппараты белән тутырдылар дөньяны, укый-яза белмәгән диваналар да ялт иттереп ясап бирә ала хәзер фотосурәтеңне.

— Анысы яхшы, — диде лейтенант. — Рәсемен күбәйтергә кирәк, кеше күп йөри торган урыннарга белдерү язып эләрбез. Телевидение-радиога, газеталарга тизрәк хәбәр бирергә кирәк. Телефоныгыз бармы?

— Бар.

— Кемдер, мәсәлән, гел телефон янында булырга тиеш. Акча сорап шылтыратулары да мөмкин. Шундый юл белән, мәсәлән, акча эшләү модага кереп бара.

— Шулай гына булсачы...

Чын хәсрәт белән очрашканда дөнья байлыгы чүпкә әйләнә шул. Уллары гына исән булсын, акчаны җир тишегеннән дә табарга әзер алар.

Ә лейтенантның башы эшли икән, кечкенә күзләрен кабартма яңакларына батырып, тагы бер фикер әйтеп куйды:

— Аннары, мәсәлән, сезгә үчле кешеләр юкмы?

Иңендә канатлары да булса фәрештәгә әйләнәсе бу хатын балаларча беркатлы иде: "И Ходаем, безнең нинди дошманыбыз булсын, кемгә начарлыгыбыз тигән?"

Тик аның янәшәсендә утырган ир алай уйламады. Күз алдына чегән кызы кебек кара бөдрә чәчле, тулы иренле, дәртле серле карашы белән үзенә тартып китереп, теләсә кайсы ир-атны буйсындыра алучы чибәр Илгизә килеп басты, колагында аның пышылдап әйткән сүзләре яңгырады: "Ә мин сезне барыбер яшәтмим!"

Лейтенант дөрес әйтә. Шулай булуы мөмкин, бик мөмкин. Тик бу турыда Фәндәс кенә белергә тиеш, әлегә үзе генә...

* * *

Илгизә өйдә иде.

— О-о! Какие люди! И без охраны! — дип кыланып-чытлыкланып каршы алды ул Фәндәсне.

Аларның нәкъ алты ай очрашканнары юк иде. Соңгы тапкыр малае тугач килде монда Фәндәс. Хушлашырга дип килде.

— Әти булдым, Илгизә, — диде. — Ике ярда бәргәләнеп йөреп булмас...

Ә Илгизә елмайды. Әле ничек елмайды! Сөяркәсеннән көлү, аның ирлеген мыскыллау чагыла иде бу зәһәр елмаюда. Ирне таптап-сытып юк итү теләге чагыла иде. Хатын елан кебек Фәндәснең муенына сарылды, кайнар иреннәре белән муенын, яңакларын яндырып үтте дә, колагына әкрен генә пышылдады:

— Ә мин сезне барыбер яшәтмим...

Бу юлы да елмая:

— Дөньяда безнең барлыкны да искә төшерденмени, җанкисәккәем? Әйдә үт, күңелебез киң, гафу итә беләбез. Хәләл җефетең ана каз кебек бәбкәсе янында бөтереләдер. Сиңа сан да юктыр, ә, бәгыркәем? Юмарт Илгизә апаң исеңә төштеме?

Артын юри боргалый-боргалый, иңнәрен уйнатып, хатын залга үтте. Фәндәс тә аңа иярде. Илгизә бер бүлмәле фатирда яшәп ята. Әмма шул кечкенә, җыйнак бүлмә Фәндәс өчен оҗмах иде. Әле һаман балалыктан чыгып бетмәгән, ир белән йоклауны оят эш дип белгән, ә аннары, авырга узгач, мең сәбәп табып ирен янына китермәгән Энҗесеннән күрмәгән ләззәт-назларны шунда татыды ул. Ике ялкын бергә кушылып шунда дөрләде...

Илгизә, халат итәген ачып, аягын-аякка куеп, ишек төбендәге софага урнашты. Ике кулы белән зур чәчәкле йомшак одеял җәелгән ятакка таянды. Халат изүе ачылып китеп, ирләр карашын йота торган мул ак күкрәкләре күренде. Хатынның зур чем-кара күзләре хәйләкәр елмаеп ирне күзәтә. Әмма Фәндәс аңа карамый, ул карашы белән бүлмәне айкап чыкты да, кием шкафларын ачып карады. Эре-эре адымнар белән кухняга үтте, бәдрәф-ванна бүлмәләренә күз салды.

— Кемне эзлисең, җанашым? Әллә көнчелегең уяндымы? Эзләмә, беркемем дә юк. Шәм күргән саен эреп төшүче түгел мин. Кил әле яныма, сагындым бит үзеңне.

Чакыруын кабул итмичә, Фәндәснең һаман бүлмә уртасында басып торуын күргәч, үзе аның янына килде. Халат бавын ычкындырып, ялангач тәне белән иргә сыенды, дәртләнеп-шашып кочарга-үбәргә тотынды. Хатынның кайнар сулышы тәнеңне түгел, бәгыреңне көйдереп, көл итәрлек иде. Ләкин Фәндәс аны читкә этәргә көч тапты.

— Кая, берәр нәрсә бир әле эчәргә. Йөрәк яна ату.

Илгизә китергән күбекләнеп торган салкын сыраны бер кабуда йотып куйгач, хушлашып та тормыйча, ашыгып чыгып китте.

* * *

Илгизә аның эшенә иртүк шылтыратты. Дулкынлануы тавышыннан ук сизелә иде.

— Фәндәс, кадерлем... Гафу ит... Мин бит белмәдем. Кичә телевизордан әйттеләр... Егылып китә яздым... Ужас! Что творится! Алло! Фәндәс... Хәлеңне аңлыйм, кайгыңны уртаклашам.

— Рәхмәт, — диде ир, хатынның эмоцияләр тулы сөйләмен сабыр гына тыңлап бетергәч.

— Фәндәс, алтыным, яңалыклар юкмы соң?

— Нинди яңалык?

— Бала хакында дим... Берәр хәбәр юкмы?

— Юк шул әлегә... — Фәндәс, бәгырен телеп торган авыр хәсрәтеннән берьюлы бушанырга теләгәндәй, авыр сулап куйды.

— Син кичә килдең... Шундый ачулы идең... Әллә миннән шикләнәсеңме, җан канатым?

Яшереп торудан мәгънә юк, Илгизә — кешене үтәли күрә торган сихерче белән бер.

— Булды инде. Тәмам баш катты бит. Ни уйларга да аптыраган.

— Аптырарга түгел, эзләргә кирәк. Ни йөрәк белән эшеңдә утырасың? Неужели шундый чакта эш турында уйлый аласың?

— Нишлим соң?! Киңәш бир.

Телефонда тынлык урнашты. Бераздан Илгизә телгә килде:

— Мин кайдадыр укыган идем: хәер теләнчеләр урлый икән балаларны. Именно имчәк балаларын. Ник икәнен беләсең инде, кешеләр күбрәк кызгансын өчен. Базар, вокзал тирәләреннән эзләп карамадыгызмы? Хәер сорашучылар арасыннан?

— Анысы милиция эше инде. Үзләре беләдер әле каян эзләргә икәнен.

— Абау, бәгърем, йөрәгең таштыр синең! Кулыңа китереп тоттырганнарын авыз күтәреп көтеп утырасыңмы инде?! Ну и папаша! Мәче баласы турында сөйләшәбезмени!?

Илгизәнең чынлап ачуы килде бугай, ул телефон трубкасын куйды. Элемтә өзелде. Әмма аның соңгы сүзләре Фәндәснең күңелен актарып ташлаган иде инде. Башындагы авыр уйларын сытып юк итәргә теләгәндәй, чигәләрен уды. Кеше арасында бераз онытылырмын, җиңелрәк булмасмы дип килгән иде, кая ул! Миенә кадалган без-сораулар үзе белән ияреп йөри ич. Өенә кайтса — анда хатынының куркудан агарынган йөзе дә, хәсрәт оялаган нурсыз күзләре. Ике көн эчендә шәүләгә әйләнде тәмам. Әллә Илгизә янына барыргамы? Чынлап та! Шул хатынның кайнар кочагына кереп, бер онытылыр иде ичмасам. Илгизә юата белә, күпне күргән хатын ул. Дөньяга аек күз белән карый, үзенә ни кирәген яхшы белә. Әгәр моннан өч ел элек Фәндәскә, үзеңнән ун яшькә олы хатынның сөяркәсе буласың, дисәләр, ул кычкырып көләр генә иде. Җиләк кебек яшь-яшь кызлар янында бөтерелеп торганда, карчыкларга ни йомышы төшсен? Әле ничек кенә килеп капты Илгизәнең кармагына. Үзе теләп, башын-күзен тондырып капланды хатынга. Яшь аермасы турында ярты еллап вакыт үткәч кенә белде, әмма моңа бер дә исе китмәде — татлы әйбер бозылмый икән ул! Ә Илгизә акыллы хатын булып чыкты. Аның киңәшләре, кирәкле кешеләр белән дуслыгы, элемтәләре Фәндәскә ярап куйды: астагыларга да, өстәдәгеләргә дә ярарга тырышып ике кирпеч арасында кысылып йөрүче бригадирдан төзелеш трестының бүлек башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелә алды. Илгизә — Фәндәс өчен берьюлы әни дә, укытучы да, сөяркә дә, дус та булды. Үз проблемаларын башкалар өстенә өймичә, бер кайгысыз кеше кебек гел көлеп-шаркылдап йөрүче бу хатын янында рәхәт, җиңел иде аңа.

Фәндәс кунакханә номерын җыйды:

— Матурым, әйдә, ачуланышмыйк әле. Син бит акыллы хатын, аңлыйсың.

— Аңлыйм, аңлыйм, — диде Илгизә, берни булмагандай. — Фәндәс, мин сиңа шуны әйтергә онытканмын: әгәр минем ярдәм кирәк булса — пажалысты, любой вакытта. Бала өчен акча сорасалар дим. Мужыт шуның өчен урлаганнардыр. Боевиклар карыйкарый бала-чага да бандит булып бетте бит хәзер. Алла... Җанкисәгем, ник эндәшмисең?

— Ишетәм. Рәхмәт. Илгизә... карлыгачым... Син мине кабул итә аласыңмы?

— Кайчан?

— Менә хәзер. Минем синең яныңда буласым килә.

Телефон трубкасында Илгизәнең шаркылдап көлүе ишетелде.

— Шулаймыни? С какой стати?

— Юат мине, Илгизә...

* * *

...Бала исән иде. Аңа берни дә булмаган, мышный-мышный йоклап ята. Ирен-борын тирәләре маңкалап-юешләнеп беткән, асты буялган. Янына килмәле түгел: сидек-бук исе... Бала исән, бүреләр дә тимәгән үзенә, кыргый этләр дә ботарлап ташламаган, елан да чакмаган... Могҗиза, әмма факт: куе урманның аулак бер почмагында, каен төбендә берьялгызы төн чыккан бала исән! Тик бу хәл хатынны аз гына да сөендерми, чөнки авыр, кара эшне үзенә башкарырга туры киләчәк, димәк, гомере буе кылган сансыз-исәпсез гөнаһларына тагы бер яман эш өстәләчәк.

Хатын машинасыннан пластмасс шешәгә тутырылган су алып килде. Учак сүндергән сыман, илтифатсыз хәрәкәтләр белән бала өстенә су койды. Аңа баланың уянуы, елавы кирәк иде. Шул тавыш аны ярсыта, нәфрәтен көчәйтә, ачуын кузгата. Теләгенә иреште: бала уянды. Тик ул акырмый, шыңшый гына, тавышы бик зәгыйфь чыга. "Тизрәк эшне бетерергә, котылырга кирәк бу җәфадан", — дип уйлады хатын. Көрәген җиргә батырды. Мондый кечкенә каберләрне беренче тапкыр казуы түгел. Егетләр кочагында назлануның башы рәхәт булса да, ахыры михнәт икәнен унбиш яшендә үк аңлаган иде. Үзенең байтак гөнаһын, якты дөньяга килеп, аваз салырга да өлгермәгән сабыйларын, кача-поса җир куенына яшерде ул. Аталары кем икәнен үзе дә белми иде, шуңамыдыр, берсен дә кызганмады. Хәер, аны да кызганучы булмаган, дөньяга китергән анасы чүп савытына чыгарып ташлаган үзен... Тере килеш. Шунда үләсе генә дә бит. Юк, бер яхшысы табылган, коткарган. "Изге гамәл кылдым, саваплы булдым", — дип үзенчә сөенеп тә йөргәндер әле. Ә чүплектән табылган бала үзенең коткаручысын гомер буе каргап яшәгәнен башына да китермәгәндер...

Казу эшен бетергәч, хатын шыңшып ятучы баланы үзе белән алып килгән иске ертык җәймәгә төрде дә, җиңел, кечкенә, әле тормыш уты сүнмәгән җылы гәүдәне сай кабергә төшерде...

* * *

Юкка гына гаепли аны Илгизә. Фәндәс таш бәгырьле түгел. Өенә кайтканчы, ул башта милициягә кагылды. Лейтенант үз урынында түгел иде. Башка егетләрдән белеште: әлегә өметле хәбәр юк. Илгизәсенең киңәшен тотып, Фәндәс базарга сугылды. Бала кочаклап, хәер теләнеп утыручы хатыннарны күзәтте. Үзләре дә, балалары да шоколад төсендә. Хәерче булсалар да, җүләр түгел бит алар, көпәкөндез урланган бала тотып утырмаслар. Аннары, монда калдырмаслар да иде баланы, читкә, ераккарак озату җаен карарлар иде. Улын болар арасыннан эзләп йөрү мәгънәсез эш, вакытны бушка уздыру гына.

Бәлки берәр хәбәр бардыр, дип, Фәндәс өенә ашыкты. Ишекне ачып керүгә, хатыны аның каршысына атылып чыкты.

— Фәндәс! Улыбыз исән! Исән!

— Кайда ул?

— Кайда икәнен белмим, әмма ул исән!

— Туктале, син башта тынычлан. Аңлатып сөйлә.

— Мин сине эзләдем. Тик син эшеңдә юк идең. Телефоннан шылтыратып әйттеләр.

— Кем әйтте? Милициядәнме?

— Юк. Баланы урлаучы әйтте.

— Хатын-кызмы, ир-атмы?

Энҗе аптырап калды, нәзек кашларын җыерып, нидер исенә төшерергә азапланды. Йөзендә уйлар өере, гаҗизлек чагыла иде. Ул гаепле бала кебек башын чайкады:

— Белмим... Аермадым.

— И-и, җебегән!

Әле генә анасының канат астына сыенган каз бәбкәседәй, Илгизә янында юаныч табып, бераз тынычланып кайткан ирнең, елау-сыктаудан башка бернине белмәгән артык көчсез, кыюсыз хатынына никтер ачуы килде. Аның урынында Илгизә булсамы! Ире кайтуын кул кушырып көтеп утырмас, әллә кайчан берәр чарасын күрер иде!

Әмма юкка гына кызды Фәндәс. Энҗенең бер гаебе дә юк иде.

Аңа бер сәгать элек шылтыраттылар.

Телефон шылтыраган саен Энҗе сискәнеп куя. Бер тәндә, бер җанда берьюлы өмет һәм курку кушыла: нинди хәбәр алып килер телефон чыбыклары?

Калтыранган куллары белән телефон трубкасын алып, әкрен генә дәште:

— Ал-ло...

Хатын-кызныкына да, ир-атныкына да охшаган карлыккан тупас тавыш:

— Балагыз кирәкме? — дип сорады.

Энҗе, элемтә өзелүдән куркып, ашыга-ашыга җавап бирде:

— Әйе, әйе! Кайда ул? Исәнме?

— Исән булмаса, шылтыратмас идем.

— Зинһар өчен, кайтарыгыз улымны! Ни телисез, шуны бирергә риза. Баламны гына кайтарыгыз! — Энҗе елый иде.

— Мышкылдама! Ату телефонны куям.

— Юк-юк. Зинһар, куймагыз, югалмагыз!

— Алайса тыңла. Карчыга урманын беләсеңме? Унбишенче километрда? Шунда бер плакат бар. "Берегите лес от пожара" дигән. Бүген кичке тугызда ирең шунда килсен. Үзе генә. Кәҗәләрсез.

Энҗе билгесез затның һәр сүзен хәтеренә сеңдереп барырга тырышты. Кул астында гына ручка-кәгазь юк иде. Соңгы сүзне аңламады: "Нинди кәҗәләр тагы? Аларның ни катнашы бар?" Әмма кайтарып сорамады, бәлки ире аңлар. Телефондагы тавыш югалды, "пип-пип" дигән өзлексез аваз гүя Энҗене үрти иде. Хатын иренең эш номерын җыйды, әмма шул ук эчпошыргыч авазны гына ишетте...

* * *

Төгәл өч көрәк туфрак ыргытырга өлгерде хатын. Якында гына ишетелгән эт өргән тавыш аны сискәнергә, сагаерга мәҗбүр итте... Ул да булмады, куе булып үскән абагалар арасыннан кап-кара эт килеп чыкты. Сарык бәтие кебек бөдрә йонлы һәм, бозау хәтле булмаса да, шактый зур иде ул. Күзләре учактагы күмер булып ялтырый, зур итеп ачылган авызында үткен ак тешләре тезелеп тора. Ул өрә-өрә хатын өстенә килде. Эттән бигрәк, "моның хуҗасы да булуы мөмкин бит" дигән уй куркытты хатынны, кулындагы көрәге белән селтәнә-селтәнә, ул машинасына таба чигенде. Бер аягы ниндидер түмгәккә килеп бәрелде дә, хатын, тигезлеген саклый алмыйча, арты белән җиргә килеп төште. Котылуга тамчы да өмет калмаган, ярсыган эт менә-менә аның өстенә сикерәсе иде. Хатынны якында гына ишетелгән тавыш коткарды:

— Граф, ко мне!

Бер хатынга, бер тавыш килгән якка карап икеләнеп торды эт. Икенче тапкыр яңгыраган боерыкка буйсынды.

— Граф! — дип бу юлы усалрак, кырысрак дәштеләр. Эт, дошманына ачулы караш ташлап, тешләрен ыржайтты да, телен салындырып тавыш килгән якка сыпыртты. Хатын яшен тизлеге белән сикереп торып, машинасына таба йөгерде. Егылган чакта кулыннан ычкынып киткән көрәкне эзләп торырга вакыты юк иде аның.

* * *

Бу — аулак урын. Тар басма булып сузылган асфальт юлның ике ягында да урман. Монда хәрәкәт аз. Аксу авылына илтүче әлеге юл төп трассадан читтә үтә. Менә ярты сәгать ике таякка беркетелгән, "Урманны янгыннан саклагыз!" дигән сүзләр язылган калай янында тора инде Фәндәс, бер сөт машинасы белән арбалы мотоциклдан башка үтүче күренмәде.

Ә киче соң, киче нинди! Кайгының кара мәчеләре эчеңне тырнамаса, урман буенда саф һава сулап, хозурланып кына йөрисе. Гүя ниндидер зур картина, рәсем карап утыра Фәндәс: тирә-як илаһи тынлыкка чумган, хәтта яфраклар да селкенми. Дөньяда бернинди кайгы, бернинди гамь юк кебек. Ир, монда ни өчен килгәнен исенә төшереп, авыр сулап куйды,

тынычсызланып сәгатенә күз төшерде. Билгесезлек җанын кимерә иде. Ир арган башын руль өстендә ятучы кулларына салды. Кайчан бетәр бу мәхшәр?! Сабый гомере белән уйнаучыларны дөньяда яшәтмәс иде Фәндәс. Тик кайда соң алар? Нигә күренмиләр? Аның уйларын ишеткәндәй, якында гына машина кычкыртты. Ир башта күзгегә күз салды, шундук кәефе кырылды. Чөнки яшел төстәге "Жигули" да, аның хуҗасы да аңа бик таныш иде. Кәяз, төз басып аның каршына килүче ак чалбарлы, кара күзлекле хатын башка беркем дә түгел, ә Илгизә иде. Фәндәс урыныннан кузгалмады.

— Нишләп утырасың монда, бәгырькәем? — дип сорады хатын, машина ишеген ачып. Килешле җиңел хәрәкәтләр белән Фәндәс янына кереп утырды.

— Шул ук сорауны мин сиңа да бирә алам, — диде ир.

— Сине озаткач, өйгә кайткан идем — ишектә записка тора. Авылдашым Зилә калдырган. Әниең кайтырга кушты, аш үткәрә, дигән. Кибеттән тегесен-монысын алдым да, кайтырга чыктым. Күрәм: синең машина тора. Аптырап киттем. Әллә, мәйтәм, берәр нәрсә булдымы? Төнгә каршы бер дә юкка монда тормыйсыңдыр.

— Тынычлык бетте, Илгизә. Төн дә юк, көн дә юк хәзер... — Фәндәс ни булганын сөйләп бирде.

— Күпме сорадылар соң?

— Нәрсәне?

— Акча, дим. Выкуп күпме сорадылар?

Шунда гына Фәндәснең башына барып җитте: Энҗе аңа акча турында берни дә әйтмәде бит! Әллә онытканмы? Ул чагында монда утырудан ни мәгънә? Фәндәснең сытык чыраен күрер өчен генә чакырмаганнардыр бит бандитлар.

Ә Илгизә юатырга ашыкты:

— Тукта, борчылма әле син. Минемчә алар ялгышканнар. Хәтерлисеңме, мин сиңа сөйләгән идем. Күршедәге Разиянең малаен, мәктәптән кайтканда, машинага утыртып урлап киткәннәр иде. Супермаркет директорының малае белән бутаганнар. Акча суырырга теләгәннәр шулай. Ярый әле, ялгышларын аңлап, бакчалар янында төшереп калдырганнар мескен малайны. Әнисенә соңыннан гына сөйләп биргән. Шулай тавышсыз-тынсыз гына үтеп китте, милициягә әйтеп тормадылар. Кстати, син мильтоннарга хәбәр итмәдеңме звонок турында?

— Юк. Бик каты кисәткәннәр. Кәҗәләрсез генә килсен, дигәннәр.

— Кәҗәләр?! Ха-ха-ха... — Илгизә башын артка ташлап шаркылдап көлеп җибәрде. Фәндәснең ачуы килде.

— Яхшы чакта көләбез дә, башыбызга кайгы төшсә, шулар янына чабып киләбез бит.

— Ну, чабып бардың, ярдәмнәре тидеме соң? Ник дәшмисең? То-то, җанкисәгем. Алар синең белән мине түгел, мафияне яклый шул. Кайда акча — бер букча.

Фәндәс тагы сәгатенә карап алды.

— Унберенче китте бит инде! Неужели алдадылар!? Белмим, аңламыйм! Кемгә, нигә кирәк булды ул бала? Терелләй тапыйлар бит йөрәкне. Энҗегә ни диярмен? Ул бик өметләнеп калды. Үзе дә бала гына бит әле.

Җәйге ни озын көн дә хушлашып китеп бара. Кояш офык артына төшеп югалды, җир өстенә әкрен-әкрен генә караңгылык үрмәләде. Фәндәс тә, Илгизә дә бер сүз дә дәшмичә үз уйларына батып утыралар.

— Фәндәс...

Болай итеп бары Илгизә генә дәшә ала. Әйтерсең, дөньяда шул исемнән дә матуррак исем юк та. Вулкан авызыннан оеп, саркып чыккан кайнар ташкын кебек җылы бөрки ул тавыштан. Ир-ат затын әсир итәр өчен гүзәллек кенә түгел, әллә нинди сихри көчләр биргән хатын-кызга Ходай.

— Фәндәс... Сине минем кебек яратучы бармы икән бу дөньяда? Их, белмәдең кадерләремне. Үзең дә яратасың бит. Бүген шуны аңладым. Сагынгансың син мине. Ник газаплыйсың үзеңне? Теге баланы да...

— Нинди баланы?

— Хатыныңны әйтәм. Сиңа пар түгел ул. Яшь, имеш, кыз, имеш... Ну, нәрсә оттың инде шуннан?! Назга сусап яшисең бит.

Илгизә озын тырнаклы нечкә бармакларын ирнең куе, кылдай каты чәчләренә батырды.

— Сиңа мин кирәк, Фәндәс. Мин кирәк!

Фәндәс карашын читкә борды.

— Илгизә, тукта... Вакыты, урыны ул түгел.

— Син мине бүлдермә. Сөйлисем килгәндә сөйләп калыйм әле. Дөреслектән качма, Фәндәс. Хатының белән сине бала гына бәйли, шулай бит?

Бу сорауны үзенә үзе дә биргәне бар Фәндәснең. Энҗе — аның ачылмаган чәчәге. Үз учагы, үз куллары белән кабызган учагы. Кипкән, коры-сары утыннардан түгел, яшьлек суы тамып торган талчыбыклар салып тергезде аны Фәндәс. Тиз генә кабынып, кызып китә алмый әле ул учак, аңа җылы сулыш өрәсе бар, аны җил-яңгырлардан, яман күзләрдән саклыйсы бар. Килер бер көн — учак дөрләп янар, һәм ул бары аныкы, Фәндәснеке генә булыр. Ә Илгизә — башкалар кабызган, теләсә кем коры-сары ташлап киткән очраклы учак кына. Фәндәс әнә шул әзер учакка килде, аркасын җылытты. Ә учакны саклау, сүндермәү аның бурычы түгел. Менә шундый фәлсәфи уйларга бирелеп куя иде ир. Ә бүген башкача уйлый башлады. Пыскып янган салкын учак туйдыра башлаган икән. Чи утынның кабынуын көтеп, санап кына бирелгән гайрәтле елларын әрәмгә уздырсынмы? Юк, ул Илгизәдән баш тартмаячак. Күңеле киң Фәндәснең: аның тормышында икесе өчен дә урын җитәрлек. Ләкин хәзер түгел, соңрак. Башта улын табасы, өендә тынычлык урнаштырасы бар.

Ә Илгизәнең кайнар сулышы битләрен яндыра.

— Фәндәсем, алтыным. Әйдә китик бергә. Хет җир читенә. Туйдым бу пычрак шәһәрдән, гостиницадан, таракан көтүе кебек басып алган әрмәннәрдән туйдым. Китик, бәгърем... Минем белән бәхетле булырсың. Илгизә апаң беркемнән дә обижать иттермәс үзеңне, кадерлем.

Үзе сөйли, үзе үбә. Фәндәс хисләрен тыя алмаган хатынны читкә этте:

— Илгизә!Син бит бөтен эшне бозасың!

Хатын аңа буйсынды, үзен кулга алды. Чәченбашын рәтләде дә, урыныннан кузгалды. Ул елмая иде.

— Хуш, егетем.

Машинасына утыргач, озын итеп сигнал бирде. Пыяласы төшерелгән тәрәзәдән кул болгый-болгый үтеп китте.

Ә Фәндәс озак утырды әле урман буенда. Бар дөньяны караңгылык чорнап алды, фараларын кабызып, анда-санда машиналар үткәләде. Сәгать унбер тулды, уникe тулды... Тик Фәндәс көткән кешеләр күренмәде.

* * *

Ә бу вакытта Энҗе балалар хастаханәсендә утыра иде. Йөрәк парәсе — сабые система астында ята. Күп елаудан, ачлыктан ул соң дәрәҗәгә җитеп хәлсезләнгән. Ә әнисенең имезергә сөте юк... Табиблар аны тынычландырдылар: улы терелячәк! Үз бәхетенә үзе ышанмыйча сабыенең йокысын саклый ана, улының һәр хәрәкәтен, һәр сулышын күзәтеп утыра. "Барысы да әйбәт, ял итегез", — диделәр аңа. Ләкин аны моннан бернинди көч тә кузгата алмаячак. Энҗе үзенең нарасыен бер генә секундка да ялгыз калдырмаячак. Утсыз янган йөрәген кабат яраламас өчен аңа барысын да сөйләп тормадылар. "Баланы Сергеевка авылы кешеләре табып китерде", — дип кенә әйттеләр.

Әгәр шушы авылның Павел атлы кешесе мунча миңлеге әзерләргә дип урманга бармаган, яки барып та этен ияртмәгән булса, бала терелэй җиргә күмеләсе иде, дигән хәбәрне ул күтәрә алыр идеме икән?..

* * *

Дүшәмбе көнне Фәндәсне милициягә чакырдылар. Кабартма битле лейтенант аның белән елмаеп исәнләште.

— Малайның хәле ничек? — дип сорады.

— Җан керде бераз, елмая башлады.

— Җинаятьченең кем икәнен белдек бит, мәсәлән. Тота гына алмыйбыз үзен. Шәһәрдән үк чыгып тайган ахры. Өе бикле, эшендә юк. Документларын алып киткән. Менә шундый хәлләр...

— Үз кулларым белән буып үтерер идем мин аны, судсыз-нисез. Фашист! — диде Фәндәс нәфрәтләнеп. — Кем ул? Кешеме, әллә ерткычмы?

... Юк, моңа ышануы авыр иде. Әмма фактлар раслый, барысы да дәлилләнгән: кунакханә мөһере сугылган ертык җәймә, аның бармак эзләре калган көрәк...

— Мин аның кайда икәнен беләм, — диде Фәндәс. Бала урлаучы белән соңгы тапкыр кайда, ничек очрашуларын сөйләп бирде. Лейтенант аны бүлдермичә, битараф кына тыңлады. Җинаятьчене тотарга дип сикереп тормады, Фәндәскә кызганулы караш ташлап: "Хым..." — дип кенә куйды.

— Ул авылда, әнисендә качып ята! — дип кабатлады Фәндәс.

Ул Илгизәнең балалар йортында тәрбияләнүен һәм дә милиция архивында аның турында байтак кына "истәлекләр" саклануын белми иде...

Укучыларыбызның берсе

Исәнмесез, хөрмәтле "Идел" журналы хезмәткәрләре?!

Бездә "Идел" альманахының 1970 елдан 1989 елга кадәр дөнья күргән барлык 21 саны да саклана. Ул гына түгел, 60 нчы елларда "Ф.Табеев редакторлыгында" чыгарылган "Идел" альманахлары да бар әле. Журналны гаиләбез белән көтеп алабыз һәм бик яратып укыйбыз. Без әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк кешеләр. Шәхси китапханәбез бик бай, анда 3 меңләп китап исәпләнә. Ел саен өебезгә 15-20 исемдәге гәзитә-журналлар алдырабыз. Шулардан бик күп кисемтәләр алып, аерым букчалар ясыйм (шигырьләр, җырлар, әдәбият-сәнгать әһелләре турындагы язмалар, алар белән интервьюлар, файдалы киңәшләр һ.б.)

Китапка, сәнгатькә мәхәббәт уятучы кеше — әнием. Ул, мин мәктәпкә йөри башлаганчы ук, кычкырып китаплар укып, моңлы тавышы белән "Тәфтиләү", "Су буйлап", "Эскадрон", "Иске карурман" җырларын җырлап, күңелемне баета башлады. Әнием Сәхипҗамал үзенә ошаган шигырьләрне аерым дәфтәргә күчереп ала, гарәп, латин хәрефле китапларны кадерләп саклый, шулар белән безне дә таныштыра иде. Борынгы маҗаралы кыйссаларны һәм тагын байтак әсәрләрне мин шулай кече яшьтән үк белеп үстем "Сак-Сок" бәетен, "Таһир-Зөһрә" кыйссасын, "Әбугалисина"ны, "Каһарман катил" дастанын миңа әнием укыды.

Баш мөхәррир Рашат Низамиевның Фәрит Яруллин турындагы китабына гашыйкмын. Ирләрчә ныклы кул белән язучы (Туфан абый фикерен яза дип уйламагыз, Нәбирәне укый башлагач ук, аның язу стиленә шаккатып, үзем шундый фикергә килгән идем) Нәбирә Гыйматдинованың бер әсәрен дә калдырмыйча укып, һәрбер чыккан китабын алып барам.

"Идел" журналының быелгы беренче саны бик матур конкурс игълан иткән. (Татар әдәбиятындагы иң шәп мәхәббәт шигырьләренә — Ред.) Мине, шигъриятне аеруча сөюче буларак, бу конкурс үзенә бөтереп алды.

Мактанып әйтүем түгел, мин барлык татар шагыйрьләренең әсәрләрен укып, күзәтеп торам. Китапханәбездә шигырь китаплары шактый. Әмма алар арасыннан конкурска иң яхшы мәхәббәт шигыре сайлап алу минем өчен энә белән кое казу. Ник дисәгез, Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Галиев, И.Юзеев, Ә.Баян, Х.Камалов, Г.Рәхим, Р.Гаташ, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Ф.Ярулин, Зөлфәт, М.Әгъләмов, К.Сибгатуллин, С.Гәрәева, С.Сөләйманова, Г.Зәйнашева, К.Булатова, Ш.Җиһангирова, Э.Шәрифуллиналар — мәхәббәткә мәдхия җырлаучылар. Алар һәм башка бик күпләр берсеннән-берсе матуррак мәхәббәт шигырьләре иҗат иткәннәр һәм итәләр. Менә шуның өчен дә мин сезгә башка шигырьләр юлларга булдым. Конкурс шартларына каршы килеп булса да (сез бер генә шигырь сорагансыз, һәм авторы белән), җибәргән шигырьләрне карап чыксагыз иде. Өч шигырьнең дә авторлары билгесез. Бәлки сезнең арадан авторларын белүчеләр табылыр?

Хөрмәт белән, Апастан Миләүшә Вәлиуллина

Редакциядән. *Укучыбыз җибәргән шигырьләр конкурска килгән башка шигырьләр кебек үк, конкурсның жюриена тапшырылачак.*

Марсель Галиев.

Алданудан куркам.
1989, №2.

...1964 нче елның августы. Якты көннәр. Азнакай илнең беренче кешесен — Никита Сергеевич Хрущевны каршыларга әзерләнә.

...Көтәбез. Кояш төшлеккә җитте. Кыздыра. Кинәт кычкырган тавыш:

— Килә-ә!

Озак көтеп арудан гамьсезләнә башлаган гавам, кайнап, бер сулыштан тупланып өлгерде. Минутлар үтә, урам буш. Шаяртканнар гына. Билгесезлек каршында алдану җиңел. Тагын берничә тапкыр шулай кычкырдылар. Андый чакта барыбер ышанып алданасың икән. Әз генә читкә тайпылсаң да күрми калырсың, узып китәрләр кебек.

Шул чак урам уртасына бер аягына титаклап җүләр Гасима килеп чыкты. Беләгенә аскан сумкасы шактый авыр күренә.

— Җүләрләр! Нишләп ятасыз монда?! Кибетләргә колбаса-май чыгарып өйгәннәр. Ул карт китүгә җыеп алалар бит аны! Барыгыз, җүләрләр!

Ул арада Гасиманы ике милиционер култыклар алдылар. Гасима халык арасына кереп чумар алдыннан, каерылып, тагын бер инәлеп кычкырды:

— Авыз ачып каласыз бит, ул карт китү-гә...

...Көтәбез. Инде төш авышты. Арган халык барыбер таралмый. Газоннардагы мул үләнлек тәмам изелеп бетте. Аяк астында шиңгән, тапталган чәчәк бәйләмнәре аунап ята. Аны ачык машинада килә дип көткән халыкның нияте изге, чәчәк белән күмү иде. Барысын да ташлаттылар. Имеш, чәчәк бәйләменә таш кыстырып ыргытучылар була икән...

...Без зарыгып көткән вакытларда Хрущев, Ык буендагы миллионер "Авангард" колхозы җирләрен карап йөргәннән соң, Сәпәй умарталыгында төшке ашка тукталган икән (әлеге урынны хәзер дә "Хрущев урманы" дип йөртәләр).

Анда әлеге дә баягы чәчәк аркасында шундый хәл була: бөтен ритуаллар, кемнең кайчан, ничек, нәрсә әйтәсе, нинди хәрәкәт ясыйсы меңкат уйланылган бит югыйсә, ә монда... кинәт кенә урман эченнән бер кызчык йөгереп чыга. Ак бантиклы, үзе кадәр чәчәк бәйләме күтәргән. Җаваплы кешеләр катып кала. Нишләргә? Бу бит программада каралмаган. Тән сакчылары ничек искәрмәгән? Никита Сергеевич үзе каршы килеп, кызчыктан чәчәк бәйләмен кабул итеп, аны үз оныгы кебек итеп сөеп куюга, тирә-юньдә чүгеп калган җаннар тураеп, үз рәвешен ала.

...Ниһаять, урамның аргы очыннан башланган дулкын, күкрәп, безнең тирәгә дә килеп җитте:

— Килә! Киләләр!!

Халык тетрәп, урамның як-ягына тыгызлашты. Мин алгы рәттә, арттан бәргән кайнар сулыш, күкрәк көчен тоеп торам. Килә... урам уртасыннан елык-елык итеп тимер ташкын килә. Иң алдан юлны авыр дерелдәтеп, брезент түбәле мәһабәт ЗИЛ үтеп китте. Аннан йөз метрлар кала шундый ук машина. Үзе! Күпме сурәтләрдә күреп күнеккән түгәрәк йөз. Ян тәрәзәдән кул болгап килә. Тизлек уртача. Вакытны туктатырга тырышып, текәлеп карыйм. Менә ул миннән бер сулышлык арада. Катлы-катлы ияк, арган кыяфәт. Халыкның шашып сәламләвенә артык исе китми кебек. Миңа тарих җиле кагылып уза. Ул шофер кырыенда. Артта галәмәт зур гәүдәле хәрби кеше. "Генерал", дип уйлап өлгерәм.

Тукталмады...

...Ат аунаган җирдә төк кала, диләр. Соңыннан төрле сүзләр таралды. "Авангард"ка тирә-як авыллардан эре, нәселле дуңгызлар җыйганнар икән дә, делегация киткәннән соң, үз дуңгызларын танып бүлешә алмыйча, председательләр арасында гауга чыккан, имеш. Умарта ояларын җете кызылга буяганнар да кортлар качып беткән, имеш. Кайсы чын да кайсы ялган — халык арасына таралганны кире җыеп ала алмыйсың.

Ркаил Зәйдулла.

Ельцин түбәтәе.
1992, №1-2

...Бераздан Ельцинның Язучылар белән очрашырга киләсе дә билгеле булды. Бу хәбәрне безгә Язучылар союзы рәисе Ренат Мөхәммәдиев җиткерде. Аның шулай Мәскәүдән сирәк-мирәк кайткан араларда: "Горбачев белән сөйләшеп тордым әле", "Ельцин белән күрештем", — дип, безне шаккаттырып китә торган гадәте бар иде, шуңа күрә бу хәбәргә без башта артык игътибар да бирмәдек. Ләкин бу юлы союз рәисенең кара кучкыл йөзе тагын җитдиләнгән, күзләре дә бүтәнчәрәк карый иде. "Язучылар белән очрашуны үзем программага керттем", — диде ул тирән коедан чыккан тавыш белән. Барыбыз да тирән хөрмәт белән аңа төбәлдек.

...Сәгать дүрт тулганда парад ишеге тирәсендә коточкыч гауга куба. Язучылар союзы хезмәткәре Мансур Шиһаповның ярсулы тавышыннан стенага эленгән портретлар дерелди, акшар коела.

— Кая ул? Кая ул? Аңгыра-а... — дип үкерә Шиһапов. Аның бу әрнүле авазы суга батып барган кешенең иңрәвен хәтерләтә.

Ельцинга террористлар һөҗүм иткәнме әллә, дип шул якка ашыгам. Кешедәге кызыксыну хисе барыннан да өстен бит ул. Инде суда тончыгам дигәндә генә саламга ябышкандай, Шиһапов минем изүдән эләктерә, — алты-җиде ел ял итүдән соң ныгып алган куллары келәшчәдәй кысылган, күз алмалары орбитадан ычкынып, космоска алгысына:

— Ркаи-ил! Кая ул? Кая ул?

— Кем? Ельцинмы? — дим мин аптырап.

— Җиһан, Җиһан кая?

Мәсьәлә ачыклана. Вахтер карчыкка парад ишеге төбендә сәгать дүрткә кадәр торырга кушкан булганнар икән, дүрт тулгач, ул ишеккә имән таякны тыгып, йозакны бикләп каядыр китеп тә барган. Менә-менә Ельцин килергә тиеш, ә парад ишеге бикле. Мин Шиһаповка кызганып карыйм. Үкерерсең дә, нибуч. Мондый проколларны гафу итмиләр. Элек бай хезмәтчеләре, кучерлар, ә хәзер татар язучылары кереп-чыгып йөри торган арткы ишектән алып кермәссең бит инде Ельцинны шундый затлы бинага?

Ә Җиһан карчыкка нәрсә — ул Сталин заманы кешесе, төгәллеккә өйрәнгән. Дүрткә кадәр дигәннәр, нәкъ дүрттә ул парад ишеген шапылдатып бикләп алган. Ельцинның соңга калуында аның ни эше бар? Эшкә ике минут соңга калганга да унар елга Колымага эләккән чакларны яхшы хәтерли ул. Үзе дә ничәдер ел шунда яшәгән... Ниһаять, Җиһан карчыкны эзләп табалар. Шиһапов, тормозы ычкынган трактор кебек, аның өстенә килә:

— Кая йөрисең син?! Чәчемне агарттың... инфаркт...

Тик вахтерны мондый приступ белән генә алырлык түгел. Казан артыннан ул — бөтен урыс патшаларының рәхәтен

татыган яктан:

— Кычкырма!.. — дип чырылдый ул. — Ильсин килә дип бәдрәфкә бармый торыйммы? Киләсе кеше килер, шайтаныма да олакмас...

Шиһапов — верноподданный, без мизгелгә ачылган авызын йомарга онытып тора, тик каршы әйтми, вахтерлар белән сүзгә килүнең ахыры яхшы бетмәсен ул да яхшы белә. Дөнья күргән кеше...

...Менә ул көтелгән мизгел! Колакларны тондырып кул чаба башладылар. Сокланулы тавышлар, арттагы рәттәгеләр урындыкларын шапылдатып урыннарыннан торалар, бер мәлдән бөтен зал аягүрә басты. Бары тик алдагы ике-өч рәт кенә урыннарыннан калкынмадылар...

— Сезнең халык бигрәк хисле, — ди Ельцин сәхнәгә үтүгә. — Чак костюм җиңен умырып төшермәделәр...

Зал көлеп җибәрә, барысы да иркен сулыш алалар — менә бит ул Ельцин нинди гади, үз кеше!..

...Үземнең язучылык нәфесемне канәгатьләндереп утырган арада Ельцин инде сүз алган, ул мавыгып Кытай турында, аның реформалар нәтиҗәсендә ирешкән уңышлары турында сөйли иде. Ул безгә Ерак Көнчыгышта ирекле биләмәләр ачуның файдасын исбатлый иде...

...Кайнар канлы Бәйрәмова түзеп утыра алмады, Ельцинның бер паузасыннан файдаланып, беренче рәттән чәчрәп тә чыкты:

— Без Кытай турында тыңларга килмәдек, безнең үз проблемаларыбыз да муеннан ашкан! Шуларга якынрак килсәгез иде...

Рәсәй лидерының йөзе бурлаттай кызарып чыкты, күзләрендә дәһшәтле чаткылар кабынып сүнде, иреннәре тагын да сузайды. Күренеп тора — сүзен бүлдергәнгә өйрәнмәгән иде ул...

— Эмоцияләргә бирелмик, иптәшләр. Тынычлап конструктив сөйләшик, — диде ул. — Мин инде берничә көн Татариядә, тәэсирләр, әлбәттә, күп... Монда килгәнче мин Татария халкының культурасы белән танышып чыктым. Менә Язучылар оешмасы... Тикмәгә генә ул 1934 елда беренчеләрдән булып төзелмәгән бит. Хәзер илдә иң зур оешмалардан санала, 200 СССР Язучылар союзы члены бар. Татар культурасы бөтен дөньяда танылды һәм хөрмәт казанды.

Зал тагын гөрләтеп кул чапты. Кайбер урыннардан Бәйрәмовага карап ысылдаган авазлар да ишетелеп алды. Нинди кешенең сүзен бүләргә җөрьәт итә бит, янәсе, бичара...

Мин артка борылып карадым. Сәхнәгә төбәлгән мөкиббән дымсу карашлар агымыннан башлар әйләнеп китте. Тугрылык, бирелгәнлек ләззәте җылы дулкын булып мине дә чорнап алды. Гомуми эйфория эчемә үтеп керде, йомшак учлары белән йөрәгемне иркәләде, хәтта артымда — билдән түбәнрәк төштә — йөнтәс койрык үсеп чыкканын тоя башладым, ирексездән шуны болгыйсы килү теләге уянды.

Казаннан китәр алдыннан Ельцин юкка гына: "Биредә мин бары тик җылы карашлар гына күрдем", — дип әйтмәгәндер. Безнең халык чыннан да киң күңелле, ыштансыз халык. Ыштан ул койрыкны болгарга мишәйт итә...

...Ниһаять ул сүзен тәмамлады. Үз фикерләрен әйтү өчен, сораулар бирү өчен язучылар сөйли башлады.

Сүзне Батулла алды:

— Бүген без бөек рәссамыбыз Бакый ага Урманчены җир куенына тапшырдык. Бер минут тынлык белән аның истәлеген яд итик...

Бөтен зал белән торып бастык. Урманченың исемен Ельцин беренче тапкыр шунда ишетте. Боларның рәссамнары да бар икән, дип уйлап та куйгандыр әле...

Әлбәттә, сорауларның да, чыгышларның да күбесе Татарстанның суверенитеты тирәсендә әйләнде. Шул вакытта күбебезнең мөстәкыйльлеккә әле һаман Мәскәүдән көтүебез ачыкланды. Әйтерсең, аны безгә Мәскәү агайлары зәңгәр каймалы тәлинкәгә салып китерергә тиеш. Менә шунда инде Ельцин үзенең атаклы җөмләсен әйтте:

— Возьмите столько суверенитета, сколько можете проглотить...

...Халык өерелеп залдан чыга. Түбәтәй кигән Ельцин да ишеккә ашыга — аның әле университетта да очрашасы бар. Ул, ничек кирәк алай халыкны ерып чыгып, көтеп торган машинага да утырмыйча кызу-кызу адымнар белән урам чатына — 2 нче трамвай тукталышына юнәлә, кешеләр аңардан калмый ияреп баралар. Ниһаять, трамвай туктый, түбәтәйле Ельцин Кольцога төшәсе урынга кире якка — Чехов базарына таба китеп бара. Демократ!

Туфан МИҢНУЛЛИН

Минһаҗ маҗаралары

Н. Хаҗиахмат рәсеме

Минһаҗ абзый бер ай чамасы күзгә-башка күренми торды. Эзләп өйләренә барган идек, Җомабикә апа капкадан да кертмәде.

— Минһаҗ абзый кайда? — дигән соравыбызга:

— Үзеннән сорагыз, — дип кенә җавап бирде.

— Сорар идек тә, таба алмыйбыз, — дидек.

— Әйбәтләбрәк эзләгез, — дип Җомабикә апа капканы Садретдинның борын төбендә шартлатып ябып куйды. Садретдинның шәмәхә борыны чак кысылып калмады.

Без эзләмәдек. Җомабикә апаның сөйләшү рәвешеннән чамаладык инде: Минһаҗ абзый беркая да китмәгән, исән-сау, өендә бикләнеп ята. Нигә бикләнгән? Монысын инде, күрәсең, без белергә тиеш түгел.

Сер ләкин барыбер ачылды. Минһаҗ абзый үзе үк ачты аны.

Көннәрдән бер көнне безнең янга ул кесәсенә калын дәфтәр тыгып килде. Килде дә дәфтәрне Вәлиәхмәт абзыйга сузды.

— Бик шәпләп, ныгытып укып чыгыгыз. Садретдин да аңларлык булсын. Укып чыккач сөйләшегез. Әйтәсе сүзегез булса, миңа әйтерсез, — диде.

— Нәрсә соң ул? — дидек.

— Закун, — диде Минһаҗ абзый.

— Нинди закон тагын? — дидек. — Закон бит ул гәҗиткә басылган була. Законны дәфтәргә язмыйлар,— дидек.

— Бу — мин язган закун, — диде Минһаҗ абзый.

— Кит әле, Минһаҗ абзый. Безне надан дигәч тә теге. Законны Мәскәүдә язалар, Казанда язалар. Кайпердедә закон язалар димени?! Кайпердедә язылган законга кем буйсынсын? Синең бит әле закон язарга пичәтең дә юк. Пичәт басылмаган закон закон булалмый, — диештек.

— Закун язарга пичәт түгел, баш кирәк. Томана шул сез, томана. Закун язуның тәртибен белмисез. Закунны аны башта бер кеше яза. Аннан аны дипутатлар тикшерәләр. Тикшергәчтен призинтка җибәрәләр. Призинт кул куеп пичәт суга. Белдегезме? Менә миңа да ай ярым элек депутат Туфан Миңнуллин килде. “Минһаҗ абзый” ди, коткар, ди, закун язып бир, ди. Безнең тикшерә торган закуннарыбыз бетте, ә призинт бездән закун сорый”, — ди. “Нинди закун кирәк суң сиңа?” — дим. “Гаилә турында закун яз”, — ди. Гаилә дигән сүз, Садретдин, “симия” дигән сүз була, белеп тор. Сез наданнар симия дисез, без укыганнар гаилә дибез, аңладыңмы?

Бездә бөтен төрле нәрсәгә закун бар икән, гаилә

турында юк икән. Шуңа күрә симияләр бозылышып тарала икән. Лилин янында эшләп закуннар чыгаргалаган булгач, ризалык бирдем Туфан Миңнуллинга. Үзебезнең райун кешесе бит, ким-хур булып йөрмәсен бутәннәр арасында. Шуңарга күрә бик әйбәтләп укыгыз. Ялгышлары булса, әйтерсез, мин нәчәлствы түгел — ялгышымны әйткәннәргә ачу сакламыйм.

Минһаҗ абзый шуларны әйтте дә өенә кайтып китте. Без кызыл тышлы калын дәфтәрне тотып калдык.

— Минһаҗ абзый әйткәч, укырга кирәк, — диде Вәлиәхмәт абзый.

— Кирәк булгач, укы, — дидек.

Вәлиәхмәт абзый укырга тотынды. "Закун. Гаилә турында".

Беренче ыстатия

Гаилә турында закунның бик кирәклеге турында. Ник дигәндә, кеше өйләнмичә яши алмый һәм өйләнмичә яшәргә дә тиеш түгел. Чөнки дә кемнең кем хатыны, кемнең кем ире, кемнең кем баласы икәнен беркем белмәсә, ни була? Бер көн Садретдиннар сарыгының бәрәне адашып Мөслимәләргә кергән. Садретдин, үз бәрәнен Мөслимәләрдә күргәч, бәрәнне алмакчы булган, тик Мөслимә, ул безнең бәрән, дигән. Киткән талаш. Ярый әле Мөслимәләрнең үз бәрәне табылган. Ике бәрән дә бер-берсенә бик ошаган, ди. Ә бит кеше бәрән генә түгел. Сарык та түгел. Авыл кешесенә сарык дип карыйлар инде каравын. Ләкин дә бу дөрес нәрсә түгел. Һәм дә дөрес тә булырга тиеш түгел. Шуңа күрә закун кирәк. Әле күптән түгел генә Садретдин салган баштан үз хатыны дип Габдрахман хатынын кочаклаган. "Оятсыз, дигән Габдрахман хатыны, минем бит закунный ирем бар, синең дә закунный хатының бар", дигән. "Төкерәм мин сезнең закуныгызга", — дигән Садретдин. Нигә ул шулай дип әйткән? Чөнки дә гаилә турында закунның юклыгын белә Садретдин. Әгәр дә закун булса, төкереп карасын. Закунга төкергәннәрнең теленә бик тиз кутыр чыгаралар. Димәк ки, шулай булгач, закун кирәк. Аннан соң, закуны булмагач, гаилә үзе дә булырга тиеш түгел. Менә сыерлар өчен закун юк, аларда гаилә дә юк. Бер көтүгә бер үгез. Бозаулар йөри әниләренә ияреп, үгезгә чурт та юк. Әнә калхуз үгезенә карагыз. Сыерларга саламны туратып, фураж белән бутап, җылы су белән изеп ашаталар. Ә үгезгә нәрсә? Йөри мескен кышның салкын көннәрендә салам эскертләре янында чемченеп. Һәм дә ки шуннан соң ул ике йөз сыерны яратырга тиеш. Алай була алмый. Әмма дә ләкин шул ук вакытта бер сыерга бер үгез дә асырап булмый. Ә кешеләр өчен бер хатынга бер ир тотып була. Бер иргә дүрт хатын да тотып була дип сөйлиләр. Мин бу хакта үз сүземне әйтермен. Безнең калхуз придсидәтеленең хатыннары бишәү-алтау диләр. Ул мир үгезенә алар да аздыр әле. Әмма да ләкин бит бөтен кеше дә андый түгел. Аларның барысын бергә гаилә дип тә атап булмый әле. Закун кирәк. Закунда бөтенесе дә тәртип белән язылсын. Әйтик, менә болай. Нәрсә ул гаилә, дигәннән башлап алып китик.

Икенче ыстатия

Нәрсә ул гаилә? Гаилә ул — авыл савитында язылышкан ир белән хатын. Авыл савитын хәзер җирле үзидарә дип атыйлар инде. Киләчәктә ничек булыр, белгән юк. Безнең илдә бит исем алыштырып уйнау мудыда. Шомбай бүреген әйләндереп кигән кебек. Калхузның исемен бетерәбез дип ниләр генә кыландырмыйлар. Калхуз шул ук. Асатсия дисәң дә калхуз, касатсия дисәң дә калхуз. Гаиләнең балалары да була. Балалары булмаганнары да була. Кайнаналы, кайнаталы гаиләләр була. Алар булмаса кайбер киленнәргә рәхәт булыр иде дә бит, алай гына булмый шул. Кайнана белән кайната кайчандыр ир белән хатын булган шул. Ир белән хатын булгач, тик кенә ятмаганнардыр инде — малайлары туган.

Тагын әле әбиле-бабайлы гаиләләр була. Ягъни мәсәлән, өйләнгән кеше хатынның өенә йортка керә. Монда инде закунны бик дөрес язарга кирәк. Татарга аерым, урыска аерым. Чөнки дә урыста йортка керү элек-электән бар, алар инде ияләшкән. Татарда элек йортка керү булмаган. Хәзер инде татарның да кайберләре йортка керә. Анысы турында бүтән ыстатиядә әйтелер.

Гаиләләрнең язылышмаганын да гаилә дип әйтүчеләр бар. Мәсәлән ки, безнең авылның Сәләхетдин Фәрхиҗамал белән язылышмыйча җитмеш биш ел яшәделәр. Алты малайлары, дүрт кызлары, кырык оныклары бар. Сәләхетдин "безнең симия" дип сөйләргә ярата. Дөрес түгел. Закун ест закун. Икесе дә авыл савиты пичәте сугылмыйча яшәргә ни имиет правы. Или пичәт бастырсыннар, или аерылсыннар, или "симия" дип сөйләп йөрмәсеннәр. Без дә анысы Җомабикә җиңгәгез белән авыл савитында язылышмаган. Аның каравы, безгә Казан мулласы никах укыган да, Бладимир Илич Лилин безнең ир белән хатын икәнлекне үзе күреп торган. Аннары соң, мин бит "симия" дип сөйләнеп тә йөрмим. Маручкалар янына баргалаганмын икән, туже закунны бозмадым, симия булмагач барылгандыр инде.

Ызгышып, талашып торган гаиләне гаилә дип атаргамы? Атарга, әмма дә ләкин аерым ыстатиядә талашуның тәртибен ныклап язып куярга.

Әгәр дә хатын-кыз кияүгә чыкмыйча гына балалар тапса, ул гаилә буламы? Бу бик четерекле нәрсә. Шуңа күрә моңа аерым ыстатия кирәк. Әгәр дә ир кеше өйләнмичә генә бала таба икән, ул гаилә буламы? Көлмәгез. Бу көлке түгел. Бу хактагы ыстатияне укыгач көлке түгеллеген белерсез. Гаиләдә кемнәр булганы әйтелгән иде, шуларның һәрберсе турында закунда аерым-аерым ыстатия булсын. Чөнки дә гаиләдәге һәр җан иясе үзенең кем икәнен, нишләргә тиешлеген, нишләмәскә кирәклеген белсен. Шуны белмәү аркасында дөнья буталып бетте.

Өченче ыстатия

Кем ул ир? Ир ул үзе яраткан хатын белән язылышып торучы кеше. Өйләнгәнчегә хәтле ул җегет дип атала. Өйләнгәнчегә хәтле җегет булып җитешә алмаучылар да була булуын. Алар өйләнгәч тә ир булып бетә ал-

мыйлар. Анысы аерым ыстатия. Ир булыр өчен өйләнү кирәк. Гаиләң булу кирәк. Әле ул гына да җитми. Шул гаиләңне ашата алырлык рәтең булсын. Монысы — бер. Икенчесе — хатыныңны күрше ирләренә карамаслык итеп кочакларлык рәтең дә булсын. Шуңа күрә дә, әгәр дә берәр җегет авыл савитына, мин өйләнәм, дип бер кыз ияртеп килә икән, аңарга шушы сораулар бирелергә тиеш: беренчесе: хатыныңны ашата аласыңмы? Икенчесе: хатыныңның күңелен күрә аласыңмы? Әгәр дә өйләнергә теләгән малай, ашата алмыйм, мин үзем хатын эшләгәнне ашарга җыенам, дисә, авыл савитыннан йомшак җиренә тибеп чыгарырга. Әгәр дә мәгәр, ашата алам, дисә, ничә бала ашата аласың, дип сорарга. Унны дисә — яшел таныклык бирергә, бишне дисә — кызыл таныклык бирергә, берне генә дисә, сары таныклык та ярый.

Инде шуннан соң, хатыныңның күңелен күрә аласыңмы, дигән сорауга, нәрсә соң ул күңелен күрү, дип сораса, бар, энем, башта аның нәрсә икәнен әтиеңнән сорап кил, дип кайтарып җибәрергә. Белеп килсә һәм дә күңелен күрә алам дисә, ышанырга. Ләкин кәгазьгә ашата алам, күрә алам дип кул куйдырырга.

Әгәренки берничә елдан соң берәр хатын килеп иреннән зарланса, ул мине ашата алмый, балаларын ашата алмый, күңелемне күрми, чөнки дә эчеп йөри-йөри аның инде рәте беткән дисә, теге ир дип аталган имгәкне авыл савитына чакыртып алырга да, теге чакта куйган кулын күрсәтергә. Нигә син теге чакта алдаштың, сабакы, диярга. Төзәләм дисә, бер тапкыр ышанып карарга, төзәлмим дисә, печәргә дә ир дигән исемен тартып алырга. Паспортына хатын-кыздан да хуже дип язып куярга. Юкса, безнең авылда бер җирдә дә эшләмичә, хатыны тапканны эчеп йөрүче Әхмәдиша, мин сиңа мужикмы, юкмы, дип үзен ашаткан хатынын кыйный. Син мужик түгел, дип әйтер иде хатыны, тегенең паспортына мужик дип язылган. Бу бәндәләр мужик булмагач, балалары да аныкы була алмый ич инде. Шуңа күрә ул балаларга әниләренең фамилияләрен бирергә.

Ирләрне бала чакларыннан ук ир итеп үстерергә кирәк. Яңа туган ир балаларның муенына "Тукмак асып йөргән һәр кеше дә ир түгел әле ул!" дип язу язып элергә кирәк. Ул язу, ир малай булып туган кеше өйләнгәч, хатын белән иң кимендә өч ел яшәгәч, хатыны тарафыннан алынырга тиеш. Хатыны алмый икән ул язуны, ир булырга тиешле сакаллы малай шул язу белән үлгәнче яшәргә тиеш. Ир дулый башласа, хатын бармагы белән шул язуга гына төртеп күрсәтергә тиеш. Садретдинның муенында шул язу булса, бугазын бик киерә алмас иде, примир.

Ирләрне яшь чакларында кияү дип атыйлар, картайгач бабай һәм кайната диләр, ике егет бертуган кызга өйләнсәләр баҗай булалар.

а) Кияү булу җиңел түгел. Иң беренчесе: ул хатынының әнисенә, ягъни мәсәлән әбиенә ошарга тиеш. "Әби, әби!" дип елмаеп торсын. Шул чакта аңа кайнар коймак та, кияү пәрәмәче дә эләгәчәк. Ара-тирә кияү кеше әбиенә чәчәкле яулык бүләк итсен. Анда инде әби кеше үз иренә ашатасы ризыкны да кияүгә ашатачак. Кияү әбиенә бик кыйбатлы бүләк алмасын. Карчык кеше нәфесле була, пәлтә алып бирсәң — тун көтә, тун бүләк итсәң, алтын алка өмет итә.

Кияү хатынының әтисен "бабай" ди. Бабай белән сак булырга кирәк. Чәчәкле яулыкларга алданучы зат түгел. Әгәр дә бабайның якты чыраен күрәсең килсә, мәгънәле сүз сөйләргә кирәк. Күбрәк бабайның сүзен җөпләп "әйе, әйе, дөрес әйтәсең, бабай" дип утырырга тиеш кияү. Әнә Вәлиәхмәтнең кияве, Вәлиәхмәт сүзен җөпләп, Вәлиәхмәтнең соңгы акчасына алынган машинада йөри.

Кияүнең балдызы булуы мөмкин. Элеккеге бабайларыбызның "балдызның бер аягы җизнәсенеке" дигән татар халык сүзенә ышанып, балдызга үрелмәсен. Ул болай гына, на всякий случай гына әйтелгән. Кияү туры мәгънәсендә аңламасын. Сүз дә юк, балдыз һәрвакытта да хатыннан матуррак күренә. Балдызны хатын алдында мактарга ярамый. Хатын мондый очракта үз туганыннан да көнләшә.

Кияүнең кайнише дә булуы ихтимал. Үзләре шәп булса, кайниш итәргә, шәләй-вәләй йөрсәләр җизниләренең өендә эзләре булмасын. Вәлиәхмәтнең кайнише районда урында утыра. Кәнишне, ул әйбәт кайниш. Садретдин кайнише кайда? Шаталтрестта нәчәлнек. Нигә кирәк андый кайниш.

б) Ирләрен бабай ясаучы — аларның кызлары була, шуны онытмаска кирәк. Камәрттиннең бабай буласы килмәгән иде дә, егетләр сыман кызларга күз кысып йөри иде, кызы кияүгә чыкты да бабай булды да куйды Камәрттин. Бабайларга закунны каты язарга кирәкми. Кызын киявеннән саклап вакланып йөрмәсен — шул гына. Үзең чыктыңмы кияүгә? Чыктың — яшә чыкканың белән генә, дип әйтсен.

Кайнатага да шул сүз. Кысылмасын килен эшенә. Кайната киленне үз карчыгыннан, үз карчыгын киленнән сакларга тиеш. Бу, кәнишне, бик авыр эш. Запарктагы арысланнар читлегенә кереп йөрү белән бер. Ләкин түзсен. Шуңа күрә ул — ир кеше.

в) Баҗай. "Кәҗә мал түгел, баҗа туган түгел" дигән сүзне сызып ташларга. Дөрес түгел ул. "Баҗалар иң якын туганнар" дип закунга язып куярга. Чөнки бертуган хатыннарыннан алар бергәләшеп нужа күрәләр. Баҗаң калхуз придсидәтелеме, глава-мазармы булса, дөнья рәхәте. Вәлиәхмәт киявенә машина алырлык акчаны каян тапты? Баҗасы Казанда завсклад иде заманында.

Дүртенче ыстатия

Кем ул хатын? Хатын ул авыл савитына, ягъни җирле үзидарәгә барып үзе яраткан ир зәты белән язылышып торучы, ягъни мәсәлән, кияүгә чыккан кыз кеше. Кияүгә чыгучының кыз булмавы да мөмкин. Анысы турында бик каты һәм дә ки бик акыллы аерым закун язарга кирәк. Без язган закунда кияүгә чыккан һәр хатын-кыз хатын дип аталырга тиеш. Хатынның әбәзеннестләре нинди? Ирен, балаларын тәрбияләсен. Аларның өстебашы чиста булсын, ире тапкан ризыктан адәм ашарлык ризык пешерсен. Ачык чырайлы булсын. Әгәр дә өендә рәтле ризык күрмичә, җүнле сүз ишетмичә изаланган ир уҗымга керсә, хатыны "хыянәт, хыянәт" дип шыңшып йөрмәсен. Тамагы тук хайван көтүдән уҗымга керми. Хәер, кәҗә дигәне әллә ни ашатсаң да керә инде. Анысы

башка ыстатия. Иркәләнеп торган хайван да көтүдән өенә кайта. Вәлиәхмәт бит үз хатыны тирәсендә генә чуала, аракы да эчми, чөнки дә хатыны шәп. Садретдин исерек башы белән бүтән хатыннар артыннан йөрмәкче була. Мескен. Чөнки дә хатыны тужы рәтле сүз әйтә белми Садретдинга.

Хатын куштан булырга да тиеш түгел. Куштан хатынның балалары маңкалы була.

Хатынга иренең кесәсен актару кәтигәрически тыела. Чөнки дә ул эшнең мәгънәсе юк. Әгәр дә мәгәр иреңнең акчасы юк икән, актарсаң да юк инде ул, актармасаң да юк. Садретдин кесәсен ун ел актарсаң да тәмәке валчыгыннан башка ни табасың. Әгәр дә бар икән иреңнең акчасы, нигә аны актарып торырга. Кирәк икән — үзе бирер. Бирми икән, значитсы акча үзенә кирәк. Мужыт сыра эчәсе килгәндер, мужыт берәрсенә шикалад алып бирәсе итәдер.

Хатын иреннән акыллырак булса да, акыллы итеп күрсәтмәсен. Җомабикә җиңгәгезне әйтмим миннән акыллырак дип, ләкин дә аңгыра да түгел. Ә үзе, Минһаҗетдин абзагыз ни әйтсә — шул дөрес, дип тора. Аның каравы, түшәккә яткач иман шартына өйрәтә инде. Яныңда Җомабикә түгел, Гассавит депутаты яткан дип уйларсыз.

Хатын бизәнеп йөрсен. Чит-ят ир күзенә ничек күренергә теләсә, үз иренә дә шулай күренсен. Бер көн Садретдин хатынын күрдем ишегалларында — куркып киттем. Миңа ул хатынны балга, майга манып бирсәләр дә ашамас идем. Шул хатын урамга чыгып Садретдинны яманлап йөри, яныма ятмый дип зарлана. Андый хатын янына Садретдин шикелле дөм исереп ятсаң гына инде.

Хатын иркә булырга тиеш. Ятсын беләккә, әйтсен колакка, үтсен йөрәккә. Мәче кебек яныңда сырпалансын, кулыңа алып җон уңаена сыйпаганыңны сизми дә калырлык булсын. Ата каз сыман ысылдап торган хатынны кочаклап булмый, гафу итегез, извините, кем әйтмешли.

Хатынны беркая да чыгармыйча өйдә генә тоту, алай ярамый, болай ярамый дип тукып тору кәтигәрически тыела. Ирләр белсеннәр: бәйдәге эт усал була. Безнең авылның тычкак Гаптери нишли? Хатыны ишегалдына чыкса да ияреп чыга иде, хатыны берәр кеше белән сөйләшеп торса да күзен акайта иде. Нәрсә булды. Нәрсә булганын әйтмим инде, юкса бүтән хатыннар да шулай эшли башларлар.

Ачу килгәндә хатынга кул күтәрү — хайванлык. Шуңа күрә, хатынын кыйнаганнарга хайван дип карарга кирәк. Хатын дөньяга ни өчен яратылган? Иренең ачуын китереп ирне сынар өчен. Чын ирме ул, юкмы. Чын ир булса, җаен таба, булмаса — хайван була. Җомабикә апагыз ачуны китергәндә мин нишлим? Ишегалдына чыгып утын ярам, кыш көне булса, кар көрим. Эш тә эшләнә, ачу да басыла, эшләп кергәндә Җомабикә дә юашланган була.

— Арыдыңмы, Минһаҗетдин, әйдә, чәй эч, — дип тора.

Хатын-кыз Адәм галиәссәламнең кабыргасыннан яратылган. Шуны закунга ук язып куярга. Нигә кирәк дигәндә, ирләр хатыннарына үз кабыргасын кадерләгән кебек кадерләп карасын, хатыннар ир кабыргасыннан икәнлекләрен онытмасын.

Ирләрнең бабай, кияү, баҗай чаклары булган кебек хатыннарның да әби, кайнана, килен-киләндәш булган чаклары була. Ирләрнең бабай, кияү, баҗай чаклары бер ыстатиягә сыйса, хатыннарның кайнана, килен, килендәш чакларына аерым ыстатияләр кирәк. Чөнки дә хатын дигән җан иясе бер генә ыстатиягә сыя алмый. Ул әле хәтта закунга да сыеша алмый. Садретдинның хатынына, примир, ун закун да аз. Фәлән дә итмим мин ул закуныгызга дип үз туксанын туксан итәчәк.

Бишенче ыстатия

Кем ул килен? Ул кайнаналы, кайнаталы, кайнагалы, каенсеңелле хатын. Күрәсезме, ничаклы күз карап тора бу җан иясенә. Әгәр дә мәгәр яңа гына кияүгә чыккан кыз шул күзләрдән куркып калса, бетә. Нимесчә әйтсәк, капут. Әгәренки бу күзләрнең буласын алдан белеп, алардан курыкмаска план төзеп чыккан булса кияүгә һәм шул план буенча теге күзләрне чукырга тотынса, тужы капут. Килен ул иң кимендә алты-җиде нәчәлникнең йомышына чабып, барысыннан да рәхмәт ишетә белгән, үзенә әз-мәз чумара да калдыра алган калхуз завхузы кебек булырга тиеш. Придсидәтел әйтә икән, Вәлиәхмәт абзый, бүген Казаннан кунак килә, караштырып куй әле дип, завхуз күл буенда нәрсәдер көйләп куярга тиеш. Әйтә икән бугалтир, Вәлиәхмәт абзый, райуннан налагавый инспектор килә дип, завхуз тегенемоны табыштырып куярга тиеш. Килен дә шулай булсын. Кайнанасына "Син тик кенә тор, карт убыр", дип кычкырып әйтмичә эчтән генә уйласа, тыштан, "хәзер, әнкәй, хәзер" дисә, озын гумерле була. Әнә Камәрттин Хәлидәсенең килене атом бумбасы кебек шартларга торучы кайнанасы белән ничек тора. Хәлидә менә шартлыйм, менә шартлыйм дип кыза башлауга, килен тегенең авызын майлы коймак белән каплый да куя. Садретдинның килене нишли? Дальний вастуктан кайтып кайнанасы белән талашып китә иде. "Авылга кайтып, шул җен карчыгына әйтәсемне әйтеп китмәсәм, тамагымнан азык узмый", — дип әйткән ди бер кайтканында. Әйтүен әйткән дә, Дальний вастукта эшләр кәкәйләнгәч, шул җен карчыгы янына кайтып егылдылар. Вәт бит ул дөнья.

Иң хәйләкәр, иң акыллы, иң яхшы килен — кайнатасына сөйкемле булып күренә торган килен. Әнә Вәлиәхмәт ничек мактый киленен. Юкса аның килененең баскан токмачы да Вәлиәхмәтнең баш бармагы калынлыгы. Вәлиәхмәт киленен мактый, хатыныннан токмач бастыра. Чөнки дә аның килене Вәлиәхмәткә елмаеп кына тора. "Безнең әткәй җегетләргә биргесез әле ул", — дип Вәлиәхмәтнең җил ягына салам кыстыра.

Килен кайнагага да елмаерга тиеш. Чөнки энекәшенең хатыны елмаеп: "Безнең абый бал ярата", — дип кайнагасының алдына бер кашык бал куйса, кайнага ул бер кашык балны бер тәпән итеп күрәчәк. Һәм энекәше киленгә кычкырган вакытта, "тимә киленгә, муеныңны борып өзәрмен", дип киленен энекәшеннән саклаячак.

Кайнигәч турында әйткәндә инде, ничегрәк әйтергә дә аптыраган. Ул кайнанадан да яман. Әгәр дә инде бу

адәми зат кияүгә чыга алмый калган карт кыз да булса, эш тагы да хөрти. Закунда киленне кайнигәчтән саклый торган пункыт булсын: әгәр дә каенигәч киленне көн саен чукып тора икән, аны нимидленне кияүгә бирергә кирәк. Әгәр дә алучы булмаса, киленгә сүз әйтмәслек итеп кисәтергә тиешле. Килен дә чукып торучы кайнигәчкә бирешмәсен. Ир дә үз хатынын апасыннан сакласын. Каенсеңелгә килен үз сеңлесенә караган кебек карасын. Шул вакытта каенсеңел дә җиңги дип кенә торачак, чөнки каенсеңелләр усал булмыйлар. Садретдинның сеңлесе Садретдин хатыны сыман юлбарыска да җиңги дип кенә тора. Садретдин чыгырдан чыгып хатынына чыбыркы белән кизәнгәч, аның сеңлесе җиңгәсе белән икәүләп Садретдинны бәйләп куйганнарын бөтен авыл белә.

Алтынчы ыстатия

Кем ул кайнана? Бөтен кеше өчен бик күркәм, бик кадерле хатын-кыз. Бик күп киленнәр өчен бигүк күркәм булмаган җан иясе. Мин әллә безнең татар киленнәре өчен генә шундый микән каенана дип йөри идем, түгел икән. Барча халыкларның киленнәре дә өнәп бетерми икән кайнананы. Мин Әмрикәгә барышлый папуас дигән халык яши торган җиргә тукталган идем. Шунда бер папуас килене әйтә: минем абирабураны үзегез белән алып китмәссез микән ди. Абирабура — аларча каенана дигән сүз икән. Кара син аларны, сүзен дә уйлап тапканнар — абирабура. Бездәге убырлы дигән сүз дә бар шикелле, бур дигәне дә бар. Мондый ямьсез сүзне киленнәр спитсеялне кайнаналар өчен генә уйлап табалардыр. Шул папуас килене оят җирен яфрак белән генә каплаган — үзе нәрсә ди: абирабураны алып кит, имеш. Алып китеп кая куйыйм ди мин аңы. Бездә үзебездә абирабуралар беткәнме. Садретдин хатынының кайнанасы үзе генә дә ни тора.

Менә инде шуларны әйткәннән соң кайнаналар турындагы ыстатияне бөтен халыкларга яраклы итеп язарга кирәк. Иң беренчесе шулай булырга тиеш: өйгә килен төшкәч кайнана үзенең түрдән төшкәнен аңласын. Түргә менгәндә дә күркә кебек күперенеп, кабарынып менмәсен, сакланыбрак, караныбрак менеп утырсын. Хәзерге заманда бигрәк тә. Хәзерге заман киленнәре үзләреннән гайре бүтән берәүне дә яратмыйлар. Ә аларны акылга утыртырлык ирләр бүген юк. Напримир, Садретдин ни әйтә ала хатынына? Әйтеп карасын. Ул хатын Садретдинны сүтеп җыйганны, аның әнисен сүтеп җыймыймы? Җыя. Әле җитмәсә, җыйганда кайбер зәпчәсләрне куймый калуы да ихтимал.

Кайнана, эчендә арысланнар көтүе уласа да, киленгә елмаеп карарга тиеш. Өй эчендә, ишегалдында, бигрәк тә кухня дигән җирдә кара-каршы очрашмаска тырышсын. Киленнең тозсыз ашын чыраен сытмый гына ашасын. Әгәр дә ир кеше хатынына "бу аш тозсыз булган" дисә, ирнең анасы, ягъни мәсәлән, каенана "юкны сөйләмә, бик тәмле булган" дип әйтсен. Көтүне кайнана үзе кусын. Киленнәр йокларга яратучан булалар. Аларның чөнки дә төнлә йокылары туймый. Чөнки дә алар ир куенында яталар. Ир куенында йоклап булмый ул. Ә кайнанага нәрсә — йоклаган карты янында йоклый инде ул. Шуңарга күрә йокысы туя. Кайнана урамга чыгып киленен хурлап йөрмәсен. Киленен бүтәннәр хурлаганда да якласын. Әгәренки хатын ирен тирги икән, кайнана малае ягында булмасын, килен ягында булсын.

Кайнана кайчандыр килен булган кеше бит. Килен чагындагы үз кайнанасының ачуын килененнән алмасын.

Кайнана үз улына әни дә бит әле. Менә шул: улы өйләнгәч әни икәнлеген онытсын. Белсен — малае аныкы түгел инде. Теге пумала баш киленнеке малае. Башы-аягы белән аныкы. Кайнаналарның иң зур ялгышы — өйләнгән улын үзенеке дип уйлау. Өйләнгән малай — төшеп калган акча белән бер. Тапкан кеше беркайчан да аны хуҗасына бирми.

Кайнана турында ыстатияне язып бетереп булмый. Депутатлар арасында абирабуралар бардыр — алар өстәсеннәр төшеп калган нәрсәләрне.

Җиденче ыстатия

Килендәш кем? Ике агай-эненең хатыннары. Әгәренки баҗайлар бертуган агай-энеләр кебек дус булса, килендәшләр алай түгел. Аларның һәрберсе, мин әйбәтрәк, дип уйлый. Уйлап кына калмый, сөйләп тә йөри әле. Ул үз иренә килендәшен гел яманлап сөйләүчән була. Килендәшнең бәхетле чагы: агай-энеләрнең талашкан чагы. Шуңа күрә ул үз ирен гел өстереп кенә тора. Шуларны белгәч закунда язылсын: хатын сүзенә карап үз браты белән талашкан иргә ыштыраф салырга. Шул ыштырафны ирдән түгел, хатынынннан түләтергә. Әгәр дә ирнең хатыны әйтә икән: "Ник син генә карарга тиеш әниеңне, абыең белән энекәшеңнең дә әнисе бит ул", — дисә, "Минем әнием миңа берәү генә, калганнарда эшем юк", — дип әйтергә. Шуннан соң да хатының аңламаса, үзең чамала инде. Әмма дә ләкин братыңа барып бәйләнмә. Чөнки дә братыңның хатыны синең хатыныңнан юаш түгел. Әгәр дә килендәшләр талаша икән, моңа алар гаепле түгел, аларның ирләре гаепле. Димәк ки, алар бозаулар.

Сигезенче ыстатия

Гаиләдәге гауга. Нәрсә ул гауга? Гауга ул минем кебек укымышлылар әйтә торган сүз. Прастуй халык телендә ул төрлечә әйтелә. Талашу да диләр, ызгышу, тиргәү, әйткәләшү, әрепләшү, табак-савыт шалтырату, тәмсезләшү, шаулап алу, чәкәләшү дә диләр. Гаугасыз, тыныч кына гел үбешеп, ялашып кына яшәгән гаиләләр юктыр һәм дә ки ул була да алмый. Әгәренки ир белән хатын шыпырт кына яшиләр икән, алар, димәк ки, бигүк нормальный түгел. Аларны гаилә дип атап бергә яшәтергә микән, ул хакта бик ныклап уйларга кирәк. Чөнки дә хатын-кыз вапшым гаугасыз яши алмый. Кыткылдамаган тавык йомырка салмаган кебек.

Әмма дә ләкин гауга белән гауга арасында аерма бар. Менә шуны бик ныклап закунда язып чыгарга кирәк. Әгәренки ир хатынына "җылан" дип, хатын иренә "сарык" дип әйтә икән, бу әйткәләшү була. Моңа бик

искитеп карарга ярамый. Ир белән хатын димәк ки берберсенең кем икәнлекләрен яхшы беләләр. Кешенең ниндие юк та сарыкның ниндие юк. Уйлабрак карасаң, җыланның да агуы даруга ярый. Әнә Садретдинның хатыны Садретдинга "дуңгыз" ди. Садретдинның ачуы киләме? Юк. Чөнки ул үзенең дуңгыз икәнлеген белә. Белгәчтен нигә хатынын ачулансын.

Әгәренки инде хатын, сез нәселегез белән — хайван, дисә, бусы — куркыныч. Бу инде чынлап та талашу була. Монда боларны нимидленне аерырга кирәк. Үзегез уйлап карагыз. Әгәр дә Җомабикә миңа "нәселегез белән хайван" дисә, минем нәселнең кая барып чыкканын беләсеңме? Атабыз Адәмгә барып җитә. Атабыз Адәм дә хайван булып чыгамы? Шалиш! Мине дуңгыз диген, ишәк диген, ну атабыз Адәмгә тимә. Вапшим әрепләшкәндә хайван дигән сүзне әйтмәскә. Канкрит итеп әйт, йә дуңгыз диген, йә ишәк диген. Ату миңа "хайван" дисәләр, мин кайсы хайван икән, дип баш ватып йөрергә тиеш. Ни чуртыма миңа хатын аркасында баш ватып йөрергә. Баш ватар нәрсәләр болай да җитәрлек.

"Табак-савыт шалтырау" дип юк өчен гаугалашып алуны әйтергә кирәк. Әйтик, например, Садертдин Вәлиәхмәт хатынының итәгенә карап калган ди. Шуның өчен Садертдингә хатыны: "Нәрсә, оятсыз, мин генә җитмиммени сиңа?" дип әйтте ди. Шуннан Садретдин: "Җитәсең, җаным, артып та каласың әле. Калганын кая куярга белмим", — дигәч, хатыны Садретдинга: "Өйгә генә кайт әле, сүтеп җыям мин сине", — дип куркыта ди. Монысы инде менә табак-савыт шалтырап алу гына була. Чөнки дә сүтеп җыям дип болай гына әйтә Садретдин хатыны. Чөнки дә белә ул — Садретдинны сүтсәң, җыеп булмый. Бөтен шистирнәләре ашалып беткән. Мондый гаиләләргә тияргә ярамый. Чурту матыр, яшәсеннәр үзләренчә.

"Авылда бер дигән кыз идем, сиңа кияүгә чыгып кына әрәм булдым", — дип әйтелгән сүзне дә талашуга кертмәскә. Чөнки дә бу сүзне хатыннарның туксан тугыз прасинты әйтә. Даже Садретдинның хатыны да "мин капитализым оныгы идем, сатсализм кызы идем, коммунизымның килене булырга тиеш идем, синең аркада гына димакрития булдым" дип әйтә икән, дөрес әйтә. Садретдин булмаса, аңарга кияүгә чыкмаса, берәр мафиягә кияүгә чыкса, Садретдин хатыны кәнишне, каммунизм килене була иде.

Чәкәләшеп алу да кирәк гаиләдә. Чәкәләшеп аласың да — ут чыга, икең дә кызып китәсең. Кызган хутта кочаклап аласың. Хатын "кит, мин сине яратмыйм" дигән була, син китмисең. Иртәгесен хатының сине мактап сөйли: "Минеке кебек ир дөнья йөзләрендә юк", — дигән була.

Вапшым әйткәндә, болай: нәселне тикшермәгәндә, бүтән гауга өчен ир белән хатын арасына кермәскә: әйтешсеннәр, әрепләшсеннәр и таки далие.

Хатыннарны нисинзурный сүз әйтеп сүгү катигарически тыела. Хатыннарны сүккәндә иң каты сүз "Их, син!" дигән сүздән узмаска тиеш. Артыгын әйтә күрмәгез, хужы булачак. Хатыннарга яратып әйтелгән сүз дә чамалы булсын. Әгәренки син хатыныңа "сандугачым" дип әйтәсең икән, ул ышанмаячак. "Бу март мәчесе кайдадыр өстерәлеп кайтты ахры, теле бигрәк төче" дип уйлаячак. Иң әйбәте — гаебең булса, үзенә бәйлән. "Самый лушчий абаруна — эты нападиние", — дия иде минем дустым маршал Жуков.

Әгәренки тел кычытып тиргәшеп аласылары килсә, ир белән хатын алдан сөйләшеп куйсыннар. Син фәлән кадәр сүз әйтәсең, мин фәлән кадәр, диешсеннәр. Ирнең бер сүзенә хатыны егерме сүздән дә артыгын әйтмәсен. Вапшым, әрепләшкәндә ярты сәгатьтән артык әрепләшүне рөхсәт итмәскә. Ярты сәгать эчендә дөньядагы бөтен ямьсез сүзләрне әйтешеп бетерергә була. Үзем тыңлап тордым: Садретдин хатыны белән ызгышканда Садретдин хатыны бер минут эчендә дөньядагы бөтен хайван һәм дә бөтен збир исемнәрен әйтеп бетерде. Садретдин нибарысы "кубра" дигәнне генә әйтеп өлгерде. Әйтеп өлгерсә дә хатыны кубраның ни икәнен аңламады. Шуңа күрә әйтешкәндә берең аңламаган сүзне икенчең әйтмәсен. Беткәнмени үзебездәге збирләр.

Тугызынчы ыстатия

Ничә яшьтә өйләнергә һәм дә ки ничә яшьтә кияүгә чыгарга? Хәзерге яшьләрне 25 яшьтән дә иртә өйләндерергә ярамый. Әнә Садретдиннең малае — үзенә инде утыз яшь, үзе балалыктан чыгып җитмәгән. Каз сугыштырып йөри бит, күсәк. Аның яшендә без самалютка пич чыгарып, патша төшереп, Бладимир Илич Лилин белән бер кәбиниттә бергә утырып эшләдек. Ә бу җыламыйча ашый да алмый. Хәер, ул үзе дә әле өйләнергә җыенмый. Аның ише күсәкләр авыл тулы. Кырыкка җиткәннәре бар араларында. Көтүләре белән җыелышып эчеп йөриләр. Өйләнү уйларында да юк. Сорыйм бервакыт шуларның берсеннән: "Нигә өйләнмисең?" — дип. "Нәрсәгә кирәк ул миңа?" — ди. "Хатын нәрсәгә кирәклеген дә белмисеңмени?" — дим. "Син беләсеңме соң?" — ди бу миңа. "Беләм, кәнишне", — дим. "Белсәң, тагын бер өйлән", — ди. Күрдегезме? Теле бар, ние юк.

Шулай. Егерме бишкә хәтле өйләндерергә кирәкми. Егерме биштән калдырырга да кирәкми рәтле егетләрне. Юкса алар рәтсезләргә ияреп, нәсел калдырырга яраксыз булалар. Кызларны кияүгә биргәндә егермедән уздырмаска. Чөнки дә егермедән узган кызлар карап-карап йөри дә "рәтле ир юк икән бу дөньяда" дип кияүгә чыкмый кала.

Уныньчы ыстатия

Ничә хатын алырга? Хатыны хатын ише булса, берәү җитә. Хатыны хатын ише булмаса, унны алсаң да тулк юк. Ире ир ише булса, ун хатынны да хатын итеп тота ала, ире ир ише булмаса, бер хатын да әрәм. Шуннан чыгып инде, ягъни мәсәлән, нәрсә килеп чыга инде. Әгәр дә ир буласы кеше җирле үзидарәдән "фәләнфәлән фамилияле кеше икеме-өчме, бишме-унмы хатынны ашатып-киендереп тота ала" дигән ысправкы алып килсә, аңа теләгәнчә хатын алырга рөхсәт итәргә. Тик шунысы да булсын — күп хатынга өйләнәсе ир беренче хатыныннан да ысправка алсын. "Мин фәлән-

фәләннең фәлән исемле хатыны фәләнгә икенче хатынга өйләнергә рөхсәт бирәм. Чөнки дә минем иремә мин генә җитмим. Төнлә йокларга ирек бирми, шуңа күрә йокым туймый кала. Иремнең икенче хатынына кирәкмәгән сүз әйтеп ачуын китермәскә, талаш чыгармаска сүз бирәм. Әгәр дә иремнең икенче хатыны тавыш чыгарса, телемне тешләп калырга, каршы сүз әйтмәскә сүз бирәм". Менә шундый ысправкысы булсын өйләнәсе ирнең. Әгәренки ике хатын ире өченче хатынга өйләнергә җыенса, алдагы ике хатыны бергәләп язарга тиешләр ысправкыны. Әгәр дә ир дүртенчемеунынчымыга өйләнергә җыенса, бөтен хатыннары бергә җыелып язсыннар ысправкыны.

Хатын өстенә чыгасы "хатыннар да" иремнең миннән алдагы хатыннарына притинзем юк дигән расписки язып загыска бирергә тиешләр. Соңынтын үзеннән алдагыларны гаепләп шыңгырдап йөрмәсен. Бер хатынлы ирләргә хатыныннан аерылырга рөхсәт ителсә дә, күп хатынлы ирләргә хатын аерырга һәм дә ки үзенә аерылырга рөхсәт ителмәсен. Нәфесеңне тыя алмыйча өйләндеңме — яшә.

Ирләр белән хатыннар тигез булырга тиеш, дип әйтәбез икән, хатыннарга да ике-өч-дүрт ир белән язылышып торырга рөхсәт ителсен. Хәзергесе заманда бу нәрсә бигрәк тә кирәк, чөнки дә үз тамакларын үзләре туйдыра алмаучы ир дип аталган бәндәләр күбәйгәннән-күбәя бара. Аларны хатыннары ашатмый кем ашатсын. Ашату гына түгел эчертәсе дә бар бит әле. Садретдинга әләгә миннән әләгүен дә, ул әле, ни әйтсәң дә, үзен ашатырлык ризык таба. Аңардан хуҗылар да бар шул. Шунысын бик ачык итеп әйтергә кирәк закунда: әгәр дә берәр хатын күп ир дип аталган җан ияләрен үз янына алып закунный иргә санарга тели икән, загыска барганда "мин фәлән-фәләннәрне тәрбиягә алам. Аларны ашатып-эчертеп торырга сүз бирәм" дип расписки язсын. Теге хатынга кияүгә чыгарга җыенучы ир имгәкләре "мин ир дигән исемнән отказ бирәм. Мине алган хатын мине ир дип санамасын. Яхшы ашатса, айгыр йә үгез булып кына яшәргә риза" дигән язу язып бирсен.

Унберенче ыстатия

Кем фамилиясен алырга? Бу ыстатиянең кирәге юк сыман кайбер татарларга. Андыйларга эт фамилиясе кушсаң да барыбер. Садертдиннан сора син фамилиясен — белми дә ул аны. Чөнки дә кирәкми ул аңа. "Сат фамилияңне бер яртыга" дисәң, сатып та җибәрә. "Хатының фамилиясенә күч" дисәң, күчә. Мондыйларга закун да юк, чурт та юк. Ну барыбер закунсыз ярамый. Әлегә татарда ирләр бетмәгән. Шуңа күрә закунда язарга: ирләр фамилиясе главный булырга тиеш. Йортка керүчеләрне генә хатын исеменә күчерергә. Мин исеменә дип ялгыш язмадым. Йортка кергән иргә хатынның фамилиясен дә бирмәскә, исемен генә бирергә. Напримир, Гәптриев Садретдин дигән кеше Габдрахманова Миннебикәгә кияүгә чыга икән, Садретдинга Миннебикәева дигән фамилия бирергә. Авыл җирендә тегеләй-болай сөйләшкәндә, Миннебикәнең сарыгы, дип дәшәргә. Бетте-китте, вәссәлам.

Уникенче ыстатия

Мал бүлешү. Бу ыстатияне язганда бик нервыландым. Кеше дигән нәмәрсәнең бөтен әшәкелеге чөнки дә мал бүлешкәндә өскә калкып чыга. Карап торасың — ярыйсы гына ир кебек күренә, хатыны да ыспай, теле дә тәмле сыман. Аерылышып мал бүлешергә тотыналар — берсе иблис, икенчесе шайтанга әйләнә дә куя. Ну, өйләнешкәндә җаный да җаный булып, яши башлагач барып чыкмады дип тормыйсың, кит икең ике якка матур гына. Юк бит, тотыналар бер пар галушны икегә бүлергә. Нишләп беттеләр Хәтимә белән Хәлиулла? Бер җәбе сынык сәнәк өчен сәнәккә сәнәк килделәр. Шуңа күрә дә закунда тегеләй дигән булып, болай дигән булып болгатмаска, турыдан-туры язарга: әгәр дә ир белән хатын аерылыша икән, иренә өстенә кигән киемен, хатынына өстенә киенгән киемен генә бирергә дә калганын балаларына бирергә. Яши белмәдеңме, яши алмадыңмы, бала үрчеттеңме, бүт дубыр, балаларың хәерче булмасын.Үзең теләсәң нишлә.

Унөченче ыстатия

Йортка керү. Әгәренки дә бер татар кешесе андамонда буталып йөрепме, йә булмаса бүтәнчәме, язылышкач хатынының өенә йортка керә икән, аны ярты ир дип кенә санарга. Үзенә бер куыш та коралмаган бәндә ир буламы? Әгәр дә өйләнгәндә торыр урын булмаса, йә өйләнмәсен, яки дә инде өйләнсә, өйләнәсе кызына әйтсен: "Мин синең өеңә күчмим, мине бик яратсаң, минем белән урамда яшә", — дисен. Риза булса була, булмаса чурту матыр. Хәйбулла исемле бер зимагур безнең авылның бер хатынына йортка керде, әйеме. Аны бер кем дә иргә санамады. Хәтта ки Садретдин да аның белән бергә аракы эчмәде. Маладис, Садретдин! Минем үземне дә Җомабикә җиңгәгезгә өйләндергәндә Казан баеның алты ятажлы хан сараенда яшәрсез диделәр. Мин әйттем — яшәмим, дидем. Һәм яшәмәдем. Үзем салган өйдә Җомабикә апагыз белән дөбердәтеп яшибез. Җомабикә җиңгәгез кайчакларда мине эт итеп сүгә, әллә ниләр әйтеп бетерә. Әмма дә ләкин: "Син үзеңә мүкле абзар да сала алмадың бит, мәхлүк", — дип әйтә алмый.

Өйләнгәч йортка кергән урысмы, йә булмаса бүтән халык җегетеме, хатыны өендә хатынның әнисенә "Тюша! Тюша!" дип әйтә икән, әйтсен. Аларда шулай тиеш. Әгәренки татарның җегет кисәге марҗага йортка кереп "тюша, тюша!" дип йөри икән, йөрсен. Тик аның ише кешеләрне өйләнде дип әйтмәскә, кияүгә чыкты дип тә әйтмәскә, "замуж вышел" диярргә кирәк.

Вапшым болай: әгәренки татар малае татар кызының өенә йортка керергә җыена икән, языльштырмаска. Гаилә дигән исем күтәреп йөрмәсен. Бик җиңел генә яшәмәкче булалар кайбер малайлар. Ишек тә хатыннан, тегесе дә хатыннан. Алай булмый ул, бырат.

Унҗиденче ыстатия

Кем баласы? Ир белән хатын балалары тугачтын ук баланың кем ягына тартканын тикшерергә тотыналар. Хатын-кызга бала кемгә ошаса да барыбер. Үз баласы икәнлеген белә ич инде ул. Менә ирләр төпченә. Көнләшә торганнары бигрәк тә. Карый — миңа ошаганмы, күршегәме? Әллә инде калхуз придсидәтеленәме. Шикләнсә, бәйләнә башлый хатынга. Хатын җылый. Симия таркала. Үзегез дә беләсез, Хәмдебануның кызы Казаннан нигыр малае күтәреп кайтты. Ире күтәрелеп бәрелгән ди. Ичмасам урыска ошаган булса да ярарые, дип үкергән ди дә, куып җибәргән ди Хәмдебану кызын. Кыз әйтә ди, валлаһи бер гөнаһым да юк, дип әйтә ди. Әниемнән ничек тудым, шул килеш чыктым кияүгә, кияүгә чыккач та иремнән башка кешегә күтәрелеп тә карамадым, дип әйтә ди. Ире әйтә ди, күтәрелеп карамаган шул, күтәрелеп караса, өстенә нигыр ятканын күргән булыр иде, дип әйтә ди. Шуннан ни булды дисезме? Алып китте бит ире Хәмдебану кызын баласыние белән. Болай булган. Ирнең әнисе заманында бер нигыр белән гүләйт иткән булган икән. Шул нигырдан шушы ир туган. Ак булып туган тууын да, әмма дә ләкин канына нигырның каны да күчеп калган. Менә шул кан Хәмдебану кызы малаена күбрәк эләккән дә, малай нигыр булып туган. Вәт сезгә кәнсәләрия.

Садретдин нишләп йөрде теге чакта. Малай минеке түгел, дигән булып. Безнең нәселнең борыны тукмак кебек, ә бу курнус борынлы дип. Ярый әле хатыны әтчәйни. Әйткән Садретдингә. Күрсәткән Садретдинга малаеның Садретдинга ошаган җирен. Шып булган Садретдин.

Шуңарга күрә закунны бу турыда нык язарга кирәк. Ирләр шыңгырдап йөрерлек булмасын. Раз синең законный хатының икән, ошаганмы, ошамаганмы — тавыш куптарма. Дажы малаең үзеңә йөз прасинты белән ошамаса да шыңгырдама. Син дулап кына малаеңның җирән чәче каралыр дип уйлыйсыңмы? Бу ыстатия өчен ирләр мине кәнишне сүгәрләр, безнең хатыннарны аздыра, диярләр. Бик кирәге бар хатыннарыгызның, минем үз Җомабикәм яшәсен. Җыен юк-бар белән хатыннарыгызга бәйләнмәгез. Әгәр бик суръезный икән инде, тавышсыз гына әйт хатыныңа "Сау бул, җаным бәгырем" диген. Вәт булырсың ир кеше.

Вапшым, малай синеке, бырат. Минеке түгел, дип үзеңнән көлдереп йөрмә.

Унбишенче ыстатия

Сөяркә. Бу ыстатияны укып чыккач, бик күпне белүче Вәлиәхмәт каршы чыгар иде. "Гаилә турында закунга сөяркә сыймый", — дияр. Ә мин әйтәм: "Шулаен шулай да, әмма дә ләкин бар бит ул дим. Әби патша заманыннан ук сөяркәләр булган, әллә кем патша булса да сөяркә булачак. Праблима шунда гына — закунның кайсы җиренә кыстырырга сөяркәне? Закунный хатын янына куярга да ярамый. Читкә чыгарыең, гаиләгә касаниясе бар сыман. Инде аңардан котылып булмый икән, болай итик: Сөяркә хатынның да, бүтәннәрнең дә күзенә бәрелеп тормаска тиеш. Сөяркә белән күрешү анда бер, монда бер йөз гырам канияк эчеп куйган кебек кенә булсын. Әз-мәз генә башка да китә, әз-мәз генә исе дә килеп тора, хатын да эчеп кайткансың, сабакы, дип артык ачуланмый. Күз кырые белән карап кына ала да, "ярый инде, болай гына булгач", дип ирне прашшайт итә. Аннары шунысы — ирләр сөяркәне хатынын уважайт иткән кебек уважайт итәргә тиеш.

Сөяркә аркасында гаилә бозып, тавыш чыгарып йөрерлек булса, андый иргә сөяркә әрәм. Бии белмисең икән, чыкма биергә кеше көлдереп. Шундый бул — әгәр дә хатыныңны "иреңнең сөяркәсе бар" дип котырталар икән, "әллә минем ирем бүтәннәрдән кимме?" дип әйтерлек булсын хатының. Вапшым, сөяркә ул бернинди закунга да сыймый торган, бөтен халыкларда да борын заманда ук булган һәм дә булачак гыйшык-мыйшык җимеше. Закунда да шулай каралсын.

Уналтынчы ыстатия

Бу закун призинт кул куйган көннән галәмгә керә. Галәмгә керә дигән сүзне дөрес итеп язмадым бугай. Галәм дә сыман, гамәл дә сыман, колакта калган. Гаеп итмәссез. Төзәтеп язучылар бардыр әле Гассавиттә.

Закунны язды: Минһаҗ Габсаматов

Дәфтәрне укып чыккач, Садретдин тузынырга тотынды.

— Түздем, түздем, бу юлы мине мыскыл иткәне өчен күрмәгәнен күрсәтәм мин Минһаҗга, — дип Минһаҗ абзыйларга китте. Ни булыр икән, дип без дә аңа иярдек.

Минһаҗ абзый капка төпләрендә "Бер адым алга, ике адым артка" дигән китап укып утыра иде.

— Укыдыгызмы закунны? — дип сорады Минһаҗ абзый.

— Укуын укудык та, син нигә гел миннән көләсең? Закун түгел бу — чипуха. Мин барыбер буйсынмыйм бу закуныңа, — диде Садретдин.

— Яле, бирегез әле, — дип Минһаҗ абзый закон язылган дәфтәрне бездән алды да кулындагы каләме белән шул дәфтәргә нидер язып: "Мәгез укыгыз әле", — диде.

Без закунга өстәп язылган сүзләрне укыдык

"Уналтынчы ыстатия

Бу закунны язган кешене мыскыл итүче җүнсез бәндә табылса, аны ирләр арасында йөртмәскә" дип язып куелган иде.

— Законда аерылышу турында ыстатия юк, — дигән иде Вәлиәхмәт абзый:

— Аерылышу бу закунга керми. Аерылгач гаилә бетә, гаилә беткәч бу закун ниемә, — диде Минһаҗ абзый, — вапшым язылган закун буенча гына яшәргә тырышкан гаиләнең дә поты бер тиен. Язылмаган закуннар бар, чисталык, тугрылык бар — шулар буенча яшәсен адәм балалары, — дип тә өстәп куйды.

Марат ЗАКИР

Яңгырда

...Тыңлама тамчылар сәгатен —
Бер юкка тып та тып санийлар.
Бу назлы язгы җил бары тик,
Бары тик мин киткәч зар елар.

Тыңлама тамчылар сәгатен —
Бер юкка тып та тып сынийлар.
Бу сабыр көзге җил бары тик,
Бары тик син киткәч зар елар.

Тыңласаң тамчылар сәгатен,
Тыңла син — тик аннан ни мәгънә?!
Бу язда, бу көздә барыбер
Мин Мәҗнүн булырмын, син — Ләйлә!

Бу язда, бу көздә барыбер
Тамчылар сулышы яңгырар!
Бу язда — бу көздә тик безгә
Дип кенә яварлар яңгырлар.

Тик безгә дип кенә килде ул —
Дәрьяда тибрәнер мизгелләр!
Ак көмеш чатырда саташып,
Сокланып көлделәр көзгеләр.

Һич сүнмәс бу яңгыр...
Сүнмәсен!
Дөрләсен бу яңгыр, дөрләсен!
Бер ярсыз ДӘРЬЯСУ — Алкын су
Тибрәтер мәңгегә безне дә.

Мәйсәрә ЯКУПОВА

Мәйсәрә апа сагышлы, моңлы чакларында җырлар чыгара, сүзләрен дә, көен дә үзе яза.

* * *

Иртә торып тышка чыксам,
Үлән үсә дым белән.
Үләннәр үсә дым белән,
Гомерем үтә моң белән.

* * *

Җем-җем кара чәчләремне
Тарыймын, үрәлмимен.
Эчемдәге янган утны
Беркем дә белә алмыйдыр.

Аккош күле, 1991 ел

Гәүһәрия САФИНА-КӘРИМУЛЛИНА

Көз

Агачлардан тибрәлеп
Яфраклар коела.
Алар да җылы якка
Очадыр күк тоела.

Кукмараның 1 нче урта мәктәбе.
1956 ел

Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА

* * *

Китеп барыш инде.
Китеп барыш.
Җанда әрнү,
Җанда ачы сагыш.
Котылмакчы булып бу халәттән,
Вәгъдәләрдән, сөю, хыянәттән
Китеп барыш инде,
Китеп барыш.
Көтмим куа чыгучыны арттан,
Исмәсен җил миңа каршы яктан,
Очрамасын юлда бер тукталыш,
Китеп барыш бит бу,
Китеп барыш.
Белсәң иде алда ниләр көтә,
Күңел — тиле, бәхет өмет итә.
Ник бу кадәр аяусыз син, язмыш?
Китеп барыш инде,
Китеп барыш.

Нәгыйм ШАҺИ

Яз шаукымы кагылганда

Әкрен искән яз җиленнән
Синең хәлеңне сорыйм.
Йомшак җил битемнән үпсә,
Синең сәлам дип уйлыйм.

Тирәгемдә кошлар сайраганда
Мин дә кушылып җырлыйм.
Чын йөрәктән өзелеп җырлыйм,
Син тыңлыйдыр дип уйлыйм.

Бар гүзәллек, дөнья яме
Синнән килә дип уйлыйм.
Ул да мине сагына дигән
Татлы уйдан мин туймыйм.

Зур Чынлы авылы 8 б сыйныф укучысы.
1975 ел

Рашат НИЗАМИ

Яшел күзле малай

Җәйне яратканга күрә
Күзләре яшел иде.
Чирәмлектә уйный-уйный
Тезләре яшел иде.

Суларга карап бакты ул,
Күкләргә карап бакты.
Җаны чиста булгангамы,
Дөньялар — гаҗәп якты!

Яфрактан-яфракка тамган
Түгәрәк тамчы кебек,
Бөреләнде күңелендә
Түгәрәк кенә өмет.

Шул өмете коймалардан
йолдызга кадәр чөйде, —
Чөнки күршедәге йортка
Кунак кыз килгән иде.

Аның бантиклы чәчләрен
Тотып карыйсы килде.
Күбәләктәй чәчтасмасын
сүтеп карыйсы килде.

Әллә ни булды малайга —
Үзгәреп китте кинәт.
Канатлы йолдыз җилләре
кагылган аңа, димәк!

Койма ярыгыннан кызны
Көн саен күреп алды.
Кунак кызның елмаюын
Курайга төреп салды.

"Яшел" иде мәхәббәте,
Күзләре яшел иде.
Әйтер сүзе, әкият булып,
Курайга яшеренде.

Солтан ШӘМСИ

Иблис кубызына

Ничә тәүлек котырына
Апрель кергәч ак бураннар,
Ни арада үзгәрде соң
Гөрләвекле бу урамнар?

Урам түгел, заманның да
Бу мәхшәрдән төсе качкан,
Күз иярми пейзажларга,
Иблис көлә, авызын ачкан.

Ул йотмакчы була инде,
Ымсындырып данга, малга:
"Дөньялыкта шөһрәт алу
Сезгә йола булып калган".

Ул аркаңнан сөя синең,
Хуплый шулай, юл яздыра.
Туктамасын, уйланмасын,
Мактыйм әле, дип аздыра.

Кил аңыңа, адәми зат!
Биемә Иблис кубызына.
Күңел түрендәге Җанның
Колак салчы авазына.

1997 ел,
9 апрель

Рәфикъ ЮНЫС

* * *

Күпме таңны юлда каршыладым.
Күпме йөзләр үтте каршымнан.
Мин эзләдем сине еллар буе.
Син юк, ахры, безнең гасырда.

Киләчәктә, димәк, туырсың син.
Бүтән җилләр бәрлер кыяга.
Минем кебек ялгыз булырсың син
Кеше белән тулы дөньяда.

Көзге җилләр кебек ачы сагыш
Ерак йолдызлардан эзләтер.
Очратмассың мине. Аклың инде
"Галәмдә ул юк шул!" — дип әйтер.

Син эзләрсең. Минем сурәт чагылыр
Болытларда, зәңгәр көртләрдә.
Күрәсеңме, сиңа еллар аша
Кулларымны сузам үткәннән.

Үзем җитә алмасам да, сине
Шигырьләрем, бәлки, табар бер.
Сине сагну тулы бу юлларга
Кайнар яшең, бәлки, тамар бер...

1976

Нәбирә Гыйматдинова.

Син дә сәрхүшме, татар хатыны
1995, №2.

Җәйге төн. Авыл изрәп йоклый. Тик зәңгәр капкалы йортта гына халык уяу. Ачылмалы тәрәзәдән ургылган җыр тып-тын урамнарга тарала. Мәҗлес гөрли. Нәзек кенә тавыш белән хатыннар җырлый. Безнең татар хатыннары. Ирләр кушылмый (татар ире җырларга иренә ул).

Әптер-сиптер, корчаңгы,
Сат бәрәңге бакчаңны.
Сатсаң бәрәңге бакчаңны —
Бергә эчәрбез акчаңны...

...Күпме генә тыңласам да, бүтәен эчтәлектәге җыр (әйтик сандугачлар турында, мәхәббәт турында) ишетмәдем. Эчү-салуны сәнгать дәрәҗәсенә күтәреп, мактап җырлый татар хатыны, димәк безнең милләтнең рухи хәзинәсе "баеган": тулы бер "аракы фольклоры жанры" үсеп чыккан. Димәк, эчеп кенә күрсәтми инде сылукайларыбыз, "эшен" көйгә салып та раслый. Шәһәр шәһәр дибез тагы, ул кызларыбызны җыеп боздыра, дип аны яманлыйбыз, баксаң әхлагыбыз көзгесе — татар авыллары, ташкалалардан да уздырып типтереп ята лабаса. Бүген анда озын муенлы шешә кадерле кунак, аерылмас дус, самавырдан алда "күзләрен җемелдәтеп" өстәлгә ул менеп кунаклый! Элек аракы табынында утыруны да гөнаһ санаган татар кызы, татар хатыны аны җырлый-җырлый, бии-бии эчә. Кыстатыш юк, ялындырыш юк. Хөррият, азатлык, тигезлек. Ирләр белән рәхәтләнеп чәкештер! Ак яулыклы әбиләребезгә хәтле бүтән безнең. Осталыкка махсус курсларда укыганнар диярсең, көмешкәне менә дигән итеп ясап бирәләр. Марҗа түтиләр көнләшерлек. Юри генә тикшерегез: сезнең авылда да самогон куучы яки биш бәягә аракы сатып көн күрүче әбиапалар бар. "Лавка" бикләнми, тәүлек буе эшли, рәхим итеп, теләсә кайсы вакытта тәрәзәсенә чиерт...

...Мондый мисалларның иге-чиге юк. Парлашып эчәләр, ир дәвалана, котыла, ә хатын упкынга егыла. Менә сиңа "әптер-сиптер, корчаңгы!.."

...Коточкыч зур фаҗига бу. Без аның асылына төшенеп, аңлап кына бетермибез бугай. Ирләрнең эчүе ярты бәла икән, хатын-кызның аракы дигән дәҗҗал белән әшнәлеге — бербөтен бәла. Җәмгыять әхлакый яктан кайчан таркалып бетә дисәләр, һич икеләнмичә, хатыннарыбыз эчүчелеккә сабышкач, дип җавап бирергә кирәктер мөгаен...

Без бүген ике шәхеснең, ике шагыйрьнең томаннар артында калган мәхәббәте турында тел тибрәтергә баздык. Аларның берсе — Хәсән Туфан, икенчесе — Клара Булатова...

Нәбирә Гыйматдинова.

Яратуның гөнаһысы юк.
1995, №3.

— ...Кыяр-кыймас кына, шигъри юлларда гына ачты Туфан күңел серен. Шигырьләр миңа аталган дип башта уема да кертмәдем. Белгәч, үземне иң бәхетле хатын-кыз итеп тойдым. Шушы олы хискә минем дә җавап бирәсем килә иде... Хәсән абый җитди сүзләрен, иҗатыма бәяләмәләрен гел проза белән яза, Клара дип, үзе белән тиң куеп яза иде. Ә мәхәббәтен аңлатырга керештеме, шигырьгә күчә. Ике кеше булып яшәде ул елларда шагыйрь. Аның берсе — аек акыллы, салкын канлы, философ Хәсән Туфан, икенчесе — дөньясын онытып гашыйк булган Искәндәр атлы ир...

— Күп кенә ирләр күз белән ярата, ягъни хатын-кызның тышкы кыяфәтенә кызыга, диләр.

— Ләкин ул "күпләр" белән Туфанны бутарга ярамый. Ул хатын-кызны гел күрми иде. Аһ биле, аһ күкрәге, дип шашмады. Ә бит бүген безнең ир-егетләребез, хатын-кызның исемен ишетүгә үк, аны күз алдына ялангач килеш китерәләр. Кай җирендә ничек икән дип.

— Күрәсең ул сезнең җаныгызны яраткандыр.

— Әйе, әйе, Хәсән абыйда тәнгә омтылыш юк иде, юк! Никахка хәтле хатын-кызга кул сузуны ул бозыклык дип санады. Шуңа күрә минем терсәгемә бармак белән дә кагылмады. Аларның фатирында кунган чаклар да бар иде юкса. Ә ул тән сыйпау турында әз генә дә хыялланмый иде. Безнең бөтен якынлык — күпердә икәү янәшә басып торудан гыйбарәт...

— Ул күпер дигәннәре бик кадерле бугай. Аны шигырьләре— гездә еш искә алгансыз.

— Университет студентлары тулай торагына илтүче күпер ул. Әле дә бәхетлеләр аның аша үтеп йөридер. Бер кичне Хәсән абый мине озата китте. Төн җиткән иде. Без күпердә туктап калдык. Салкын, ә минем өстә җиңел күлмәк кенә. Туңам, дерелдим билгеле. Туфан, аксыл соры костюмының бер очын иңемә япты да, кочаклап алды. Аңа сыенган килеш шигырьләр сөйләдем. Шул гына. Баксаң, күпердәге төн шагыйрьнең җанын актарган, кайту белән каләмгә ябышкан. Берничә көннән хат килә. Конверт эчендә "Күпердән кайткач" дигән өр-яңа шигырь!

...Шундый куллар бар иделәр
Чәчләр көрән чагында.
Давылларны кичкәч менә
Шундый куллар тагын да.
Нишләдең син, һәр ят кулны
Читләтүче йөрәгем?!
Синең кулларың, Тәнәкәй,
Чит кул түгел, күрәсең...

...Иртәгәсен без тагын очрашырга сүз куешкан идек, ләкин мин нигәдер бармадым. Моны Туфан үзен санламау дип аңлаган күрәсең, җаны бик җәрәхәтләнгән. Шуны белдереп, берьюлы 5 шигырен җибәргән. Укып чыккач, мәгънәсезлегемне аңлап еладым... Ак кәгазьдәге юлларда бәргәләнү, гаҗизлек, йөрәк ярасы — укыган кеше ничек шуларны күрмәсен ди!..

— Бер-берсен шул хәтле яраткан ике җан кавышып бергә гомер кичерергә тиеш кебек иде. Язмыш, сезне аерып, артык рәхимсез кыланган түгелме соң?

— Язмыш түгел, Туфанның дуслары аерды безне, Нәбирә. Хәсән абый мәхәббәткә артык сак карый иде. Ул сөйгән хатыны Луизаны югалтуларын кичереп, сөргеннән "кайсыгызның кулы җылы" дип кайткан яралы шагыйрь бит инде. Аңа бик тә җылы кул кирәк булган. Ул аны миннән табарга тырышкан һәм таптым дип ышанган да. Ләкин табып җиткермәгән...

Розалина
ШАҺИЕВА

"Борынгы Казан"



Н. Хаҗиахмәт рәсемнәре

"Борынгы Казан" — зур масштаблы беренче күргәзмә. Ул Казандагы һәм Казан Кремлендәге археологик тикшеренүләргә, Казан тарихы һәм мәдәниятенә караган материалларга, Русия һәм Татарстанның зур музей-саклагычларындагы коллекцияләргә нигезләнеп оештырылды. Күргәзмә X-XX гасырларны эченә алучы гаять зур хронологик чорның рухи-матди культурасын, шәһәр тарихын күз алдына бастыра.



Н. Кумысникова костюмнары

Күргәзмәдә Дәүләт Эрмитажы, Дәүләт Рус музее, Русия Этнография музее, Дәүләт Тарих музее, Дәүләт Третьяков галереясы, Татарстанның Берләштерелгән Дәүләт музее, Татарстанның Сынлы сәнгать музее, Казан дәүләт университеты музее һәм Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә, Татарстанның Милли китапханәсе, Татарстанның Милли архивы, Татарстанның Элемтә тарихы музее, "Туран" фонды, "Казан" милли-мәдәни үзәге каршындагы Милли мәдәният музее археологик материаллары, фәнни-антропологик һәм тарихи-мәдәни реконструкцияләр (элекке хәленә кайтарылган истәлекләр — ред.), архив материаллары, дәүләт актлары һәм документлары, ярлыклар, грамота, указлар, картография һәм архитектура һәйкәлләренең реконструкциясе, хәрби кием үрнәкләре, әдәбият һәм сәнгать истәлекләре, сәнгати-монументаль паннолар һәм фотоколлажлар, атаклы тарихи мәдәният истәлекләренең копияләре белән катнашалар.

Экспозициядә Казан Кремлендә археологик казынулар вакытында табылган истәлекләр — чех хакиме Вацлав тәңкәсе, X гасырның гарәп дирхәме, Эрмитаж коллекциясеннән X-XII йөзгә караган болгар көмеш савыт-сабасы, монголларга кадәрге чорга караган атаклы муенса (ТР Берләштерелгән музее), Казан ханы Сәхипгәрәйнең 1523 елгы ярлыгының төп нөсхәсе, углы Үтәмешгәрәй белән Сөембикәнең билгесез оста тасвирлаган портреты (XVI-XVII гасырлар), нумизмат коллекцияләре, уен кораллары үрнәкләре, Казан китапханәләрендә сакланучы борынгы кульъязмалар күрсәтелә.

Татар рәссамнары Ш.Шәйдуллин, Ф.Халиков, Р.Заһидуллин, И.Зарипов, К.Нәфиков, И.Рәфиковның тарихи картиналары меңьеллык Казанның җыелма тарихи-архитектур образын күз алдына бастыралар.

Экспозициядә шулай ук бүгенге казанлыларның ерак бабалары төзегән шәһәрләр (Фанагория, Биләр, Болгар) диорамалары да күренекле урынны алып тора.

Беренче тапкыр экспозициядә Казанны басып алуның фаҗигале вакыйгалары да тасвирлана.

Экспозициянең өченче катында Казан суверен. Татарстан башкаласы буларак күрсәтелә. "XX гасыр башы китапханәсе" блогыннан башлап 1990 еллар авангардына хәтле — заманча татар мәдәнияте-сәнгатенең морфологиясе (эчке төзелеше) аркылы яңа меңьеллык бусагасында Казаныбызның бөтен дөнья татарлары һәм бирердә яшәүче бар халыклар өчен куәтле рухи-мәдәни үзәк булуы ассызыклана.

Тышлыкның 3 битен карагыз.

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА

"Иремә тамга кирәк..."

Очрашуларга күп йөргәч, нәрсәләр генә ишетмисең икән. Янына килеп тә сөйлиләр, язып та җибәрәләр. Кайберләре елый-елый, кайберләре көлә-көлә сөйли. Әлеге вакыйганы да көлеп кенә бәян кылдылар. Саимә (исемен үзгәртәм) унҗиде яшендә кияүгә чыга. Танышуларына ике ай да үтми, егет аңа тәкъдим ясый. Һәм өйләнешкәч кәләшен туган авылына алып кайтып китә. Авыл җире ошый Саимәгә, матур гына яши башлыйлар. Йортта кайнана, кайната, каенсеңелләр. Беркөнне кайнана килененә гаилә серен ача:

— Алдан ук сиңа белгертмәгәнебезгә ачуланма. Иреңнең игез туганы төрмәдә утыра. Шуның хәлен белеп кайтыгыз әле, — ди.

Күчтәнәчләрен күтәреп, ире Самат белән Саимә ерак сәфәргә кузгалалар. Барып җиткәч, Самат хатынын төрмә капка төбендә калдырып эчкә кереп китә. Бер сәгать уза, ике сәгать, ир һаман күренми. Түземлеге төкәнгән яшь хатын нишләргә икән дип уй корганда Самат килеп чыга.

— Йә, картым, туганың белән күрештегезме? — ди ул.

Ире, беренче мәртәбә күргән сыман, аңа текәлеп-текәлеп карап тора. Төрмә шул, башы миңгерәгәндер, дип уйлый Саимә. Ябуда яткан туганын кызганып йөрәге дә сызланадыр.

— Күчтәнәчләрне яратып ашадымы соң? Әйдә, мине берәр фатирга урнаштыр да янында төн кунарсың. Туган-тумача өчен аерым бүлмә бар ди бит анда.

— Юк, булды, күрештек, кайтабыз, — дип кырт кисә Самат һәм кызу-кызу вокзалга табан атлый. Иренең ике сөйләшергә яратмаганын белгән хатын сүзсез генә аның артыннан ияргә.

Кайткач картлар сораша, ничек, Фәрит белән сөйләштегезме? Нәрсә ди, зарланамы, үкенәме? Мәгънәсезгә төрмәгә эләкте инде. Урлап машина саткан. Саткан акчасын да тапмады милиция, ятим балалар йортына бирдем ди үзе. Биргәндер, аның холкы шундый.

Нәрсә дисен килен. "Мине эчкә кертмәде Самат, малаегызның чыраен да күрмәдем", — ди.

Ә Самат үзе кайтканнан бирле җүнле-башлы сөйләшми. Эшкә дә йөрми, бөтен шөгыле — печәнлеккә менеп йокы симертү, тәмле ашау. Анысы ярый, сөйләшмәсен, эшләмәсен, атна-ун көн ял итсен (еллар буе ялсыз эшли әле), ә менә Саимәсенә салкынаюын берничек тә аңлатып булмый. Төнлә хатыны янына ятмый башлады, аерым йоклый, мунчада да ишекне бикләп ялгызы гына юына. Югыйсә ачуланышканнары да юк.

— Самат бәгырем, авырмыйсыңдыр ич? — дип өзгәләнә хатын, иренең бер алдына, биш артына төшә. — Авырсаң — тамагың кысылыр иде. Ашавың әйбәт, әнидән көн дә бәлеш пешертәсең, көн дә тавык суйдыртасың. Йомырка салырдай тавык калмады йортта. Шул төрмәне урап кайтканнан бирле әллә нишләдең син.

Элек шелтәләп берәр сүз әйтсәң Самат: "Җә, чәпчемә карчык" — дип көлә иде, хәзер ишетмәмешкә салыша, йөзен читкә бора.

Картлар да аптыраштa, каенсеңелләр дә аптыраштa. Шулай ике атна үтә. Бер кичне Самат хатынга:

— Фәритне барып күрик, иртәгә юлга җыен, — ди.

"Бар әле, кызым, карышма, — диләр картлар. — Әллә анда игезәге белән бер-бер хәл булып, Самат үзен эчтән кимерә микән, белеп кайт", — диләр.

Ир — инә, хатын — җеп, тагын Саматына ияреп төрмәгә юл тота Саимә. Бу юлысы Самат белән эчкә керергә дип бик өтәләнә ул, ләкин ир, теге вакыттагы кебек көтәргә кушып капка төбендә бастырып калдыра. Ярты сәгатьтән ук кебек атылып та чыга. Күзе акайган, борын тишекләре киңәйгән, артыннан куалармыни, еш-еш сулый.

— Ул сиңа тидеме? — ди ир, дөнья ярып акыра.

— Кем?

— Фәрит, минем игезәк сыңары!

— Шаштың мәллә, бәгърем. Фәритегезне бер булса да күргәнме соң әле мин.

— Ничек күрмәдең? Ике атна бергә яшәдегез, ничек күрмәдең?! — ди Самат, ярсыган саен ярсып. Аннан соң тынычлана. — Хәер, тимәгәндер, ант итте бит, хатыныңа күтәрелеп тә карамам, диде. Туган якны бер кайтып күрим, туйганчы ашармын, туйганчы йокьлармын, ике генә атнага мине алмаштыр, дигәч, кызгандым. Нәрсә, карчык, күзеңне шарландырдың? Теге чакта син авылга Фәрит белән кайтып киткән идең, әйе. Без аның белән бер тамчы су төсле, охшаганнар, хәтта әни белән әти дә аера алмый. Төрмә сакчыларын әйтмим дә.

"Көлсәң — көл, еласаң — ела, үпкәләсәң — гүпчим үпкәлә" дип хатын бу хәлне онытырга тырыша. Әмма күңелдәге бер уй тынычлык бирми. "Фәрит тиздән төп йортка әйләнеп кайтыр, Самат белән икесен бутамас өчен иремә нинди тамга салырга икән, дип баш ватам әле. Ир ул сиңа хайван түгел, мөгезенә чүпрәк бәйләп яки маңгаена буяу сөртеп булмый. Тамга мәсьәләсендә миңа берәрсе киңәш бирмәс микән?" — ди Саимә.

Сезнең киңәш кирәк, беренчеләр!

Журналны иң беренче саннарыннан ук алдыручылар, шушы авыр заманда ун ел буена "Идел"гә турылыклы калучылар — без бүген, уртак бәйрәмебез көнендә, сезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә сезнең киңәшегез кирәк. (Башка укучыларыбызның фикерләрен дә, һичшиксез, зиһенгә алачакбыз.)

Ә иң әүвәл, ниһаять, ныклабрак танышыйк әле. Без, журналны әзерләүчеләр, тыйнаклыкны бер читкә куеп, бәйрәм саны сәхнәсендә ару гына бөтерелеп алдык. Сез безне инде танып та беләсез, холык-фигыльләребезне дә чамалыйсыз булыр. Безнең дә сезне аерып беләсебез, һәркайсыгызга, үз итеп, "син" дип дәшәсебез килә.

Вакыт табып син менә шушы сорауларга җавап бирсәң иде.

1.	Исем-фамилияң, туган елың? Кайда яшисең, ни белән мәшгульсең? Нинди шатлыкларың, кайгы-гамьнәрең бар?
2.	"Идел" белән "язылышуың" ничек булды? Кулыңа беренче санны алган көнне хәтерлисеңме?
3.	Журналны ничә көн укыйсың, кайчан укыйсың? Синнән башка тагын ничә кеше укый? Яңа санны озак саклыйсыңмы?
4.	"Идел" авторларының кайсысын өзелеп яратасың? Ә тагын кайсыларын "просто" яратасың?

Ахыры 80 биттә

Ахыры 80 биттә

Кадерле укучыбыз!

Синең алда — журналыбызның табадан гына төшкән саны. Бөтен ачу-ярсуыңны (ә, бәлкем, канәгатьлек хисеңне дә) салып, буш урынга фикереңне яз әле. Тагын бер гозер: эчтәлектәге (икенче якта) исеме турына һәр әсәргә билге куй: мәктәптәгечә, 1 дән алып 5 кә кадәр (бик тә, бик тә, бик тә ошаганнарына «алтылы» тамызырга да ярый). Укымаганнары турына [—] билгесе куй.

Ә БУ САНГА ТУЛАЕМ НИНДИ БИЛГЕ КУЯСЫҢ? [ ]

Инде, кисеп, кәгазьне «Идел»гә җибәрәсе генә кала. Безнең адрес:

420012 Казан, Мөштәри ур., 14. «Идел».

Бу сан типографиягә тапшырыла: 13.07.99. Ә сезгә ул кайчан килеп җитте?

РАШАТ НИЗАМИ
КӨРӘШ РУХЫН ЮГАЛТМАСКА! 1
"Идел" бит ул!.. 3, 5, 26
Казан, Мөштәри ур., 14. "Идел"гә 4, 20, 21, 22, 27
Су башы
МАНСУР ВӘЛИЕВ
"ИДЕЛ" ӨЧЕН КӨРӘШ 4
Танышу
ДИНӘ ӘХМӘТ
PER ASPERA, БИШКҮМӘЧ ӘПИЕ
(сугарылган хикәя) 8
Су башы
КАМИЛ КӘРИМОВ
БЕЗ — "ИДЕЛ" МАЛАЙЛАРЫ 13
Ун ел элек...
РИМЗИЛ ВӘЛИ
ИДЕЛ ҺАМАН АГА 14
ИСМӘГЫЙЛЬ ШӘРӘФИЕВ
САГЫНУ 17
10024 битнең берсе 18, 20, 26, 64, 76
Вакыт тәрәзәсе
ИНСАФ СОЛТАНОВ
ФӘИЗНЕҢ ЯШЕЛ КУЫШЫ 22
ЛӘИС ЗӘЛКАРНӘЙ
КОЯШКА — ҖЫЛЫНЫРГА КИТТЕ 25
Бәрәкалла! 25
Журнал + укучы 27, 79
Нәсер
ӘЧТЕРХАН ЧИКЛӘВЕГЕ 28, 36, 44, 52
Безнекеләр 34, 42, 50, 57, 74
Шигърият
ЗАҺИД МӘХМҮДИ
ДАҺИДИЛАР 56
Нәсер
РӘМЗИЯ ГАБДЕЛХАКОВА
ЮГАЛТУ
хикәя 58
Укучыларыбызның берсе 63
Ша-Ярыш
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
МИНҺАҖ МАҖАРАЛАРЫ 66
Шәҗәрә
РОЗАЛИНА ШАҺИЕВА
"БОРЫНГЫ КАЗАН" 77
Галәмәт
НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА
"ИРЕМӘ ТАМГА КИРӘК" 78
Анкета 79

Тышлыкның 1 нче битендә Н. Хаҗиәхмәт эше, 2-4 битләрдә А. Тәхәвиев фоторәсемнәре.

5. 1989 елдан бирле чыккан әсәрләрнең кайсыларын "вәт ичмасам шәп!" дип, хәтер сандыгыңның түренә салып куйдың!?

6. Ун ел эчендә журнал шактый үзгәрде.

Үзгәрешләрнең әйбәтләре:

начарлары:

7. Шулай да, "Идел" кыйбласын үзгәртмәде. Бу фикер белән килешәсеңме?

8. Басылган әсәрләрнең үзеңә ошаган төрләренә, ошау дәрәҗәсенә карап, урын бир (иң ошаганы — 1, аннан бераз калыша төшкәне — 2 һ.т.ш.):

проза (нәсер) әсәрләре (повесть-бәян, хикәяләр: тарихи, фантастик, детектив, мәхәббәт хикәяләре) — иң ошаганнарының астына сыз; шигырьләр; тарихи тема; сәясәт; миллият; истәлекләр; юмор-сатира; хикмәтле хәлләр, тылсым; кроссвордлар, тестлар.
Бирелә аталмаганнардан тагын ни?

9. Журналның бизәлеше сиңа ошыймы? Ни җитеп бетми яки артык?

10. Иске логотипны (журнал исеменең тышлыктагы язылышы) үзгәртү дөрес булдымы? Яңасы сиңа ошыймы?

11. Журналны кай төшеннән укый башлыйсың? Нинди әйберләрне укымый калдырасың?

12. Әзерлекле укучыга аталган, төшенү кыенрак булган сәхифәләрне ("Миллият академиясе", "Идел" журналының аналитик үзәге") дәвам итәргә кирәкме, юкмы?

13. Баш мөхәррир булсаң, "Идел"гә нинди үзгәрешләр кертер идең?

Рәхмәт, эшләрең уң булсын. Инде җавапны кисеп алып, шушы адрес белән җибәрәсе генә калды:
420012. Казан, Мөштәри ур., 14. "Идел".
Анкетага сыймаганны өстәп яз.

1. Аучы-яугир. Х гасыр.
Н. Кумысникова реконструкциясе.

2. Рун язулы балчык савыт күчермәсе. VII гасыр. Новочеркасск музееннан.

3. Майолика. Алтын Урда чоры.

4. Казан тажы. XVI гасыр.

«Борынгы Казан» күргәзмәсе



Бу бәйрәм санының күрке сезнең күмәк рәсем булырга тиеш иде, кадерле укучыларыбыз. Ләкин 6 мең кешелек рәсемне ничек сыйдырасың?
Ун ел элек без, «Идел»челәр, сәфәр чыктык. Бу мавыктыргыч вә авыр сәфәрдә иң зур таянычыбыз сез булдыгыз.
Безгә беренче булып кушылганнар – рәхмәт сезгә!
Безгә юлда кушылганнар – рәхмәт сезгә!
Алга таба кушылачаклар – рәхмәт сезгә!
Ун ел бергә – димәк, мәңге бергә!